Документ подписан простой электронной подписью
Информация о владельце:
ФИО: Сыров Игорь Анатольевич
Должность: Директор
Дата подписания: 30.10.2023 15:09:25
Уникальный программный ключ:
b683afe664d7e9f64175886cf9626a198149ad36

СТЕРЛИТАМАКСКИЙ ФИЛИАЛ
ФЕДЕРАЛЬНОГО ГОСУДАРСТВЕННОГО БЮДЖЕТНОГО ОБРАЗОВАТЕЛЬНОГО
УЧРЕЖДЕНИЯ ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УФИМСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ НАУКИ И ТЕХНОЛОГИЙ»

Факультет ***Башкирской и тюркской филологии***
Кафедра ***Татарской и чувашской филологии***

**Рабочая программа дисциплины (модуля)**

дисциплина ***Б1.О.21 История родной (татарской) литературы***

обязательная часть

Направление

***44.03.05*** ***Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)***
код наименование направления

Программа

***Родной (татарский, чувашский) язык и литература, Иностранный язык***

Форма обучения

**Очная**

Для поступивших на обучение в
**2023 г.**

Разработчик (составитель)
***кандидат филологических наук, доцент***
***Мансуров И. С.***
ученая степень, должность, ФИО

Стерлитамак 2023

**1. Перечень планируемых результатов обучения по дисциплине, соотнесенных с установленными в образовательной программе индикаторами достижения компетенций** ........ 3

**2. Цели и место дисциплины (модуля) в структуре образовательной программы** ........ 3

**3. Объем дисциплины (модуля) в зачетных единицах с указанием количества академических или астрономических часов, выделенных на контактную работу обучающихся с преподавателем (по видам учебных занятий) и на самостоятельную работу обучающихся** ........ 4

**4. Содержание дисциплины (модуля), структурированное по темам (разделам) с указанием отведенного на них количества академических часов и видов учебных занятий** ........ 4

4.1. Разделы дисциплины и трудоемкость по видам учебных занятий (в академических часах) ........ 4

4.2. Содержание дисциплины, структурированное по разделам (темам) ........ 7

**5. Учебно-методическое обеспечение для самостоятельной работы обучающихся по дисциплине (модулю)** ........ 74

**6. Учебно-методическое и информационное обеспечение дисциплины (модуля)** ........ 167

6.1. Перечень учебной литературы, необходимой для освоения дисциплины (модуля) ........ 167

6.2. Перечень электронных библиотечных систем, современных профессиональных баз данных и информационных справочных систем ........ 169

6.3. Перечень лицензионного и свободно распространяемого программного обеспечения, в том числе отечественного производства ........ 170

**7. Материально-техническая база, необходимая для осуществления образовательного процесса по дисциплине (модулю)** ........ 170

**1. Перечень планируемых результатов обучения по дисциплине, соотнесенных с установленными в образовательной программе индикаторами достижения компетенций**

| Формируемая компетенция (с указанием кода) | Код и наименование индикатора достижения компетенции | Результаты обучения по дисциплине (модулю) |
|---|---|---|
| ПК-1. Способен использовать теоретические и практические знания для постановки и решения исследовательских задач в предметной области и в области образования | ПК-1.1. Знает о знаково-символической природе и генезисе языковых и литературных явлений, факторах их исторического развития для объяснения актуальных проблем и тенденций развития языка и литературы. | Обучающийся должен:<br>знать историю родной литературы в ее поступательном развитии и в персоналиях. |
| | ПК-1.2. Умеет интерпретировать лингвистические, историко-литературные, культурно-мировоззренческие явления и процессы в контексте общей динамики развития языка и литературы с учетом их использования для решения исследовательских задач. | Обучающийся должен:<br>уметь ориентироваться в способах и формах усвоения художественной традиции в истории литературы; анализировать художественные произведения татарских писателей, принадлежащих к различным художественным эпохам; собирать, структурировать и излагать материал по проблемам истории татарской литературы. |
| | ПК-1.3. Владеет навыками комплексного поиска, анализа и систематизации информации по изучаемым проблемам языка и литературы с использованием научных и текстовых источников, научной и учебной литературы, информационных баз данных. | Обучающийся должен:<br>владеть филологическим подходом к литературно-художественному материалу в его историческом развитии в макро- и микроуровневых параметрах, определением функционирования художественных приемов в произведениях поэзии, драматургии, прозы. |

**2. Цели и место дисциплины (модуля) в структуре образовательной программы**

Цели изучения дисциплины:
Дисциплина «История родной (татарской) литературы» относится к части, формируемой участниками образовательных отношений. Дисциплина изучается на 1-5 курсах.
Целью учебной дисциплины «История родной (татарской) литературы» является формирование у студентов комплексного представления об истории развития татарской литературы; познакомить студентов с основными фактами жизни и творчества ведущих представителей татарской литературы, определить направление их творческой эволюции и идейно-эстетических особенностей, поэтики их наиболее значительных произведений.

Дисциплина изучается на 1, 2, 3, 4, 5 курсах в 2, 3, 4, 6, 7, 8, 9, 10 семестрах

**3. Объем дисциплины (модуля) в зачетных единицах с указанием количества академических или астрономических часов, выделенных на контактную работу обучающихся с преподавателем (по видам учебных занятий) и на самостоятельную работу обучающихся**

Общая трудоемкость (объем) дисциплины составляет 26 зач. ед., 936 акад. ч.

| **Объем дисциплины** | **Всего часов** |
|---|---|
| | **Очная форма обучения** |
| Общая трудоемкость дисциплины | 936 |
| Учебных часов на контактную работу с преподавателем: | |
| лекций | 130 |
| практических (семинарских) | 254 |
| другие формы контактной работы (ФКР) | 7,4 |
| Учебных часов на контроль (включая часы подготовки): | 139,2 |
| экзамен | |
| дифференцированный зачет | |
| зачет | |
| курсовая работа | |
| Учебных часов на самостоятельную работу обучающихся (СР): | 405,4 |
| курсовая работа | |

| **Формы контроля** | **Семестры** |
|---|---|
| экзамен | 2, 8, 9, 10 |
| дифференцированный зачет | 3, 4 |
| зачет | 7 |
| курсовая работа | 9 |

**4. Содержание дисциплины (модуля), структурированное по темам (разделам) с указанием отведенного на них количества академических часов и видов учебных занятий**

**4.1. Разделы дисциплины и трудоемкость по видам учебных занятий (в академических часах)**

| **№ п/п** | **Наименование раздела / темы дисциплины** | **Виды учебных занятий, включая самостоятельную работу обучающихся и трудоемкость (в часах)** | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **Контактная работа с преподавателем** | | | **СР** |
| | | **Лек** | **Пр/Сем** | **Лаб** | |
| **1** | **Раздел 1. Древняя и средневековая татарская литература** | **16** | **32** | **0** | **60** |
| 1.1 | Древнетюркская литература | 4 | 6 | 0 | 12 |
| 1.2 | Литература булгарского периода (X – середина XIII века) | 2 | 4 | 0 | 10 |
| 1.3 | Литература периода Золотой Орды (с середины XIII века до | 6 | 10 | 0 | 16 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | середины XV века) | | | | |
| 1.4 | Литература периода Казанского ханства | 2 | 6 | 0 | 10 |
| 1.5 | Татарская литература XVII-XVIII веков | 2 | 6 | 0 | 12 |
| **2** | **Раздел 2. Татарская литература XIX в.** | **21** | **28** | **0** | **59,8** |
| 2.1 | Татарская литература первой половины XIX в. | 0 | 1 | 0 | 2 |
| 2.2 | Татарская поэзия первой половины XIX в. | 1 | 1 | 0 | 2 |
| 2.3 | Творчество А.Каргалыя, Х. Салихова | 2 | 1 | 0 | 2,8 |
| 2.4 | Творчество Ш. Заки и Кол Мухаммеда | 2 | 2 | 0 | 4 |
| 2.5 | Творчество Багави и Г. Кандалыя | 2 | 2 | 0 | 4 |
| 2.6 | Татарская литература второй половины XIX в. | 2 | 2 | 0 | 4 |
| 2.7 | Знаменитые татарский просветители и их деятельность | 0 | 2 | 0 | 4 |
| 2.8 | Татарская поэзия второй половины XIX в. | 1 | 1 | 0 | 4 |
| 2.9 | Творчество Мифтахеддина Акмуллы и Гали Чокрыя | 2 | 2 | 0 | 4 |
| 2.10 | Творчество Я.Емельянова и А.Уразаев–Курмаши | 2 | 2 | 0 | 4 |
| 2.11 | Творчество татарских поэтесс XIX века | 0 | 2 | 0 | 5 |
| 2.12 | Татарская проза второй половины XIX в. | 0 | 2 | 0 | 4 |
| 2.13 | Творчество М.Акъегет и З.Бигиева | 2 | 2 | 0 | 4 |
| 2.14 | Творчество Р.Фахретдинова и Ф.Карими | 2 | 2 | 0 | 4 |
| 2.15 | Творчество З.Хади и Ш.Мухахамедова | 2 | 2 | 0 | 4 |
| 2.16 | Первые образцы татарской драматургии. Творчество Г.Ильяси и Ф.Халиди | 1 | 2 | 0 | 4 |
| **3** | **Раздел 3. Татарская литература начала XX века** | **11** | **20** | **0** | **40** |
| 3.1 | Татарская поэзия начала XX века | 1 | 2 | 0 | 4 |
| 3.2 | Творчество Габдуллы Тукая | 2 | 4 | 0 | 8 |
| 3.3 | Творчество Мажита Гафури | 2 | 4 | 0 | 6 |
| 3.4 | Творчество Сагита Рамеева | 2 | 4 | 0 | 4 |
| 3.5 | Творчество Дэрдменда | 2 | 2 | 0 | 6 |
| 3.6 | Творчество Нажиба Думави | 1 | 2 | 0 | 6 |
| 3.7 | Творчество Шайхзады Бабича | 1 | 2 | 0 | 6 |
| **4** | **Раздел 4. Татарская проза начала XX века** | **20** | **44** | **0** | **115,8** |
| 4.1 | Творчество Гаяза Исхаки: проза, драматургия, публицистика | 4 | 6 | 0 | 20 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4.2 | Творчество Фатиха Амирхана: проза, драматургия, публицистика | 2 | 6 | 0 | 12 |
| 4.3 | Творчество Галимджана Ибрагимова: проза, драматургия, публицистика | 4 | 8 | 0 | 15,8 |
| 4.4 | Творчество Шарифа Камала | 2 | 6 | 0 | 16 |
| 4.5 | Зарождение татарского театра и его влияние на развитие татарской драматургии | 2 | 4 | 0 | 10 |
| 4.6 | Творчество Галиасгара Камала | 2 | 6 | 0 | 16 |
| 4.7 | Творчество Гафура Кулахметова | 2 | 2 | 0 | 10 |
| 4.8 | Творчество Мирхайдара Файзи | 2 | 6 | 0 | 16 |
| **5** | **Раздел 4. Татарская литература 20-х годов (1917-1929 гг.)** | **10** | **22** | **0** | **40** |
| 5.1 | Творчество Мажита Гафури | 2 | 4 | 0 | 8 |
| 5.2 | Литературная и общественная деятельность Галимджана Ибрагимова | 2 | 6 | 0 | 10 |
| 5.3 | Творчество Хади Такташа | 2 | 4 | 0 | 7 |
| 5.4 | Творчество Карима Тинчурина | 2 | 4 | 0 | 7 |
| 5.5 | Творчество Фатхи Бурнаша | 1 | 2 | 0 | 4 |
| 5.6 | Творчество Махмута Галяу | 1 | 2 | 0 | 4 |
| **6** | **Раздел 5. Татарская литература 30-х годов (1930-1941 гг.)** | **10** | **22** | **0** | **39,7** |
| 6.1 | Творчество Шарифа Камала и Тази Гиззат | 2 | 4 | 0 | 6 |
| 6.2 | Творчество Кави Назми и  Гаделя Кутуя | 2 | 4 | 0 | 8 |
| 6.3 | Татарская литература периода Великой отечественной войны (1941-1945 гг.) | 2 | 4 | 0 | 8 |
| 6.4 | Творчество Мусы Джалиля | 2 | 6 | 0 | 9,7 |
| 6.5 | Творчество Фатиха Карима | 2 | 4 | 0 | 8 |
| **7** | **Раздел 6. Татарская литература 40-65-х годов XX века** | **10** | **22** | **0** | **4** |
| 7.1 | Поэзия 40-65-х годов | 2 | 6 | 0 | 2 |
| 7.2 | Проза 40-65-х годов | 4 | 8 | 0 | 1 |
| 7.3 | Драматургия 40-65-х годов XX века | 4 | 8 | 0 | 1 |
| **8** | **Раздел 8. Татарская литература 65-85-х годов XX века** | **16** | **32** | **0** | **22** |
| 8.1 | Поэзия 65-85-х годов XX века | 4 | 4 | 0 | 4 |
| 8.2 | Проза 65-85-х годов XX века | 4 | 6 | 0 | 5 |
| 8.3 | Драматургия 65-85-х годов XX века | 4 | 6 | 0 | 5 |
| 8.4 | Пути и основные тенденции развития татарской литературы конца XX века | 1 | 4 | 0 | 2 |
| 8.5 | Татарская поэзия в контексте общественно-исторических реалий | 1 | 4 | 0 | 2 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 8.6 | Новые направления в татарской прозе конца XX века | 1 | 4 | 0 | 2 |
| 8.7 | Драматургия и театр конца XX века | 1 | 4 | 0 | 2 |
| **9** | **Раздел 9. Современная татарская литература** | **16** | **20** | **0** | **24** |
| 9.1 | Современные тенденции развития татарской поэзии | 6 | 6 | 0 | 8 |
| 9.2 | Разнообразие литературных направлений и течений в татарской прозе | 6 | 8 | 0 | 8 |
| 9.3 | Основные тенденции и закономерности развития татарской драматургии | 4 | 6 | 0 | 8 |
| | **Итого** | **130** | **242** | **0** | **405,3** |

### 4.2. Содержание дисциплины, структурированное по разделам (темам)

Курс лекционных занятий

| № | Наименование раздела / темы дисциплины | Содержание |
|---|---|---|
| **1** | **Раздел 1. Древняя и средневековая татарская литература** | |
| 1.1 | Древнетюркская литература | Гомумтөрки (борынгы төрки) әдәбият. Борынгы төркиләр. Аларда язу барлыкка килү мәсьәләсе. Туран (һун), рун һәм уйгур графикалары.<br>Барлык төрки халыкларның уртак мирасы дип каралган «Орхон – Енисей» язмалары. Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет–төрк» (1073–1074) китабы. Йосыф Хас Хаҗиб Баласагуниның 1069–1070 елларда язылган «Котадгу белег» дидактик поэмасы. Әхмәд Йүгнәки (XII йөз). Аның дидактик характердагы «Һибәтел–хакаик» («Хаклыклар бүләге») поэмасы. Әхмәд Ясәви (1166 елда үлә) һәм Сөләйман Бакырганый (вафаты 1186 елда) – төрки суфыйчылык шигъриятенең күренекле вәкилләре. |
| 1.2 | Литература булгарского периода (X – середина XIII века) | Болгар–хәзәр чоры. Кол Гали һәм аның “Кыйссаи Йосыф” дастаны. Болгар мифологиясе һәм халык авыз иҗаты үрнәкләре: риваять–легендалар, мәкаль–әйтемнәр, җырлар. Болгарның борынгы Русь белән мөнәсәбәтләренә бәйләнешле риваятьләр. Болгар чоры язма әдәбиятының мәшһүр шагыйре Кол Гали һәм аның «халыкка җан азыгы булган кыйммәтле әдәби җәүһәре «Кыйссаи Йосыф» дастаны (поэмасы). |
| 1.3 | Литература периода Золотой Орды (с середины XIII века до середины XV века) | Алтын Урда чорында әдәбият. Суфыйчылык әдәбияты. Алтын Урда дәүләте чорында кыпчак һәм угыз, болгар телләре нигезендә уртак тел оеша башлау, язма әдәбият вәкилләренең төрле төрки төбәкләрдән чыгуы. Иҗат ияләренең башлыча гарәп һәм фарсы телле Көнчыгыш классикларына йөз тотуы. Котб, Харәзми, Сәйф Сараи кебек шагыйрьләрнең Хәйям, Фирдәүси, Әбүгалисина, Низами, Сәгъдиләрдән килә торган дөньяви мотивларны |

| | | |
|---|---|---|
| | | үстерүе. Мәхмүд бине Гали Әл–Болгари, Хисам Кятиб кебек язучыларның Газзали, Фәрideддин Гаттар иҗатыннан килгән суфичылык традицияләренә иярүләре. Суфичылык һәм аны барлыкка китергән сәбәпләр. XlV нче йөзләрдә Идел–Урал буе төрки–татар әдәбиятында дини–мистик рухлы агымның көчәюе, моның социаль–тарихи сәбәпләре, идея–эстетик чыганаклары, «Диване Хикмәт», «Бакырган китабы» дигән җыентыклар, «Кисекбаш», «Кыйссаи Сәкам», «Нәсыйхәт–әс–салихин» кебек дини–дидактик, дини–суфичыл, дини–каһарманлык дастаннары барлыкка килү, аларда ислам диненең бөеклеген исбатларга омтылу.<br>Рабгузыйның "Кыйссасел–әнбия" китабы. Котб "Хөсрәү вә Ширин" әсәре. Дастанның саклану һәм өйрәнелү тарихы, хәзергә кадәрге басмалары. Котб дастанының язылу урыны һәм шартлары. «Хөсрәү вә Ширин» дастанының сюжеты, композицион төзелеше, образлар системасы. Поэманың оптимистик рухы. Шагыйрьнең поэтик осталыгы. Харәзми "Мәхәббәтнамә" поэмасы. Поэманың язылу һәм саклану тарихы, кулъязма нөсхәләре. Әсәрнең сюжет үзенчәлеге, композицион төзелеше. Мәхмүд Болгари (Мәхмүд бине Гали) "Нәһҗел–фәрадис" әсәре. Әсәр күчермәләренең табылган урыннары, фәнни яктан өйрәнелү тарихы. Авторның кайсы төбәктән чыккан булуы, әсәрнең язылу вакыты һәм урыны. Идел–Урал буе төрки әдәбиятында хикәячелек жанрын үстерүдә «Нәһҗел–фәрадис» әсәренең урыны һәм роле, аның традицияләре. Хисам Кятиб "Җөмҗөмә солтан" дастаны. Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (1370) әсәренең язылу урыны һәм шагыйрь биографиясенең ачык булмавы. Дастан күчермәләренең таралу төбәкләре, басма нөсхәләре турында мәгълүмат. Әсәрнең шигъри төзелеше, поэтик нәфисләү чаралары, тасвир алымнарында халык эпосы традицияләре: сыйфатны сан зурлыгы (күләм) белән ачарга омтылу, шигырьдә мәкаль һәм әйтемнәрне иркен куллану. Сәйф Сараи "Гөлестан бит–төрки" әсәре "Сөһәйл вә Гөлдерсен" дастаны. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (1394 ел) поэмасы. Әсәр сюжетының реаль җирлеге булу ихтималы, авторның «чынлык» тенденциясен алга сөрүе. Шагыйрь мирасының әһәмияте. Сайядинең «Дастан Бабахан» әсәренең таралу даирәсе, саклану һәм өйрәнелү тарихы. «Дастан Бабахан»ның татар әдәбияты үсешенә зур йогынты ясавы. Сайяди дастанының композициясе, сюжеты, образлар системасы, әдәби эшләнеше. |
| 1.4 | Литература периода Казанского ханства | Казан ханлыгы чоры татар әдәбияты. Мөстәкыйль дәүләт буларак, Казан ханлыгының барлыкка килүе. Казан шәһәре һәм казанлылар турында тарихи чыганаклар, риваятьләр, легендалар. Җирле |

| | | |
|---|---|---|
| | | халыклардан җырчы–чичәннәр, музыкантлар, рәссамнар, төрле әдип–шагыйрьләр һәм галимнәр үсеп чыгуы. (Гарифбәк, Колшәриф, Мөхәммәдшәриф, Касыйм, Нух, Мөхәммәдьяр). Көнчыгыш белән бәйләнештә Казанның роле. Бу чорда башка төбәкләрдәге төрки телле әсәрләрнең Идел–Урал буенда киң таралыш табуы (азәрбайҗан, үзбәк, госманлы, төркмән әдип һәм шагыйрьләреннән Әхмәди, Мир Хәйдәр, Дүрбәк, Лотфи, Мөхәммәд Чәләби, Вафи, Физули һәм Нәваи әсәрләре). Госманлылар, комыклар, татарлар һәм башкортлар үз шагыйре итеп санаган Өмми Камал (чын исеме Исмәгыйль) әсәрләренең Идел–Урал буенда яратып укылуы. Аның әсәрләренең идея–эстетик асылы, Казан татар әдәбиятына тәэсире. Мөхәммәдъяр “Нәсыйхәт” әсәре, “Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” поэмалары. Мөхәммәдьяр әсәрләренең табылу һәм саклану тарихы. Аның иҗатын өйрәнүче әдип һәм галимнәрнең эшчәнлеге (И.Березин, М.Иванов, Н.Исәнбәт, Ш.Абилов, Х.Миңнегулов һ.б.). Шагыйрь шәхесе турында мәгълүмат.Татар поэзиясен үстерүдә Мөхәммәдьяр иҗатының роле. Кадыйр Галибәк “Җәмигъ эт–тәварих” җыентыгы. Кадыйр Галибәкнең «Җәмигъ эт–тәварих» (1602) әсәре. Аның тәрҗемә әсәре булуы һәм оригинальлеге мәсьәләсе. Бу әсәрне өйрәнүгә өлеш керткән хәзерге галимнәрнең эшчәнлеге турында мәгълүмат. «Җәмигъ эт–тәварих»ның башка төрки халыклар культурасына мөнсәбәте. Әсәрдә гомумватанчылык идеясе; Борис Годуновка мәдхия җырлау; рус монархиясе кулы астында үзәкләшкән феодаль дәүләтне яклау. |
| 1.5 | Татарская литература XVII-XVIII веков | XVII йөз татар әдәбияты. Мәүлә Колый иҗаты. XVI йөзнең ахырында һәм XVII йөздә татар халкының иҗтимагый–сәяси хәле һәм мәдәнияте. Суфичылык идеяләренең яңадан җанлануы, моның сәбәпләре. Мәүла Колый әсәрләренең саклану тарихы, кулъязма нөсхәләрнең таралуы һәм аларны фәнни өйрәнүгә өлеш керткән әдип–галимнәрнең эшчәнлеге (Фазыл Туйкә, Г.Сәгъди, Г.Ибраһимов, Х.Хисмәтуллин, Х.Госман, К.Дәүләтшин, Г.Хөсәенов һ.б.). Мәүла Колый хикмәтләренең тематикасы, каршылыклы идея–эстетк табигате. Мәүла Колый хикмәтләренең лирик герое. 1990 елларда табылган ике поэмасы: «Берекәннәр сыйфаты» һәм «Хәләл ризык эстәгәннәр сыйфаты». Аларның идея–эстетик үзенчәлеге.<br>XVIII йөздә татар халкының иҗтимагый тормышы. Халык тормышы һәм көнкүрешнең авыз иҗаты әсәрләрендә чагылышы: «Лашманчы зары» һәм «Лашман бәете», «Солдат бәете», «Никрутлар бәете», «Пугачев бәете», «Салават Юлай» һәм «Салават бәете». Елъязмалар тибындагы әсәрләр, сәяхәтнамәләр, васыятьнамәләр; «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе», «Мөхәммәд Әмин сәяхәтнамәсе»; Гаделшаһ бине |

| | | |
|---|---|---|
| | | Габдулла һәм Габдерахман бине Туймөхәммәд васыятьнамәләре; Аксак Тимернең Болгар шәһәрен җимерүе турындагы елъязмалар, Акай кузгалышы һәм Пугачев сугышы, Екатерина II нең Казанга килүе турында язмалар. Мөхәммәдрәхим бине Рәфыйк Казани тарафыннан төзелгән һәм күчереп язылган «Мәҗмугыл–хикәят» җыентыгы. Таҗетдин Ялчыгол (1768–1838). Тормыш юлы, иҗат мирасы, күпкырлы эшчәнлеге (педагог, текстолог, тарихчы, рухани, табиб һ.б.). Әдипнең Суфый Аллаяр иҗат иткән «Сөбател гаҗизин» китабын «Рисаләи Газизә» исеме белән шәрехләве (1806). XVIII гасырда татар прозасының тематикасы киңәюе һәм форма ягыннан төрләнүе. Габдрәхим Утыз Имәни иҗаты. Габдрәхим Утыз Имәнинең (Габдрәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырым әл–Болгари) – XVIII–XIX гасыр чикләрендә иҗат иткән күренекле шагыйрь, энциклопедик белемле галим һәм җәмәгать эшлеклесе булуы. Аның тормыш юлы, иҗат мирасы турында мәгълүмат. Шагыйрьнең иҗатын өйрәнүгә өлеш керткән әдип–галимнәрнең эшчәнлеге. Аның шигъри әсәрләрендә фикер азатлыгы, гыйльми–мәгърифәт мәсьәләләре. Мәсәлән: «Тәхфәт–ел–гьөрабаә вә ләтаиф–ел–гьәзае» (Горбәтлектә йөрүчеләргә бүләк һәм аларның хурлыкка калу вакыйгалары). «Горбәтнамә» (Читтә йөрүче хикәясе). «Гавариф–эз–заман» (Замана бүләкләре), «Тәнәиһ–ел–әфкяр фи Нәсаих–ел–әхйар» (Фикерләрне пакъләндерүче файдалы киңәшләр», «Мөһиммәт–эз–заман» (Заманның мөһим билгеләре) әсәрләренең идея–проблематик тирәнлеге. Аерым шигырьләренең үзәгенә авторның үз шәхесе, үз тормышы, үзе кичергән вакыйгалар килеп керүе; үзенчәлекле лирик герой гәүдәләнеше. Утыз Имәни иҗатына Габдулла Тукай мөнәсәбәте. Шагыйрь Габдрәхим Утыз Имәнигә багышланган хезмәтләр. |
| **2** | **Раздел 2. Татарская литература XIX в.** | |
| 2.2 | Татарская поэзия первой половины XIX в. | Әдәбиятның, нигездә, шигъри характерда үсеше һәм аның төп юнәлешләре: а) дини–әхлакый; б) суфыйчыл; в) дөньяви. Аларың еш  кына үзара керешен китүе. Поэзиядә публицистик яңгырашның көчәюе (Г.Утыз Имәни «Гавариф–әз–заман»). Чорга хас социаль вакыйгаларның киңрәк урын алуы («Иляһи бәетләр»). Әхлаксыз, надан дин әһелләрен, залим түрәләрне сатирик фаш иткән әсәрләр язылу («Мүкән кантун», Г.Кандалый «Тотынышып кулың кулга»). Крестьянның авыр тормышына, социаль тигезсезлеккә, хатын–кыз язмышына игътибар арту («Илаһи бәет. Уделный», Г.Кандалый «Сәхибҗәмал»). Фольклорга тартым мавыктыргыч дастан–кыйссаларның активлашуы («Бүз егет», «Тутыйнамә»).<br>Либераль аристократия карашларын чагылдыручы әсәрләр (Гомәр Мөхәммәд улының «Тәзкирәи мөфти |

| | | |
|---|---|---|
| | | Габдессәлам» (1832), «Сәфәрнамәи шаһзадә Александр» (1837) поэмалары).<br>Бу чор әдәбиятында жанр төрлелеге (мәдхия, мәрсия, мөнәҗәт, шигъри хат, шигъри хикәят, шигъри сатира, мәсәл, күңел лирикасы һ.б.). Сурәтләү алымнары. Җанлы сөйләмгә нигезләнгән әсәрләрнең киңрәк урын ала баруы.<br>XIX гасыр урталарына таба татар поэзиясендә дөньяви мотивларның, реализм элементларының һәм күпчелеккә аңлаешлы телдә язылган шигырьләрнең урын ала баруы. Татар тормышының реаль күренешләрен тасвирлый башлау. |
| 2.3 | Творчество А.Каргалыя, Х. Салихова | Әбелмәних Каргалый (1782–1833 елдан сон}. Әсәрләре. Сәяхәтнамә һәм лирик мөнәҗәтләре. Шигырьләрендә дөньяви мәсьәләләр. Пейзаж һәм күңел лирикасы. Лирик мөнәҗәтләре. Әсәрләрендә суфичылык мотивлары. Иҗатының әһәмияте.<br>Һибәтулла Салихов (1794–1867). Беренче мәрсияләре. «Тәндә җаным...» шигыре. Дини–суфичылык мотивлары. Әсәрләрендә әхлак, тәрбия, шәхес һәм тирәлек мәсьәлә–ләре. Тел–стиль һәм идея–художество үзенчәлекләре. |
| 2.4 | Творчество Ш. Заки и Кол Мухаммеда | Шәмсетдин Зәкинең (1821–1865) тормышы һәм иҗат мирасы. Фәлсәфи рухтагы шигырьләре. Шагыйрьнең образлы фикерләү үзенчәлекләре, поэтик osталыгы. Әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше.<br>Кол Мөхәммәд (1775.– 1845) Тәрҗемәи хәле һәм иҗади мирасы. Поэмаларында әхлаки мәсьәләләр. Шигырьләрендәге фәлсәфи фикерләве, дини тематикага өстенлек бирелүе. |
| 2.5 | Творчество Багави и Г. Кандалыя | Баһавиның «Бүз егет» (1842) дастаны. Әсәр сюжетында дөньяви күренешләрнең фантастик алымнарда бирелүе. Кешенең бәхеткә, шәхси ирекkә хокукы, хатын–кыз язмышы һ.б. мәсьәләләрнең инсани планда хәл ителүе.<br>Габделҗәббар Кандалый (1797–1860) Тормышы һәм шәхесе турында мәгълүматлар. Иҗади мирасын туплау һәм өйрәнү. Әдипнең башлангыч чор иҗаты. Мәхәббәт лирикасы. Иҗатының төп яңалыклары. Шигырь техникасын баетуы. Иҗатының әһәмияте. |
| 2.6 | Татарская литература второй половины XIX в. | Гасыр уртасында җәмгыять үсешендә туган каршылыклар. 1861 елда крепостное право бетерелүе һәм Рәсәйнең, шул исәптән татар халкының, капиталистик үсеш юлына чыгуы. Азатлык хәрәкәтенең яңа этабы. Крестьян восстаниеләре. Тарихи социаль–икъдисади үзгәрешләрнең, иҗтимагый фикернең халыкларга тәэсире. Төрки халыкларда уяну хәрәкәтенә юл салучы эшлеклеләрнең мәйданга чыгуы: Азәрбайҗанда – Ахундов М.Ф., Казахстанда – Ч.Вәлиханов, А.Кунанбаев, татарларда – Х.Фәезханов, К.Насыйри һ.б.<br>Рус җәмгыятендә демократик көчләрнең татарлар |

| | | |
|---|---|---|
| | | тормышы белән кызыксынуы. «Современник» журналында П.И.Пашино мәкаләләре басылып чыгу. Казанда Татар укытучылар мәктәбе ачылу (1876). Аның педагогик кадрлар әзерләүдәге роле. Бу мәктәптә төрле елларда белем алган күренекле шәхесләр (Х.Ямашев, Г.Исхакый, С.Максуди, Г.Коләхмәтов һ.б.).<br>Казан университеты каршында оештырылган «Археология, тарих һәм этнография» җәмгыяте (1878) эшчәнлегендә рус һәм татар галимнәренең катнашуы (Н.Катанов, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри Һ.б.).<br>Татар телендә вакытлы матбугат чыгаруга омтылышлар һәм аларның тормышка ашмау сәбәпләре (И.Запольский, М.Никольский, П.Пашино, Х.Фәезханов, К.Насыйри, З.Бигиев, Ш.Әхмәров һ.б.). |
| 2.8 | Татарская поэзия второй половины XIX в. | Поэзиянең татар әдәби традицияләренә таянуы һәм шулай ук чынбарлыкка, халыкны борчыган мәсьәләләргә итүе. Тормыштагы үзгәрешләргә бәйле мәгърифәтчелек идеяләренең шигъриятькә тирән үтеп керүе. Халыкның үткәненә, олы шәхесләргә мөрәҗәгать итү көчәю (Г.Чокрый, Акмулла). Шәхеснең уй–кичерешләрен үзәккә кую аша белемлелек, әхлакый сыйфатлар макталу, социаль каршылыкларны күрсә-түнең публицистик яңгыраш алуы (Акмулла, Б.Вәисев). Яңа традицияләр эзләп рус поэзиясенә мөрәҗәгать итү (Я.Емельянов). Тәрбия, гаилә мәсьәләләренә игътибар арту һәм аның бигрәк тә шагыйрәләр иҗатында актив яңгыраш алуы (Г.Сәмитова, Бибигөлҗамал һ.б.). Дастан жанрының яңа биеклеккә күтәрелүе (Ә. Уразаев–Кормаши). Бу чор поэзиясенең яңа сыйфат үзгәрешләренә әзерлек чорын кичерүе. XVII йөз шагыйре Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» сюжеты нигезендә яңа Сәйфелмөлек дастаннары барлыкка килүе. Йосыфбик һәм М.Юмачиков дастаннары. «Эрбет бәете». «Мәкәрҗә бәете»нең (1860) язылу, басылу тарихы. Тормышны Мәкәрҗә ярминкәсе белән чагыштыру. Халыкның фәкыйрьлектә, авыр тормышта яшәвен реаль күренешләрдә тасвирлау. Моның өчен түрәләр гаепле дигән фикер үткәрелү. «Яхшыга бәхет, начарга җәза» фәлсәфәсенең яклануы. Гади халык яклауга мохтаҗ дигән нәтиҗә ясалу. Моның халык сабырлыгы, патшага тугрылыгы дигән фикер артына яшерелүе. Әсәрнең әһәмияте. |
| 2.9 | Творчество Мифтахеддина Акмуллы и Гали Чокрыя | Мифтахеддин Акмулланың (1831–1895) татар, казакъ, башкорт халыкларының уртак әдибе, мәгърифәтче, олы фикер иясе булып танылуы. Аның катлаулы тормыш һәм иҗат юлы, шәхесе. Әсәрләрендә мәгърифәтчелек идеяләре («Бәгъдәссәлам, Нургали мулла...» һ.б.). «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе»н дә гыйлем, әхлак мәсьәләләренең романтик рухта сурәтләнүе. Төрмәдә язган шигырьләрендә социаль мотивларның |

| | | |
|---|---|---|
| | | чагылуы. Лирик герой хис–кичерешләрендә тормыштагы гаделсезлекнең бирелүе («Урыным – зиндан...», «Гаҗәб: һәр кем гани булса...», «Минем кебек булыр микән бәхетсез» һ.б.). Әдипнең чын гыйлемлекне әхлакый сафлык белән бәйләп каравы («Иң әүвәл пакьләү кирәк эчнең керен...») һәм наданлыкка, комсызлыкка сатирасы («Бәланың күбе чыга эчемездән...», «Башка илне без күрәбез...»). Акмулла – чичән шагыйрь. Сәнгати осталыгы белән әдәбиятка ясаган йогынтысы.<br>Гали Чокрыйның (1826–1889) тормышы, әдәби мирасы. Иҗатында дини–суфыйчыл традицияләрнең дөньяви мотивлар белән үрелеп баруы. «Шәмгыз–зыя» (1883) китабында заманының күренекле шәхесләренә, руханиларга мөрәҗәгать итүе. Алар эшчәнлегенең әһәмиятен билгеләп, киләчәкнең шундый кешеләргә бәйле булуын күрсәтү. «Мәдхе Казан» (1889) китабында белем йорты, мәдәни учак буларак Казанның макталуы. «Хаҗнамә»дә (1876–1879) әдипнең фәлсәфи–публицистик уйланулары, фән–техника прогрессын яклавы чагылу. Туган як турындагы хис–кичерешләренең үзенчәлекле бирелеше. «Фосуле әрбага» циклында табигать күренешләренең кеше яшәешенә, аның рухи халәтенә бәйле сурәтләнүе. |
| 2.10 | Творчество Я.Емельянова и А.Уразаев–Курмаши | Яков Емельяновның (1843–1898) тормыш юлы, әдәби мирасы. Гади халыкның авыр тормышын, аянычлы көнкүрешен реалистик детальләрдә сурәтләве («Ярлы тормыш», «Кайгы» һ.б.). Шигырьләрдә үзара ярдәмләшүгә, изге гамәлләр кылуга, ата–ананы, өлкәннәрне хөрмәт итәргә чакыру һәм һәртөрле әхлаксызлыкны, усаллык–яманлыкны тәнкыйтьләү («Улыма», «Санлау», «Саран бай», «Әләк» һ.б.). Әдипнең яңа традицияләр эзләп рус поэзиясенә (И.Никитин иҗатына) мөрәҗәгать итүе. Шигырьләренең вакыйгачылыкка нигезләнүе. Җанлы сөйләм теленә таянган «сөйләм» жанрын үстерүе. Емельянов поэзиясенең үзенчәлекле сыйфатлары: теленең халыкча, тасвирның гади, ачык булуы. Шигырьне ритмик яктан баету һәм төрләндерү тәҗрибәсе. Халык авыз иҗаты белән бәйләнеше. Шагыйрьнең татар поэзиясендә тоткан урыны.<br>Әхмәт Уразаев–Кормаши (якынча 1855–1883) иҗатында романтик мәхәббәт сюжетына нигезләнгән дастан–кыйсса жанры үсеше. Баһави дастанына ияреп иҗат ителгән «Кыйссаи Бүз егет» (1874). Шигырь аралаш проза белән язылган «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» дә (1876) Сайяди әсәренең яңача үстерелеше. Шәхес азатлыгы, саф мәхәббәт өчен көрәшүче Таһир һәм Зөһрәнең кара көч символы булган ханга, аның властена капма– каршы сурәтләнүе. Коръәннән, Урта гасыр әдәбиятыннан килүче сабырлык, гаделлек, игелеклелек |

| | | |
|---|---|---|
| | | кебек сыйфатларның яклануы. Дини эчтәлек белән реаль вакыйгаларның үзара бәйләнеп килүе. Әсәрдә сурәтләү чаралары. |
| 2.13 | Творчество М.Акъегет и З.Бигиева | Муса Акъегетзаденең (1864–1923) тормыш һәм иҗат юлы. Аның Европа әдәбияты тәэсирендә булуы. «Хисамеддин менла» (1886) әсәре. Жанры (повесть – роман) турында бүгенге фәндәге карашлар. Әсәрдә кадимчелек һәм җәдитчелек каршылыгы үзәккә куелуы. Күтәрелгән төп мәсьәләләр: шәхес, мәхәббәт иреге һәм милләт мәнфәгате; гаилә тәрбиясе һәм мәдрәсәдә укыту; халыкчылык идеясе. Аларның Хисамеддин, Әбүзәр Дәүләтгилдиев, Гайса Зурколаков, Мохтар образларының эш–хәрәкәтендә хәл ителеше. Авторның шәхес ирегенә омтылу мәсьәләсен күтәрүдәге кыюлыгы, кешене горур итеп күрергә теләү мотивын сурәтләве. Хатын–кыз язмышының Хәнифә образына бәйле рәвештә бирелеше. Тискәре геройларны берьяклы гына сурәтләү.<br>Романның композициясе һәм сюжет үстерелеше. Мәхәббәт, көнкүреш һәм иҗтимагый–социаль каршылыкларның үзара бәйләнештә бирелүе. Аның рус–Аурупа әдәбиятлары йогынтысында язылуы. Әсәрдә иҗтимагый мәсьәләләрнең шәхси һәм тормыш–көнкүреш күренешләре белән аралашып килүе. Публицистик һәм лирик чигенешләрнең төп идеягә хезмәт итүе. Портрет, пейзаж кебек алымнарның, этнографик детальләрнең роле. Тел–сурәтләү чараларын кулланудагы үзенчәлекләр. Геройларның эчке дөньясын ачу алымнары, психологик анализ яралгылары. Татар әдәбиятында беренче реалистик роман буларак әһәмияте.<br>Заһир Бигиевнең (1870–1902) тормышы һәм иҗат эшчәнлеге. Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятларын яхшы белгән шәхес буларак формалашуы. Берничә кульъязмасының әлегәчә табылмавы. Туганы дин белгече Муса Бигиевнең эшчәнлеге һәм язмышы турында мәгълүмат.<br>«Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887) романы. Аның татар әдәбиятында детектив жанрдагы тәүге әсәрләрнең берсе булуы. Җинаять эшен тикшерү мәсьәләсенең гаилә, әхлакый сыйфатлар, хатын–кыз язмышы белән бәйлелектә бирелүе. Акча (Меңнәр) өчен көрәшүче Муса һәм Габденнасыйр каршылыгының чишелешендә әхлакый хөкемнең тантана итүе. Зөләйха һәм Хәдичә образларында хатын–кыз бәхете, ирек мәсьәләсенең М.Акъегетзадә фикеренә каршы планда хәл ителеше: ата–ана фатихасын алмаган Зөләйханың бәхетсезлеккә дучар булуы, өлкәннәр сүзеннән чыкмаган Хәдичәнең бәхеткә ирешүе. Әсәрдә суд һәм тикшерү органнарында эшләүчеләрнең каршылыклы бирелеше һәм аларның образ буларак ачылу дәрәҗәсе. Хикәяләү |

| | | |
|---|---|---|
| | | вакыйгалылыкка корылган романда психологик анализның йомшак булуы. Җәмгыять асылының романда объектив рәвештә реалистик чагылышы. Әсәрдәге фаҗигаларның сәбәпләренә язучының мәгърифәтчел карашлары. Әсәрнең композицион үзенчәлеге һәм теле.<br>«Зур гөнаһлар» («Гөнаһе кәбаир», 1890) романында вакыйгаларның ике сюжет сызыгы буенча үстерелеше. Габделгафурның җинаяткә килү юлын гаилә тәрбиясе һәм мәдрәсә тормышы фонында күзәтү. Маһруйны «зур гөнаһларга» китергән сәбәпләрне реалистик планда, җәмгыятьтәге шартларга бәйләп ачу. Җиһангир – уңай герой идеалы. Әлеге ике образда «Коръән»нән һәм Урта гасыр татар әдәбиятыннан килгән карашларның яклануы. Романда Ягъкуб һәм Ибраһим Галиевлар, акушерка карчык, Мәмәт образлары. Эш–хәрәкәтләренең ышандыру көченә күбрәк ия булуы. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше.<br>«Мавәраэннәһердә сәяхәт» (1893) әсәренең язылу тарихы. Сәяхәтнамәдә заманга бәйле иҗтимагый, мәдәни, милли, дини, сәяси, әхлакый мәсьәләләрнең куелышы һәм шулар аша мәгърифәтчелек карашларын пропагандалау. Әдип үзе булган, күргән, чагыштырып бәя биргән күренешләрнең лирик–публицистик уйланулар белән кушылып килүе. Әсәрнең татар публицистикасы һәм сәяхәтнамә жанры үсешендәге урыны. З.Бигиев иҗаты турында Г.Тукай, Ф. Әмирхан, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов һ.б. |
| 2.14 | Творчество Р.Фахретдинова и Ф.Карими | Күренекле мәгърифәтче, дин галиме, тарихчы, педагог, журналист һәм әдип Ризаэддин Фәхреддиннең (1859–1936) тормышы һәм мәдәни–гыйльми эшчәнлеге. Белем–тәрбия, әхлак («Тәрбияле ава» (1898), «Тәрбияле бала» (1898), «Шәкертлек әдәбе» (1899), тарих («Болгар вә Казан төрекләре», «Алтын Урда ханнары» һ.б.) мәсьәләләренә караган һәм биобиблиографик характердагы күптомлык «Асар» («Эзләр») һ.б. хезмәтләре. Татарлар өчен китапханә һәм газета кирәклеген яклавы. Р.Фәхреддин мөхәррирлек иткән атаклы «Шура» (1908–1917) журналының татар халкы тормышындагы роле.<br>«Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898) повестенда иҗтимагый тормышның әһәмиятле мәсьәләләре күтәрелү. Татар шәкерте һәм идеаллаштырылган Сәлимә образында намуслы, дөрес яшәеш кешегә бәхет китерә дигән фикернең яклануы. Әсәрнең, синкретик характеры. Сурәтләү чаралары.<br>«Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) повестеның маҗаралы сюжеты. Конфликтның искелек–яңалык, яхшылык–явызлык каршылыгына нигез–ләнүе. Габбас хәзрәт, Гайшә абыстай, Әсма образлары. Аларның эш–гамәленнән чыга торган нәтиҗәләр. Сәлим бабай, Салих |

| | | |
|---|---|---|
| | | бай, Шәкерт (мөгаллим) кебек эпизодик образларга салынган эстетик йөкләмә. «Тәрәкъкый тормозлары»ның гамәлгә күрә җәза алуы. Күтәрелгән мәсьәләләрнең, геройлар язмышының мәгърифәтчелек идеологиясе кысаларында хәл ителүе. Р.Фәхреддин әсәрләренең философик нигезләре. «Милләт анасы» төшенчәсе һәм шул яктылыкта хатын–кыз образларының гәүдәләнеше. Язучы иҗатының әһәмияте.<br>Фатих Кәриминең (1870–1937) тормыш юлы һәм әдәби–публицистик эшчәнлеге. Әсәрләренең синкретик характеры (әдәби хикәяләү, тасвир һәм публицистик, педагогик фикерләрнең, тарихи–географик мәгълүматларның бергә үрелүе. Аның иҗатына рус һәм Аурупа әдәбияты, фәлсәфәсе йогынтысы. Оренбургта «Вакыт» газетасында мөхәррилек итүе.<br>Мәхәббәт, гаилә кору мәсьәләләрен үз эченә алган, аларны гуманистик планда һәм романтик чаралар ярдәмендә хәл иткән «Салих бабайның өйләнүе» (1897) әсәрләре. «Шәкерт илә студент» (1899), «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы» (1898), «Нуреддин хәлфә» (1900) повесть–хикәяләрендә иске тип мәдрәсәләрне, әдәпсезлек–әхлаксызлыкны, кадимчелекне тәнкыйтьләү һәм яңача укытуны, башка халыклардан үрнәк алуны, дөньяви белемне, «европача» яшәүне яклау, мәхәббәт һәм гаилә турында гуманистик идеяләр. Романтик мәхәббәтне сурәтләүгә багышлаган «Морза кызы Фатыйма» (1901) әсәре. Аның татар әдәбиятында беренче документаль–биографик повесть булуы. Әсәрләрдә чор җәмгатьчелегендә бәхәсләр уяткан «Коръән» тәгълиматын дөрес аңлау, мөселманлыкның асылы, милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге турында уйланулар. Романтик утопия жанрында язылган «Хыялмы? Хакыйкатьме?» (1908) әсәрендә мөселман бердәмлегенә бәйле И.Гаспралы фикерләренең яклануы.<br>«Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902), «Кырымга сәяхәт» (1903) әсәрләрендә мәгърифәтчелек карашлары. Әдипне борчыган мәсьәләләрнең әдәби–публицистик планда бирелүе. |
| 2.15 | Творчество З.Хади и Ш.Мухахамедова | Закир Һадиның (1863–1933) тормыш юлы һәм иҗаты. «Бәхетле кыз», «Бәхетсез кыз» хикәяләрендә тормыш–көнкүреш картиналарының реалистик планда бирелүе. «Бәхетле кыз»да хатын–кыз язмышына бәйле иске гореф–гадәтләрне, әхлаксызлыкны, надан руханиларны тәнкыйть итү. Искелек тарафдарлары булган Ибәт абызагай, Сәлим муллаларга капма–каршы рәвештә Габбас мулла һәм Гайшәнең идеаллаштырылган образларын бирү. М.Акъегетзадә идеяләре белән аваздашлык. «Бәхетсез кыз» да Хәнифә фаҗигасе сәбәпләрен ата–ана тәрбиясенә һәм руханиларның үз вазифаларын тиешенчә башкармаулары аркасында |

| | | |
|---|---|---|
| | | гаиләнә–тирәдә хөкем, сөргән начар гадәтләргә бәйле ачу. Әдипнең тәрбия һәм мәгърифәт көченә тирән ышануы. «Мәгъсүм» (1906) хикәясендә иске тип мәдрәсәләрне фаш итү. Мәгъсүмнең фаҗигале үлеменә китергән сәбәпләрне кеше һәм тирәлек мөнәсәбәтендә реалистик ачу. Әсәрдә тасвирлылык һәм психологизм. Пейзажның, әдәби һәм этнографик детальләрнең роле.<br>«Яңа әсхабе кәһәф» (1908) – кадими уку йортларына сатира. Сәфәргали, Миңлешаһ, Тимербайның язмышына, эш–гамәленә бәйле шул чор татар тормышын, яшәү рәвешен күрсәтү һәм милләт фаҗигасен аңларга омтылу. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне идеаллаштырып бирү.<br>«Җиһанша хәзрәт» (1908) повестенда З.Һадиның биографизм принцибына мөрәҗәгать итүе. «Ясаган тар юлы заманга ярашмас» булган Җиһанша ишан образы. Автор идеалы чагылышы буларак Хәсән мулла. Төп геройларның Фәхрелбәнатка мөнәсәбәттә бәяләнүе. Әсәрдә типиклаштыру алымнары.<br>Язучы әсәрләре телендә ирония һәм сарказм. З.Һади иҗатында реализм тенденцияләренең ныгуы.<br>Шакир Мөхәммәдевнең (1865–1923) тормышы, күпкырлы иҗаты. Әдип һәм журналист буларак уңышлы эшләве. Сатирик «Карчыга» (1906–1907) журналы мөхәррире.<br>«Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай» (1901) повестенда беренче тапкыр татар сәүдәгәре тормышы сүрәтләнү. Искелек, наданлык, әхлаксызлыкның нәтиҗәсен гыйбрәт буларак тасвирлау. Галиәкбәр «эшчәнлеген» фаш итүдә әдәби детальләрнең роле.<br>«Яфрак асты, яки Мәкәрҗә ярминкәсе» (1901) повестенда сәүдә буржуазиясе вәкиле булган Әхмәтсафаның банкротлыкка чыгу сәбәпләрен тормыштан артта калу белән аңлату. Фән–техника прогрессының һәм мәгърифәтле булуның яклануы. Әдипнең мәгърифәтчелек идеалын чагылдырган Гали Акчурин образы. Тормыш–көнкүреш вакыйгаларының төп идеяне ачуга хезмәт итүе.<br>«Япон сугышы, яки доброволец Батыргали агай» (1905) повестенда сатирик планда Батыргалинең «патриотизмын» ачу. Вакыйгаларның капма–каршылыкка бәйле бирелеше. Төп геройны төрле яклап характерлаганда кулланылган алымнар (үз–үзенә бәя бирү, башкаларның бәя бирүе, гадәттән тыш арттыру һ.б.). Авторның рус–япон сугышының чын асылын аңлап бетерә алмавы.<br>«Япон сугышы...» – татар прозасында беренче сатирик повесть. Татар демократик сатирасының үсешендә әсәрнең роле. Кеше образын тудыру, сюжет кору һәм әсәрләрен композицион яктан оештыруда Ш.Мөхәммәдевнең үзенчәлеге.<br>«Яңа бәдәвам китабы» исемле шигъри тупланмасы |

| | | |
|---|---|---|
| | | (1903). Шартлы сюжетка нигезләнгән «Хан кызы» (1904) әсәре. Новелла һәм кечкенә фельетоннары. Язучының теле. Әдипнең журналистик һәм публицистик эшчәнлеге. Ш.Мөхәммәдев – әдәби сатирага нигез салучыларның берсе. Иҗатының әһәмияте. |
| 2.16 | Первые образцы татарской драматургии. Творчество Г.Ильяси и Ф.Халиди | XIX йөзнең соңгы чирегендә әдәбиятта драма төре барлыкка килү. Аның шактый соңарып формалашу сәбәпләре (иҗтимагый фикернең акрын үсүе; төр үзенчәлекләренә бәйле әдипләрдән билгеле бер осталык, тәҗрибә соралу; татар театры булмау). Бу чорда драма төренең мәйдан яулый башлавына этәргеч ясаган шартлар (иҗтимагый, икътисади тормыштагы үзгәрешләр, мәгърифәтчелек хәрәкәте җәелү; әдәбияттагы эчке хасият һәм сыйфат үзгәрешләренең логик нәтиҗәсе; халык авыз иҗатына һәм җырлы–биюле уеннарга, диалог–монологларга киң урын биргән әдәби әсәрләргә таяну; Казан рус театрының уңай йогынтысы).<br>Мәгърифәтчелек хәрәкәтенең сәнгатьләр үсешендә җанлану уятуы, нәтиҗәдә өй театрлары, җәдит мәдрәсәләрендә сәхнәләр корылуы. Казан укытучылар мәктәбендә һәм «Мөхәммәдия» дә укучы яшьләрнең театрга омтылышлары. Театр эшенә әзерлек чаралары турында рус матбугаты. Касыймда һәм Бакчасарайда беренче спектакльләр уйналу. И.Кудашев–Ашказарский эшчәнлеге. Беренче ачык спектакльләр куелу: а) 1906 елның 21 апрелендә Уфада Г.Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш»ы; б) 1906 елның 5 маенда Казанда «Кызганыч бала», «Гыйшык бәласе» (Г.Камал һәм Г.Кәрәм тәрҗемәләре); в) 1906 елның 22 декабрендә шул ук пьесалар. Милли театрның драматургия үсешендәге роле.<br>Милли театр өчен пьесалар язу ихтыяҗы туу. Г.Ильяси («Бичара кыз», 1887), Ф.Халиди («Рәдде «Бичара кыз», 1888), Минһаҗеддин Әл–Казаный («Ихтыярлы кыз ихтыярсыз улмыш», 1898), Г.Камал («Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет», 1900), Г.Исхакый («Өч хатын белән тормыш», 1900), Ярулла Вәли («Оят яки Күз яше», 1902) пьесалары дөнья күрү. Төрекчәдән «Хөсет баба» (1893), «Кызганыч бала» (1900), «Гыйшык бәласе» (1902), русчадан «Комедия Чистайда» (1895), «Ревизор» (1902), «Өйләнү» (1903), «Наданлык илә галимлек» (1905) әсәрләре тәрҗемә ителү.<br>Беренче драма әсәрләрендә гаилә кору, хатын–кыз язмышы, социаль, милли тигезлек мәсьәләләренең үзәккә куелуы. Конфликтның әхлакый яссылыкта хәл ителүе. Әсәрләрнең сәнгатьлелек ягыннан йомшак булуы. Беренче татар пьесаларының үз чоры өчен әһәмияте.<br>Габдрахман Ильясиның (1856–1895) тормышы, әдәби–мәдәни эшчәнлеге. «Бичара кыз» (1887) пьесасының |

| | | |
|---|---|---|
| | | сюжеты. Яңалык һәм искелек көрәшенә нигезләнгән конфликтның әхлакый планда һәм схематик хәл ителеше. Маһитапның мәҗбүри никахтан котылып, теләгән кешесенә кияүгә чыгуы – М.Акъегетзадә карашларының яңа тормыш материалында һәм әдәби төр кысаларында чагылышы. Төп геройларның эш–хәрәкәте, характер буларак ачылу дәрәҗәсе. Хатын–кыз азатлыгы проблемасы. Маһитап образы, аның уй–кичерешләрендә ирекка, яктыга омтылу чаткылары, консерватив татар байларын, семьядагы деспотизмны күрсәтүдә Биктимер образы. Конфликтның характеры һәм чишелеш үзенчәлеге. Җантимерне комик сурәтләү. Җанбай образы. Белемле, актив шәхес концепциясе. Сюжетның схематик булуы. Каршылыкларны хәл итүдә логик эзлеклелекнең җитмәве. Образларга хас сыйфатларның автор сөйләве аша ачыклануы. Беренче драма әсәре буларак әһәмияте.<br>Фатих Халиди (1850–1923). Тормышы һәм иҗаты. Аның тәрҗемәләре («Мең дә бер кичә»,»Ләйлә вә Мәҗнүн кыйссасы», «Былбыл кошы» һ.б.) һәм календарьләре. «Рәдде «Бичара кыз» (1881) әсәрендә хатын–кыз бәхете мәсьәләсенә яхшылык һәм начарлык төшенчәсеннән чыгып якын килү. Әсәрдә шәһәр ярлылары һәм сәүдәгәрләре тормышын күрсәтүдә реализм элементлары. Бу пьесаның «Бичара кыз» әсәренә мөнәсәбәте, уртак һәм аермалы яклар. Автор идеалын гәүдәләндерү ягыннан Хәлимә образы. «Яхшыга – бәхет, яманга – җәза» концепциясе. Закир образы. Ф.Халидинең Г.Ильяси карашлары белән каршылыкка керүе. «Рәдде «Бичара кыз»ның театр тәнкыйте рәвешендә язылуы. Әсәрнең реалистик нигезе һәм уңай идеалның хыял дөньясы аша бирелүе. Хәлимә образын сурәтләгәндә, Кол Гали традицияләренә таянуы. Геройларның эш–гамәлләрен психологик нигезләүнең, мотивлашты–руның йомшак булуы. Сәнгатьчә сурәтләүдән бигрәк, хикәяләүнең өстенлек итүе. «Морад Сәлимов» (1905) драмасында мәгърифәт белән наданлык» тәрбиялелек белән әхлаксызлык каршылыгының Морад һәм Якуп бай улы Сабир эш–хәрәкәтләрендә ачылуы. Әдәпле булуны, максатка ирешүне белем нәтиҗәсе итеп аңлату. «Яманга – җәза» фикеренең яклануы. Морад Сәлимов – идеаллаштырылган образ. Әсәрдә сабырлык сыйфатының макталуы. Баланы тәрбияләүдә ата–ана роле. Кыз баланың бәхете ата–ана фатихасына бәйле булу идеясен яклау. Драманың сәнгатьчә эшләнеше. Ф.Халидинең «Саран, надан Теллә бай» (1906) пьесасында Теллә бай һәм Байтирәкнең эш–гамәлләренә бәйле наданлык, саранлык кебек сыйфатларның тәнкыйтьләнүе. Җамал ярдәмендә Теллә бай кызларының теләкләренә ирешүе. Иганәчелекнең, белемгә омтылышның яклануы. Конфликтның |

| | | |
|---|---|---|
| | | зәгыйфьлеге, бик җиңел хәл ителүе.<br>«Мәхрусә ханым» (1906) әсәрендә наданлык–әхлаксызлыкның мәгърифәткә, әдәп–әхлакка каршы куелып, конфликтның мәгърифәтчел принципларда хәл ителүе.<br>«Мең дә бер сәхәр» (1903–1904) исемле кысалы кыйссасы. Ф.Халиди иҗатының әһәмияте.<br>«Комедия Чистайда» (1895) әсәрнең рус әдәбияты үрнәгендә язылган булуы. XIX йөз ахыры мещан тормыш–көнкүреше сурәтләнү. Кызының бәхете, киләчәге турында кайгыртмыйча, аны мескен хәлдә калдырган Хәйрибикәнең сатира объекты итеп алынуы. Асрау Хөснинең башкаларга караганда акыллырак булуы. Конфликтның комедиячел характеры. Ибраһим, Әфләтун, Мәрфуга образларының берьяклы гына ачылуы. Әсәрнең теле, гуманистик асылы. Әсәрнең чагыштырмача уңышлы теле, татарларда беренче комедия буларак әһәмияте. |
| **3** | **Раздел 3. Татарская литература начала XX века** | |
| 3.1 | Татарская поэзия начала XX века | XX йөз башы татар әдәбияты курсының предметы, максат-бурычлары, хронологик чикләре. Чор әдәбиятының өйрәнелү тарихы, этаплары. Татар шигъриятенең күпгасырлык тарихы, традицияләре. Шигърияткә Г.Тукай, Н.Думави, М.Укмаси, З.Бәшири, М.Гафури кебек шагыйрьләрьнең килеп керүе. 10 елларда татар поэзиясенә шагыйрьләрнең икенче буыны килү: С.Сүнчәләй, З.Ярмәки, М.Фәйзи, Н.Исәнбәт, Ф.Бурнаш, Г.Сәмитова. Ш.Бабич, С.Сүнчәләй, М.Фәйзи, һ.б. |
| 3.2 | Творчество Габдуллы Тукая | Шагыйрь, прозаик, балалар язучысы, әдәби тәнкыйтьче, публицист, журналист, методист, җәмәгать эшлеклесе. Шагыйрь иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе. Җ.Вәлиди, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Г.Сәгъди, Я.Агишев, М.Гайнуллин, И.Нуруллин, Г.Халит, Р.Ганиева һ.б. карашлары. 1905-1907 елгы инкыйлаб елларында Тукайның шагыйрь буларак формалашуы. Журналистлык эшчәнлеге. Тукайның башлангыч чор иҗатында мәгърифәтчелек идеяләренең, үгет-нәсихәтчелекнең чагылышы, мәгърифәтчелек романтикасы өстенлек итү. Тукайга Казан әдәби мохитенең йогынтысы. «Әль-ислах», «Яшен», «Ялт-йолт», газета, сатирик журналларында эшчәнлеге. Тукай шигырьләрендәге лирик геройның рухи дөньясы катлаулану, кайгы-хәсрәт, төшенкелек, өметсезлек мотивлары килеп Шагыйрь иҗатында күзәтелгән романтизмның чыганаклары, эстетик табигате, Урта гасыр татар, рус һәм Аурупа поэзиясенең традицияләре. Тукай сатирасының иң югары ноктага күтәрелүе, идея-тематик һәм сәнгатьчелек ягыннан төрлеләнүе. Г.Тукайның дини-шәригать кануннарына, Аллага, Коръәнгә мөнәсәбәте. Тукайның һәр дәвер иҗатында |

| | | |
|---|---|---|
| | | Корън, Ислам мәдәниятеннән килгән мотивларның күзәтелүе. Тукайның татар шигъриятен реалистик юнәлештә үстерүе. Шагыйрь лирикасында төрки-татар поэзиясе, халык авыз иҗаты, рус һәм Көнбатыш Аурупа әдәбиятлары традицияләренең синтезлашуы һәм аларның милли җирлектә үстерелеше. |
| 3.3 | Творчество Мажита Гафури | Әдипнең тормыш юлы. Талантлы шагыйрь, прозаик һәм публицист. Башлангыч иҗатының тематикасы. Шигъриятендә тарихи барышка мөнәсәбәтнең, социаль мотивларның тирәнлеге, реалистик «аклылык, публицистик аһәң көчәю. М.Гафуриның оста аллегорик-мәсәлче булып танылуы. М.Гафуриның 1908-1913 нче еллар лирикасында идея-эстетик үзгәрешләр: тематик киңлек, хис-кичерешләр тирәнлеге, күңел һәм фәлсәфи лириканың  өстенлек итүе, лирик геройның күңел дөньясы романтик сурәтлелеккә төрелеп бирелү, шагыйрь поэзиясенең дидактизм, үгет-нәсихәттән арынуы. Авторның шигърияткә параллель рәвештә прозада уңышлы эшләп килүе. Милли әдәбиятка гади халык, авыл, шәһәр ярлыларының, көнлекчеләрнең авыр тормышын, ачлык темасын сурәтләүне алып килүе. М.Гафури иҗатында жанр байлыгы, тел үзенчәлеге. |
| 3.4 | Творчество Сагита Рамеева | С.Рәмиев - романтик шагыйрь, прозаик һәм драматург, публицист һәм тәнкыйтьче, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе.  Журналистлык эшчәнлеге. С.Рәмиевиең башлангыч чор иҗаты. «Таң вакыты» шигыре. Лирик геройның кайгыру, борчылу сәбәпләре, бу хәлдән чыгу юллары турындагы уйланулары. Әсәр исеменең символик мәгънәсе. С.Рәмиевнең реакция  еллары шигъриятендә ярсу йөрәкле, шашкын, бунтарь, гыйсъянчы, лирик геройның бирелеше. С.Рәмиевнең үз каләм көчен драматургия төрендә сынап каравы. «Яшә Зәбәйдә, яшим мин» пьесасы. С.Рәмиевнең унынчы елларда прозага мөрәҗәгать итүе. «Нәҗметдин агай бәйрәме», «Галәветдин хаҗи корбаны – Җаек Хәдичә» хикәяләре. Әдипнең автобиографик характердагы тәгәлләнми калган «Ул исерек түгел иде» повесте. |
| 3.5 | Творчество Дэрдменда | Талантлы шагыйрь, тыйнак һәм укымышлы зыялы, милләт хадиме. Иҗатының әдәби-эстетик юнәлеше һәм әдипнең үзенчәлекле  иҗтимагый хәле. Дәрдемәнднең татар поэзиясендә классик романтик шагыйрь буларак танылуы. 1902-1903 елларда шигырь һәм хикәя жанрында беренче тәҗрибәләр ясавы. Дәрдемәнд лирикасының төп хасиятләре: шигъри таланты, кинаяле сөйләмгә, фикри тирәнлеккә, символик сурәтлелеккә осталыгы сиземләнү. Әсәрләрендә кеше һәм вакыт, урын (пространство), дөньяның бакыйлыгы, гомернең фанилыгы (чикләнгәнлеге), гомер агышы, тәкъдир, яшәү һәм үлем турында фәлсәфи уйлануларның әдип иҗатында кызыл  җеп булып сузылуы «Кораб» шигырендә гәүдәләнеше. Шагыйрь иҗатының экзистенциализм фәлсәфәсе һәм импрессионистик стиль |

| | | |
|---|---|---|
| | | билгеләре белән бәйләнеше. Дәрдемәнднең робагый; фәрд, газәл, мәдхия, мәсәл кебек жанрларда эш итүе. Шагыйрь поэзиясендә мәгънәви тирәнлек, шигъри нәфислек, сүзләрне файдалануда үзгә осталык, кыскалык, сурәтләү чараларының муллыгы. |
| 3.6 | Творчество Нажиба Думави | Н.Думавиның катлаулы тормыш юлы. Аның лирик һәм эпик төрдәге уңышлы иҗаты. Әдәби тәнкыйть, публицистика өлкәсендәге эшчәнлеге. Н.Думави шигырьләрендә социаль контрастлар, тәнкыйди башлангычның көчәюе, чынбарлыкка мөнәсәбәтнең субъектив гәүдәләнеше күзәтелү. Шагыйрь иҗатының экспрессионистик агымга мөнәсәбәте. Н.Думавиның 10-елларда төрле фәлсәфи, мәдәни-тарихи мәктәпләргә мөрәҗәгать итүе: Көнбатыш һәм Көнчыгыш фәлсәфәсен, позитивизм философиясен өйрәнүе, аңа романтизм һәм экспрессионизм кебек әдәби юнәлешләрнең тәэсире, яшәешкә, акыл көченә шик белдерүе, рухи чистарыну кебек толстойчылык һәм руссоистик карашларны яклавы һ.б. Сугыш темасының әдип иҗатында чагылышы. «Ватан каһарманы яки агач аяк» (1916) хикәясе. «Сугыш» (1908), «Сугыш тәэссораты» (1916), «Головка» (1917) әсәрләре. Әдипнең тарихи риваять, хикәя-легендаларга нигезләнеп иҗат ителгән «Су кызы» (1915), «Болгар кызы Тойгы туташ» (1915) хикәяләре. Соңгы хикәясендә Идел буе болгарларының тормышы, гореф-гадәтләре, йолалары, уен-бәйрәмнәре җанландырылу. Н.Думавиның әдәби, фәлсәфи, гыйльми карашларын чагылдырган мәкаләләре. Аның иҗатын өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләре. |
| 3.7 | Творчество Шайхзады Бабича | Шәехзадә Бабич - талантлы шагыйрь, үткен телне публицист, оста педагог, фольклорчы. Ш.Бабичның шигъри иҗаты. Иҗатында жанрлар төрлелеге, идея-тематик киңлек Бабичның шигъриятендә сәнгатьчә фикерләүнең романтик төре өстенлек итү. Шагыйрь поэзиясендә Тукай темасының зур урын тотуы. Ш.Бабич иҗатында юмор һәм сатира, аның иҗтимагый-социаль эчтәлеге тирәнәю, максат-бурычларының киңәюе. «Кандала» (1916) поэмасының сюжеты, идея-эчтәлеге. «Газазил» (1916) әсәре. Поэманың эпик киңлеге, образларның конкретлылыгы, ирония һәм сарказмның үткенлеге, фантазиягә байлыгы. Ш.Бабичның публицистик мәкаләләре, аларда күтәрелгән проблемалар. |
| **4** | **Раздел 4. Татарская проза начала XX века** | |
| 4.1 | Творчество Гаяза Исхаки: проза, драматургия, публицистика | Яңа реалистик татар әдәбиятына нигез салучы күренекле прозаик, драматург, ялкынлы публицист, журналист, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче. Әдип иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе. «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер», «Кәләпүшче кыз», «Бай углы» әсәрләре. «Өч хатын белән тормыш» драмасы, «Ике гыйшык» пьесасы һәм «Очрашу яки Гөлгыйзар» повесте. Әсәрләренең жанр |

| | | |
|---|---|---|
| | | төрлелеге һәм сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте, жанры, сюжет-композициясе, проблематикасы, стиль үзенчәлеге. Татар халкының милләт буларак бетү, юкка чыгу куркынычы, аның сәбәпләре, милләтнең бүгенге хәле һәм киләчәге турында уйланулар. Г.Исхакыйның иҗтимагый-сәяси карашларында һәм әдәби-эстетик фикерендә чагылган борылыш. «Зиндан» повесте. «Алдым-бирдем» драмасы. «Тартышу», «Мөгаллим» драмалары. «Теләнче кыз» романы «Калош», «Фамилия сәгадәте», «Сөннәтче бабай» хикәяләрендә гаилә, кеше бәхете мәсьәләләре. «Мәдрәсә җимеше», «Шәкерт абый» кебек хикәяләрдә психологизм. «Тормышмы бу?» романы. Әсәрдә күтәрелгән проблемалар. «Мулла бабай» романы «Зөләйха» фаҗигасе «Ул икеләнә иде», «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрләрендә милләтара никахлар, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләре. «Локман Хәким», «Көз», «Өйгә» таба» һ.б. әсәрләре, аларның жанр үзенчәлекләре, идея эчтәлеге. «Дулкын эчендә» пьесасында дөнья сугышы, сыйнфый, инкыйлаби вакыйгаларның кеше язмышы, бәхете, гаилә тормышы мәсьәләләре. «Җан Баевич» комедиясендә милли мәсьәләсе. «Олуг Мөхәммәд» драмасы, аның жанр үзенчәлеге. Г.Исхакыйның татар әдәбияты тарихы һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге. Г.Исхакый һәм XX йөз татар әдәбияты. |
| 4.2 | Творчество Фатиха Амирхана: проза, драматургия, публицистика | Талантлы  әдип, тәнкыйтьче һәм публицист, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. Ф.Әмирханның тормыш юлы. Аның журналистлык эшчәнлеге. «Гарәфә кич төшемдә» хикәясе. «Бәйрәмнәр» әсәре. «Фәтхулла хәзрәт» повестенда көлү һәм фаш итү объектлары. «Хәзрәт үгетләргә килде», «Габделбасыйр гыйшкы», «Сәмигулла абзый» һ.б. хикәяләре. «Картайдым» хикәясе. Әдипнең «Урталыкта»  романы. Ф.Әмирхан иҗатында хатын-кыз темасының гәүдәләнеше: «Татар кызы» нәсере; «Хәят» повесте. «Ай өстендәге Зөһрә» кыз» романтик рухлы хикәясе. «Хәкарәт саналган мәхәббәт», «Бер харабадә», «Сүнгәч» хикәяләре. Аларның идея эчтәлеге. «Яшьләр», «Тигезсезләр» драмалары. Аларның жанр, сюжет, төзелеш үзенчәлеге. |
| 4.3 | Творчество Галимджана Ибрагимова: проза, драматургия, публицистика | Г.Ибраһимовның тормыш юлы, гаҗәеп күпкырлы эшчәнлеге турында белешмә: әдип, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, публицист һәм журналист, тарихчы һәм тел белгече, методист һәм педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче. Әдипнең иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе. Язучының 1907-1912 еллардагы әдәби эшчәнлеге. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе. «Татар хатыныниләр күрми» (вариантлары) повесте. Язучының иҗатында психологизмга, әдәби геройларның эчке дөньясын, хис-кичерешлөрен, табигать, пейзаж, хатын-кыз матурлыгын, рухи мәхәббәт темаларын сурәтләүгә игътибарның көчәюе, Гареб романтизмының әдип |

| | | |
|---|---|---|
| | | иҗатында Шәрык традицияләре белән үрелеп үсүе. «Яз башы», «Дингездә», «Сәю-сәгадәт» һ.б. хикәяләре. «Карак мулла» әсәре. «Яшь йөрәкләр» романы. Әдәби метод, әдәби юнәлеш ягыннан катлаулануы: реалистик юнәлештә үсеп китүе, реализм белән романтизмның синтезы күзәтелү, реализмның романтик алымнар, чаралар белән баетылуы. «Карт ялчы», «Көтүчеләр» хикәяләре. «Безнең көннәр» романы. Аның катлаулы сюжеты, төзелеше һәм образлар системасы. Г.Ибраһимовның тәнкыйди, гыйльми, педагогик-методик эшчәнлеге. «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә күтәрелгән мәсьәләләр. Авторның бәхәсле карашлары. |
| 4.4 | Творчество Шарифа Камала | Әдипнең тормыш юлы. «Вакыт», «Шура» газета-журналларында эшчәнлеге. «Сулган гөл», «Уяну», «Буранда», «Сукбай», «Бәхет эзләгәндә» һ.б. әсәрләре. «Бер картның тойгылары», «Нәфисә», «Эч пошулы» һ.б. инсаният идеясенең сурәтләнүе. Ш.Камал иҗатында психологизм. «Уяну», «Буранда», «Сулган гөл», «Курай тавышы», «Буранда», «Бер картның тойгылары», «Козгыннар оясында» хикәяләре. «Акчарлаклар» повесте. Аның  вакытлы эшчеләр (балыкчылар) тормышын сурәтләве. Ш.Камал иҗатында сатира һәм юмор үрнәкләре. «Сәмруг кош», «Депутат» фельетон-хикәяләре. Ш.Камалның татар драматургиясен үстерүгә керткән өлеше. «Хаҗи эфәнде өйләнә» комедиясе |
| 4.5 | Зарождение татарского театра и его влияние на развитие татарской драматургии | Татар драматургиясе тарихын чорларга бүлү мәсьәләсе: 1887-1905 еллар; 1906-1911 еллар; 1912-1917 еллар. Яшь көчләр килүе. Драматургиянең тарихи темаларга мөрәҗәгать итүе, идея эчтәлеге баеуы, жанрлар системасы төрләләнүе.<br>Милли профессиональ театр барлыкка килү һәм  татар драматургиясенең, тагын да ныгып, яңа баскычка күтәрелеше, бу уңайдан рус һәм Гареб драматурглары иҗатына мөрәҗәгать итү.<br>“Сәйяр”, “Нур” театрларының барлыкка килүе. |
| 4.6 | Творчество Галиасгара Камала | Г.Камал - реалистик татар драматургиясенә нигез салучы, хикәяче һәм шигырьләр авторы, тәнкыйтьче, публицист, журналист, тәрҗемәче, рәссам, театр эшлеклесе. Камалны  драматургиягә алып килгән алшартлар. Драматургның әдәби иҗаттагы беренче тәҗрибәләре «Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет» пьесалары һәм «Сабир хәзрәт» хикәясе. Г.Камалның әдәби һәм журналистлык эшчәнлеге «Уйнаш» драмасы. «Беренче театр» комедиясе. Әсәрнең төп һәм ярдәмче конфликтлары. «Бүләк өчен», «Банкрот»  комедияләре. «Өйләнәм... ник өйләндем» трагикомедиясе. Г.Камал драма һәм комедияләренең бай сәхнә тарихы. Аның әдәби тәнкыйди  эшчәнлеге |
| 4.7 | Творчество Гафура Кулахметова | Тормыш юлы. Аның   инкыйлаби эшчәнлеге, марксистик тәгълиматны  өйрәнүе. Милли телдә марксистик әдәбият, инкыйлаби матбугат тудыруда аның  роле, Аның милли театрны оештыруга, үстерүгә керткән |

| | | |
|---|---|---|
| | | өлеше, педагогик эшчәнлеге. Г.Коләхмәтовның әдәби мирасы. Аның проза һәм драма төрләрендә эшләве, әсәрләрендә пролетариат әдәбиятының нигезе салыну. «Ике фикер» фәлсәфи драмасы. Пьесада күтәрелгән мәсьәләләр. «Яшь гомер» драмасы. Аның конфликты. Әдипнең эпик әсәрләре. «Уалган мол» нәсере. «Ник уйгандым» хикәясе. Хикәянең дини-мифологик сюжетка корылуы. |
| 4.8 | Творчество Мирхайдара Файзи | Татар әдәбияты тарихында драматург буларак танылуы, шигырь һәм хикәя жанрларында да мирас калдыруы. Аның тормыш сукмаклары. Татар драматургиясе өлкәсендә, беренче тәҗрибәләре: «Татар туе», «Ике Хәсән» пьесалары. Беренче шигырьләре. «Минем шигырьләрем», «Яшь күңел» шигырь китаплары. Шагыйрь поэзиясендә романтик иҗат принциплары. М.Фәйзинең драматургия төрендәге эшчәнлеге. «Яшьләр алдатмыйлар» водевиле. «Кызганыч» романтик драмасы. «Тәкъдирнең шаяруы», «Авыл бәйрәме» пьесасы. «Галиябану» музыкаль драмасы. Пьесаның жанр үзенчәлеге, сюжеты, композиция бөтенлеге, камиллеге. Драманың образлар системасы: Драманың сәнгатьчә эшләнеше. |
| **5** | **Раздел 4. Татарская литература 20-х годов (1917-1929 гг.)** | |
| 5.1 | Творчество Мажита Гафури | Башкортостанның халык шагыйре, татар һәм башкорт әдәбияты классигы буларак М.Гафури.<br>М.Гафуриның шигырьләрендә көн темаларына мөрәҗәгать итүе. «Бетсен империалистлар сугышы», «Икмәк», «Хөрриятькә каршы торучыларга», «Аждаһа» кебек шигырьләрендә Вакытлы хөкүмәтне, аның халыкка каршы политикасын фаш итүе. Изүчеләрне халык хөкеменә тарту пафосы белән сугарылган «Хисап көне», «Бай абзый» шигырьләре.<br>М.Гафуриның идея-эстетик үсешен күрсәтү ягыннан «Эшче» поэмасының беренче һәм икенче вариантлары. Татар опера сәнгатенә нигез салудагы роле.<br>М.Гафури – прозаик. Нигездә реализмга өстенлек бирүе. «Кара йөзләр» повесте. Әсәрнең төп проблемасы. Галимә образының типиклыгы, халыкчан характеры. Әсәрдә дини фанатизм белән аек акылның конфликтка керүе. Сәнгатьчә эшләнештә психологизмны оста файдалану. Персонажларның һәм хикәяләүченең индивидуаль теле. Әсәрнең тәнкыйди рухы.<br>«Тәрҗемәи хәлем», «Шагыйрьнең алтын приискасында» повестьларында яшь кеше образлары. Капиталистик чынбарлыкта түбән катлау яшьләренең авыр хәлен күрсәтеп бирү. Эшчеләр белән прииска хуҗаларын капма-каршы итеп сурәтләү.<br>«Тормыш баскычлары» повесте. Вахит Җәгъфәровның революцион чынбарлыкта актив көрәшче булып җитешүе. Нури Сәгыйтов, Ефимов, Нәгыйм Әминев образлары. Уңай образларны сурәтләүдәге җитешсезлекләр. Мәхмүт образы, аның типиклыгы. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Хезмәт ияләренең авыр тормышын дөрес күрсәтү. М.Гафуриның публицистикасы. М.Гафури иҗаты турындагы фәнни әдәбиятка күзәтү. |
| 5.2 | Литературная и общественная деятельность Галимджана Ибрагимова | Г.Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлы. Г.Ибраһимовның совет чоры әдәбияты үсешенә ясаган тәэсире. «Кызыл чәчәкләр» повесте. Социаль чыгыш һәм революциягә мөнәсәбәт мәсьәләсенең образларда дөрес ачылуы. Шаһбаз, Солтан, Гыйлаҗи образларына каршы куелган Фазыйл белән Гали. Кызыл чәчәк образының символик булуы. Әсәр тукымасының халык авыз иҗатына якын яклары. Дуслык, намуслы хезмәт белән тормышны матурлау идеяләре.<br>«Тирән тамырлар» романы. Сыйнфый көрәшнең яңа формалары. Фәхри һәм Вәли Хәсәнов образы. Кеше концепциясенең яңаруы. Шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәте. Сюжет-композиция үзенчәлекләре. Символик образларның роле.<br>“Алмачуар” хикәясе. Кеше һәм табигать мөнәсәбәте, әхлакый мәсьәләләрне күтәрүе. “Адәмнәр” повесте натуралистик сурәтләрдә ачлык фаҗигасын тасвирлау.<br>Г.Ибраһимовның язучы буларак осталыгын күрсәткән «Казакъ кызы» романы. Тормыш материалының яңалыгы. Тугандаш казакъ халкының тарихи үткәнен реаль итеп сурәтләү. Карлыгач-Сылу, Арсланбай образларының реальлеге һәм романтиклыгы.<br>Г.Ибраһимов – татар әдәбияты классигы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе. Февраль һәм Октябрь инкыйлабларыннан соңгы иҗтимагый эшчәнлеге. “Яңа кешеләр” пьесасы. Сыйнфый көрәш һәм яңа хакимияткә мөнәсәбәт.<br>Г.Ибраһимовның язучы, галим булып җитлегүендә башка халыклар әдәбияты, фәне, мәдәнияте тәэсире. |
| 5.3 | Творчество Хади Такташа | Иҗатының беренче чорына (1916-1922) хас үзенчәлекләр. Җәмгыятьтәге явызлыкны, рәхимсезлекне ләгънәтләү, аларга каршы чыгу протестының абстрактлыгы. Романтик сурәтләү, бунтарьлык рухы өстенлек итү. Дини-мифологик, символик образларның үзәктә торуы һәм шулар аша җир тормышын, яшәү мәгънәсен аңларга омтылу («Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр», «Янар таулар», «Җир уллары трагедиясе»). Мәхәббәттә янучы лирик герой («Урман кызы», «Таң кызы», «Зәңгәр күзләр»). Гомумкешелек кыйммәтләрен яклавы, фәлсәфи эчтәлек («Мәңгелек әкият»).<br>Иҗатының икенче чорына (1923-1931) хас үзенчәлекләр. Реалистик сурәтләү өстенлек итү. Гыйсъянчы лирик герой («Такташ үлде», «Син дә үл инде», «Әйдә, энем»). Чынбарлыкка, яңа җәмгыятькә бәя, мөнәсәбәт бирелү («Болай... гади җыр гына», «Ак чәчәкләр», «Мокамай»). Объектив һәм субъектив эчтәлек, форма яңалыгы, |

| | | |
|---|---|---|
| | | иҗтимагый тормыштагы социаль-психологик каршылыклар («Киләчәккә хатлар», «Бүгенге матурлык»). Яшьлек, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләренә мөрәҗәгать итү («Алсу», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Югалган матурлык»). Халыкчанлык, тел бизәкләре байлыгы, юмор («Нәни разбойник»). Еш кына романтизм белән реализм үрелеп килү; сөйләм шигыренең уңышлы формаларын табуы.<br>Һ.Такташ иҗатының новаторлыгы.<br>Һ.Такташ – драматург һәм прозаик. «Күмелгән кораллар», «Камил», «Югалган матурлык» драмалары. «Таң җиле» романының язылган кадәресе. “Караборынның дусты”, “Кияү” хикәяләре. Әсәрләренең проблематикасы.<br>Хәзерге татар совет шигъриятенә Һ.Такташ иҗат мәктәбенең тәэсире. |
| 5.4 | Творчество Карима Тинчурина | К.Тинчурин иҗатының үзенчәлеге, характерлар тудырудагы, сюжет корудагы аермалы яклары. К.Тинчуринның «Мәрҗәннәр» китабы, әсәрдә авторның прозаик буларак ачылуы. Драматургиядә К.Тинчурин тудырган традицияләр, аларның башка авторлар тарафыннан үстерелүе.<br>Музыкаль драма жанры үсешенә зур өлеш кертүе («Зәңгәр щәл», «Сүнгән йолдызлар», «Ил»). Иҗат үзенчәлекләре: беренче иҗат тәҗрибәләрен «Сәйяр» труппасында артист булып эшләгәндә ясый: «Хәләл кәсеп», «Беренче чәчәкләр», «Назлы кияү», «Соңгы сәлам» һ. б.; |
| 5.5 | Творчество Фатхи Бурнаша | Ф.Бурнашның романтик поэзиясе. Героик-патриотик поэзияне үстерүдә Ф.Бурнаш иҗаты. Аның әсәрләренең романтик характеры, халык иҗатына якынлыгы. Ф.Бурнашның революцион матбугаттагы эшчәнлеге. “Чәчәктән һәйкәл”, “Гөлчәчәк”, “Сахра каны”, “Ак каен”, “Әҗәл” поэмалары. Шигырьләре. “Таһир-Зөһрә” трагедиясе һәм “Яшь йөрәкләр” драмасының Ф.Бурнашны талантлы драматург итеп танытуы. Ф.Бурнашның шигърияттә сатирик юнәлешне үстерүгә керткән өлеше. |
| 5.6 | Творчество Махмута Галяу | М.Галәүнең тормыш юлы. Вакытлы матбугатта актив катнашуы. Тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге. Дәреслекләр төзүдә, уку-укыту кулланмалары язуда, аң-белем таратуда катнашуы. М.Галәүнең хикәяләре, драма әсәрләре. «Канлы тамгалар» эпопеясы. Әсәрнең беренче һәм икенче кисәкләре – «Болганчык еллар» («Ил тыныч чакта»), «Мөһаҗирләр» (Ил өреккәндә») романнары. Аларның темалары, күтәргән проблемалары, сурәтләнгән образлар.<br>М.Галәү иҗаты турында фәнни хезмәтләр. |

| 6 | **Раздел 5. Татарская литература 30-х годов (1930-1941 гг.)** | |
|---|---|---|
| 6.1 | Творчество Шарифа Камала и Тази Гиззат | Шәриф Камалның тормыш һәм иҗат юлы. Ш.Камал – прозаик. «Матур туганда» романы. Ш.Камалның публицистикасы, аның актуальлеге<br>Ш.Камал – татар әдәбияты классигы, татар совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе булуы. Язучының башлангыч чор иҗатында идея-эстетик эволюциясе. Ш.Камал – прозаик. «Матур туганда» романы.<br>Драматургның тормыш юлы. «Тәрҗемәи хәлем», «Мин ничек артист һәм драматург булдым» исемле язмалары. Т.Гыйззәтнең драматург буларак үсеш этаплары, аның иҗатындагы төп темалар.<br>1917 елга кадәрге татар авылы, андагы стихияле ңәм оешкан сыйнфый көрәшне тасвирлау. Тарихи-революцион драмалары: «Наемщик», «Чаткылар», «Ялкын», «Ташкыннар», «Бишбүләк» һ.б. Тулаем алганда бу әсәрләрдә татар крестьяны үткән юлның тарихи эзлеклелектә бирелүе. |
| 6.2 | Творчество Кави Назми и Гаделя Кутуя | Язучының тормышы һәм иҗаты. К.Нәҗминең иҗтимагый эшчәнлеге. Яңа әдәби юнәлешләр белән кызыксынуы. «Чыныгу» (1923), «Иң соңгысы» (1924), «Шобага» (1925), «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» (1926), «Таштугайга кайтмыйбыз!» (1928) кебек хикәяләре һәм аеруча хезмәт ияләренең революция, гражданнар сугышы аша социализмга килүен, яңа тормыш төзи башлавын реалистик картиналар һәм образлар аша сурәтләгән «Яр буенда учаклар» (1928), «Якты сукмак» (1929), «Кояшлы яңгыр» (1930) повестьлары. Бөек Ватан сугышы елларында К. Нәҗми. Әдип совет кешеләренең тылдагы һәм фронттагы батырлыгын, ватандарлык хисләрен әдәби образларда чагылдырган «Хәят апа» (1941), «Сагыну хаты» (1942), «Снайпер Мәрдән» (1943), «Фәридә» (1943-1944) кебек поэмаларын һәм күп санлы патриотик шигырьләре. «Язгы җилләр» исемле тарихи-революцион романы.<br>Утызынчы еллардагы идея-эстетик үсеше, шуның күрсәткече буларак, «Җавап», «Шатлык җыры» пьесалары. Әдипнең барлык жанрлар өлкәсендә дә актив эшләве. Шигырь (“Иртәнге уйлар” һ.б.), поэма (“Талантлар ватаны” һ.б.), повесть (“Тапшырылмаган хатлар”, нәсер (“Без – сталинградчылар” һ.б.) очерк (“Берлин юлында очрашу”), тәрҗемә (Лермонтовның “Маскарад”ы, Маяковскийның “Сул марш”ы һ.б.), «Солтанның бер көне», «Нишләргә?», «Вөҗдан газабы» хикәяләре, аларда сурәтләнгән интеллигенция вәкилләре образлары. «Тапшырылмаган хатлар» повесте. |
| 6.3 | Татарская литература периода Великой отечественной войны | Бөек Ватан сугышы елларында татар әдәбияты. Чор һәм әдәбият. Аңа хас үзенчәлекләр. Әдәбиятның агитатор һәм пропагандист вазифаларын үти башлавы: төп |

| | | |
|---|---|---|
| | (1941-1945 гг.) | максат-бурычы: халыкны изге көрәшкә чакыру, бердәмлеккә өндәү, җиңүгә ышаныч тәрбиләү, фашизмга нәфрәт хисе уяту һ.б. Татар язучыларының күпчелеге фронтка китүе; 30 дан артыгы сугыш кырында яисә дошман әсирлегендә һәлак булуы (М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, К.Басыйров, М.Гаяз, Р. Ильяс, Х.Мөҗәй, Д.Фәтхи һ.б.). 1942 елдан башлап төрле фронтларда 16 исемдә татарча газета чыгуы. Аларда Г.Кутуй, А.Шамов, Ә.Ерикәй, Р.Ишморат, Г.Әпсәләмов, И.Гази, Ш.Маннур, Ә.Фәйзи, Ш.Мөдәррис, М.Хөсәен һ.б. әдипләрнең журналист булып хезмәт итүе. ВКП(б) ҮКның 1944 ел 9 август карары нигезендә татар әдәбиятында һәм сәнгатендә тарихи темаларны яктыртуга зур киртә куелуы. Сугыш чоры таләпләренә иң тиз яраклашучы төрнең лирика булуы, төп мотивлар. Әдәбиятның агитатор һәм пропагандист вазифаларын үти башлавы: төп максат-бурычы: халыкны изге көрәшкә чакыру, бердәмлеккә өндәү, җиңүгә ышаныч тәрбиләү, фашизмга нәфрәт хисе уяту һ.б. Татар язучыларының күпчелеге фронтка китүе; 30 дан артыгы сугыш кырында яисә дошман әсирлегендә һәлак булуы (М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, К.Басыйров, М.Гаяз, Р. Ильяс, Х.Мөҗәй, Д.Фәтхи һ.б.).1942 елдан башлап төрле фронтларда 16 исемдә татарча газета чыгуы. Аларда Г.Кутуй, А.Шамов, Ә.Ерикәй, Р.Ишморат, Г.Әпсәләмов, И.Гази, Ш.Маннур, Ә.Фәйзи, Ш.Мөдәррис, М.Хөсәен һ.б. әдипләрнең журналист булып хезмәт итүе. ВКП(б) ҮКның 1944 ел 9 август карары нигезендә татар әдәбиятында һәм сәнгатендә тарихи темаларны яктыртуга зур киртә куелуы.<br>Сугыш чоры таләпләренә иң тиз яраклашучы төрнең лирика булуы, төп мотивлар Поэзиядә жанрлар торышы. Традицияләрне баетырга омтылу. Бу өлкәдәге бәхәсләр. Прозада хикәя, очерк, повесть кебек жанрлар алгы планга чыгуы. Прозада жанр төрлелеге. Хикәя (Г.Әпсәләмов. Ватан улы. Үлемнән көчлерәк; Ә.Еники. Бала. Ана һәм кыз; И.Гази. Алар өчәү иде). Повесть (Ф.Кәрим. Язгы төндә. Разведчик язмалары). Маҗаралы повесть (Г.Кутуй. Рөстәм маҗаралары). Нәсер (Г.Кутуй. Сагыну. Без – сталинградчылар). Фронт көндәлеге (Х.Мөҗәй. Сугышчы язмалары). Драматургиядә халык героизмын, патриотизмын, партизаннар хәрәкәтен чагылдырган драмалар дөнья күрү (М. Әмир. Партизан Иван; Т.Гыйззәт. Төнге сигнал; Н.Исәнбәт. Мәрьям). Халыкның тылдагы фидакарь хезмәтен сүрәтләү (Р.Ишморат. Кайту; М.Әмир. Гөлҗамал. Миңлекамал). Тарих һәм заман темасына бәйле олы шәхесләрнең мәһабәт образлары тудырылу (Н.Исәнбәт. М.Вахитов; М.Гали, Х.Уразиков. К.Насыйри). |
| 6.4 | Творчество Мусы | Иҗатының башлангыч чорында әсәрләрендә күтәрелгән |

| | | |
|---|---|---|
| | Джалиля | проблемалар. Азат тормышка, хезмәткә дан җырлау, яңа әхлакны яклау, яшьләрне социалистик төзелешкә рухландыру. Кызыл Армияне данлау, иске тормышны фаш итү. “Барабыз” (1925), “Иптәшкә” (1929) җыентыклары.<br>“Бәхет”, “Үткән юллар”, “Кызыл каһарман”, “Сугышта” һ.б. әсәрләрендә яшәү һәм көрәш мәгънәсе турында уйланулар. Егерменче елларда шагыйрьнең эзләнүләре, иҗат кыенлыклары. Аның поэзиягә алып килгән яңалыгы, шигъри осталыгы камилләшүе. “Орденлы миллионнар”, “Шигырьләр һәм поэмалар”, “Шигырьләр” җыентыклары. Егерменче-утызынчы еллар яшьләренең героик-романтик рухын чагылдырган әсәрләре: “Походка”, “Батыр егет турында җыр”, “Унсигез”, “Сәрби әби”, “Күк юрга”, “Комсомолларга”, “Яшьләр”, “Урожай”, “Походка”, “Арыш кырында”, “Яшьлек”, “Колхоз кызына”, “Зәйнәп”.<br>“Хат ташучы” поэмасының темасы һәм идеясе. Сәнгатьчә эшләнеше. Тимербулат һәм Фәйрүзә образлары, әсәрнең идеясен ачуда аларның әһәмияте. Поэмада халыкчан традицияләренең оста файдаланылуы.<br>Халык-ара тормышка, дөнья эшче сыйныфы бердәмлегенә багышлап язылган “Парчалар”, “Еларгамы-көләргәме”, “Джем” әсәрләре.<br>М.Җәлилнең татар опера театрын оештыруда күрсәткән хезмәтләре. “Алтынчәч”, “Илдар” либреттолары. “Алтынчәч” героик-романтик драмасының идея-эстетик кыйммәте. Әсәрнең сәхнә тарихы.<br>М.Җәлилнең әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышлап язган мәкаләләре.<br>Бөек Ватан сугышы елларында М.Җәлилнең көрәше һәм иҗаты. “Тупчы анты” (1942) җыентыгына кергән әсәрләренең төп пафосы, сәнгатьлелек дәрәҗәсе, актуальлеге. М.Җәлил – хәрби корреспондент, сугышчы, шагыйрь.<br>М.Җәлилнең әсирлек шартларындагы шигъри һәм гражданлык батырлыгы. “Моабит дәфтәре” җыентыгы. Шигырьләрендә патриот шагыйрьнең лирик образы. Әсәрләрдәге конфликт, аларның кискенлеге. Биредә тупланган әсәрләрнең темасы – коммунист шагыйрьнең туган илгә, халыкка биргән антына тугрылыгын, рухи көчен күрсәтү. “Җырларым”, “Ышанма”, “Кичер, илем”, “Кошчык”, “Ирек” әсәрләрендә кичерешләр, коммунистик идеялелеген күрсәтүдә “Егет көче”, “Үлемгә”, “Катыйльгә” һ.б. әсәрләре. “Ана бәйрәме”, “Сандугач һәм чишмә” балладаларының идея-эстетик көче. Аллегорик образлар тудыруда М.Җәлилнең новаторлыгы. Лирик герой уйларындагы фәлсәфи тирәнлек.<br>Фашизмның ерткыч асылын, кешелек дошманы булуын аяусыз фаш итүдә “Бүреләр”, “Вәхшәт”, “Сакчы” һ.б. |

| | | |
|---|---|---|
| | | әсәрләре. Совет солдатының гуманизм һәм фашистларның кабахәтлеген ачуда шагыйрь кулланган контрастлык чаралары. “Моабит дәфтәре”ндә интернационализм идеясе. Шагыйрьнең киләчәккә ышаныч белән каравын белдергән “Сугыштан соң”, “Төзүче”, “Яңа ел теләкләре”, “Шатлыкны каршылап” шигырьләре. Юмористик шигырьләре: “Хәдичә”, “Томаулы гыйшык”, “Гашыйк һәм сыер”, “Табут”, “тозлы балык”, “Борча” һ.б.<br>“Моабит дәфтәре”нең совет һәм дөнья әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше. Муса Җәлил иҗаты турында илебез һәм чит ил язучылары, галимнәре. |
| 6.5 | Творчество Фатиха Карима | 20 нче еллар уртасында шигърияткә килеп, яңа тормышка, яшьләргә, хезмәткә дан җырлавы; комсомол рухы алып килүе. Төрле вакыйгаларга мөнәсәбәтен шигырь аша белдерүе, укучыга ниндидер хәбәр җиткерү формасында язуы. Көрәш дәрте белән мавыгу, декоратив сөйләүгә, коры риторикага, яңа формалар белән мавыгуга китерүе; образлылык кимүе, сүрәт чаралары ярлылануы («Безнең һәйкәл», «Закон). 30 нчы елларда шигъри осталыгы, әдәби зәвыгы үсүе, киңәю; шигыръләрендә лирик җылылык, мөләемлык, табигыйлек артуы («Зәйтүнә», «Беренче бала», «Кемгә сөйлим серләремне»). Бу чор иҗатының төп тема-мотивлары: социалистик хезмәт, бәхетле киләчәк, совет кешесенең гуманистик сыйфатлары («Җиденче мич», «Тавышлы таң»); илне саклау («Чайка башыңны», «Пулеметчы», «Аникин»). Тоткынлык чоры иҗаты (1938-1941). Әсәрләрендә тоткынлыкның ачы газабы, рәнҗетелү хисләре өстенлек итү («Я көн генә була, я төн генә...»). Шигырьләренең төп мотивлары: лирик геройның борчылуы, сыкрануы ңәм якыннарын, туган җирен сагыну хисләре («Ант», «Көзге яңгырлы төн»). Лирик геройның, ялгыз калып, хатыны,балалары турында уйлануы («Кадрия», «Сагынып кайтам сине»). Символик образларга, чагыштыру, арттыру, антитеза һ.б. алымнарга иркен мөрәҗәгать итүе («Кыр казы»). Сугыш чоры иҗаты (1941-1945). Җиңүгә тирән ышаныч белән илен сакларга ант итү («Ант»). Лирик геройның рухи дөньясы баю, ул кешелекле, нык ихтыярлы («Теләк», «Иптәш»). Яшәү һәм үлем турында фәлсәфи уйлануы («Сөйләр сүзләр бик күп алар...»). Фашизмга нәфрәт, ләгънәт яңгырау («Бездә яздыр»). Тыл тормышы, фронт һәм тыл бердәмлеге («Сагынып көтәм», «Газиз әнкәй»). Поэма һәм баллада жанрларында иҗаты иң югары ноктага җитү («Гөлсем», «Идел егете», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Үлем уены», «Партизан хатыны», «Өмет йолдызы», «Тимер һәм тимерче». Прозада һәм драматургиядә сугыш афәтен, совет солдатының батырлыгын күрсәтү («Язгы төндә», «Разведчик язмалары» повестьлары, «Шакир |

| | | |
|---|---|---|
| | | Шигаев» пьесасы). |
| **7** | **Раздел 6. Татарская литература 40-65-х годов XX века** | |
| 7.1 | Поэзия 40-65-х годов | Сугыштан соңгы әдәбият (1945-1965).<br>Тыныч хезмәткә күчүнең беренче елларында әдәбият алдында торган яңа бурычлар. Татарстан язучыларының икенче (1950) һәм өченче (1954) съездларының әдәби хәрәкәттәге әһәмияте.<br>Тоталитар җәмгыятьнең катгый сәяси катып калган таләпләре өстенлек иткән шартларда әдәбият үсешендәге кыенлыклар. Әдәбият, сәнгатьтә «космополитик» күренешләрен гаепләү. «Конфликтсызлык» теориясе. Уңай герой, заман темасы. Шәхескә табыну күренешләренең әдәбият үсешенә тискәре йогынтысы. Әсәрләрдә тема ярлылыгы. Күп яктан чикләнгән, кыен шартларда татар әдәбияты ирешкән кайбер уңышлар. Прозада «Тукай» (Ә.Фәйзи), «Намус» (Г.Бәширов), «Рәхмәт, иптәшләр» (Ә.Еники) кебек уңышлы әсәрләрнең дөнья күрүе.<br>Илленче еллар уртасында шәхескә табыну күренешләрен фаш итү. Моның әдәбият үсешенә уңай йогынтысы. Әдәбиятның катгый, катып калган таләпләр чикләреннән котыла башлавы. 50 нче еллар уртасында М.Җәлил һәм репрессияләнгән әдипләрнең (Г.Ибраһимов, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Ш.Усманов, Ф.Сәйфи-Казанлы, Х.Туфан, С.Рәфыйков һ.б.) иҗаты халыкка кайту.<br>Әдәби тормышта дискуссия һәм бәхәсләрнең, ачыктан-ачык сөйләшү рухының көчәюе.<br>Әдәби тәнкыйтьтә кимчелекләрне кыю ачкан мәкаләләр күренә башлау.<br>Поэзиянең әдәби төрләре. Күңел лирикасы (Ә.Фәйзи. Ач тәрәзәң; С.Хәким. Көткән идем; Ш.Галиев. Әткәйгә хат). Пейзаж лирикасы (Х.Туфан. Гүзәл). Публицистик лирика (Х.Туфан. Тугызынчы дулкын. Ә җир барыбер әйләнә. Туган тел). Фәлсәфи лирика (Ә.Давыдов. Фәлсәфә. Чорлар чатында; Х.Туфан. Һиндстанны эзлим. Сөйли торган материя). Сатирик лирика (Г.Афзал. Тәвәккәл әби. Сәләхетдин абзый сөйли; Ә.Фәйзи. Улым үземә охшаган. Тәнкыйтьче мәхәббәте). Баллада (С.Хәким. Сары капкалы йорт). Поэма (С.Хәким. Дала җыры. Курск дугасы. бакчачылар; Ш.Маннур. Казан кызы; Г. Хуҗи. Гражданин, солдат, шагыйрь; Ә.Давыдов. Ташу; З.Нури. Дан юлы). Шигъри повесть (С.Баттал. Олы юл буйлап; Ш.Маннур. Җир-әнкәнең сылу кызы). Сатирик мәсәл (Ә.Исхак. Аю Яңа урында. Мәче һәм рәсем. Попугай-лектор). Поэзиядә сатира һәм юмор. Декларативлыкка, схематизмга, шаблонлыкка каршы көрәш. Поэтик жанрлар һәм аларның үсешендәге яңалыклар. Традицияләр һәм новаторлык мәсьәләре. |
| 7.2 | Проза 40-65-х годов | Татар прозасында үзгәртеп кору процессын чагылдырган әсәрләрнең дөнья күрә башлавы. А.Гыйләҗев, М.Хәсәнов, М.Мәһдиев, һ.б. язучыларның яңа роман һәм |

| | | |
|---|---|---|
| | | повестьлары, драмалары һәм поэмалары. М.Хәсәновның «Язгы аҗаган» романында сурәтләнгән образлар. Темалар һәм жанр ягыннан төрлелеге.Фронттагы һәм тылдагы батырлык (Г.Әпсәләмов. Газинур; Г.Бәширов. Намус; М.Әмир. Саф күңел). Дошман әсирлегендәге хәлләрне, фаҗигале язмышларны сурәтләү (Н.Дәүли. Яшәү белән үлем арасында; Г.Әпсәләмов. Мәңгелек кеше). Тыныч тормышны сурәтләүдә заман рухының тирәнәюе (Ә.Еники. Саз чәчәге. Рәшә; Ф.Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы; И.Гази. Гади кешеләр). Тарихка мөрәҗәгать итү (К.Нәҗми. Язгы җилләр; И.Гази. Онытылмас еллар; Ә.Фәйзи. Тукай). Хикәя (Ә.Еники. Кем җырлады?; А.Шамов. Миңнур карт). Повесть (Г.Әпсәләмов. Ак төннәр; Н.Дәүли. Яшәү белән үлем арасында; Ә.Еники. Саз чәчәге). Роман (Г.Әпсәләмов. Газинур. Алтын йолдыз; Г.Бәширов. Намус). Тарихи роман (К.Нәҗми. Язгы җилләр; И.Гази.Онытылмас еллар). Тарихи-биографик роман (Ә.Фәйзи. Тукай). Роман һәм повесть өлкәсендә эзләнүләрнең көчәюе. Прозада сюжет-композиция, тел-сурәт өлкәләрендә эзләнүләр. Иҗат көчләре мәсьәләләре. Үсеш проблемалары.<br>Үзгәртеп корының драматургиядә зур җанлану тудыруы. Тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть, ачыктан-ачык сөйләшү рухының әдәби хәрәкәткә үтеп керүе. Язучыларның иҗтимагый-политик тормышта актив катнашулары. Язучылар күтәргән актуаль мәсьәләләр буенча дәүләт күләмендә әһәмиятле карарлар кабул ителү. Героик һәм тарихи-революцион тема. |
| 7.3 | Драматургия 40-65-х годов XX века | Драматургиядә замандаш герой проблемасы. Драматургларның индивидуаль стильләре камилләшү. “Муса” (Н.Исәнбәт); “Давылга табан”, “Үлмәс җыр” (Р.Ишморат); Шамил Усманов, А.Яхин, А.Гыйләҗев пьесалары. |
| **8** | **Раздел 8. Татарская литература 65-85-х годов XX века** | |
| 8.1 | Поэзия 65-85-х годов XX века | 1965-85 еллар әдәбияты. Идеологик басымның кимүе. Чынбарлыкны күпъяклы һәм дөреслек белән сурәтләү тенденциясенең көчәя баруы. Эпик колач киңәю. Прозаның төп темалары. Тарихи темаларны яктырту. Традицион авыл темасын сурәтләү үзенчәлекләре. Ватан сугышы темасын яктыртудагы яңалыклар. Заман темасын яктыртуда яңалыклар. (Г.Ахунов, Н.Фәттах, Ф.Хөсни, Ә.Еники, М.Мәһдиев, Р.Төхвәтуллин һ.б.). «Хрущев җепшеклеге» исеме белән тарихка кергән хәбәрдарлык, демократия күренешләренең 60 нчы еллар әдәбият-сәнгатенә уңай йогынты ясавы; идеологик басымның бераз кимүе, әмма тиздән партия йогынтысы яшәешнең бөтен өлкәләренә үтеп керүе; ил тормышында торгынлык чоры башланауы.<br>Милләтләр дуслыгы, интернационализм идеяләре җирлегендә совет халкы формалашуы; рус теленең зур |

| | | |
|---|---|---|
| | | тизлек белән башка телләрне аралашудан кысрыклап чыгаруы.<br>Талантлы каләм ияләренең, хакимият идеологиясен читләтеп үтеп, әдәбиятының эстетик асылына мөрәҗәгать итүе, халыкның гасырлар дәвамында тупланып килгән әхлакый кыйммәтләрен яклап чыгуы һәм сәнгати югары әсәрләр иҗат итүе (Ә.Еники.Әйтелмәгән васыять. Туган туфрак; А.Гыйләҗев. Өч аршын җир. Җомга көн кич белән; Т.Миңнуллин. Әлдермештән Әлмәндәр һ.б.<br>Әсәрләрендә социалистик җәмгыятенең чын асылы ачылуы, эзоп теле белән тәнкыйть ителүе; кеше һәм система каршылыгы әдәби чаралар ярдәмендә тасвирлануы (А.Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә; Ә.Баянов. Тау ягы повесте һ.б.). С.Хәким, Т.Миңнуллин Россия Дәүләт бүләгенә лаек булулары; иң уңышлы әсәрләре рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителүе.<br>Поэзиядә уйланучан башлангычның көчәюе, лирик каһарманның рухи дөньясы катлаулануы, зиһен һәм фикер эшчәнлеген тулырак ачарга омтылыш.<br>Замандашыбызның рухи тәҗрибәсен тулырак ачкан олы образын тудыруда төп юнәлешләр, идея-тематик үзгәрешләр. Кеше шәхесенә игътибар арту. Лирик агымның көчәюе. Өлкән буын шагыйрьләренең иҗат активлыгы үсүе (Х.Туфан, С.Хәким, Ш.Маннур, М.Садрый, З.Нури, Н.Арсланов һ.б).<br>Ә.Давыдов һәм З.Маннур иҗаты. Тарихи-революцион тематика һәм поэтик М.Ногман поэмалары. И.Юзиев, Ш.Галиев, Х.Камал, Г.Афзал поэзияләренең үзенчәлекләре. Поэзия өлкәсендә эзләнүләр. Яңа буын шагыйрьләрнең әдәбиятка килүе (Ә.Баянов, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалимов, Р.Гатауллин).<br>Җыр һәм романслар (С.Хәким, Н.Арсланов, М.Ногман, Г.Зәйнәшева, Л.Айтуганов, Р.Әхмәтҗанов, М.Әгъләмов).<br>Поэзиядә сатира һәм юмор. Декларативлыкка, схематизмга, шаблонлыкка каршы көрәш. Поэтик жанрлар ңәм аларның үсешендәге яңалыклар.<br>Традицияләр һәм новаторлык мәсьәләре.<br>Лиро-эпик жанрның үсеш-үзгәреш кичерүе.<br>Баллада (Зөлфәт. Ике ат турында баллада. Фатыйма. Кара күбәләк; М.Галиев. Чишмә караучы карт; И.Юзеев. Унөченче; Р.Әхмәтҗанов. Таш елады). Эпик поэма (С.Хәким. Кырыгынчы бүлмә; И.Юзеев. Әнкәй. Өчәү чыктык ерак юлга; Ә.Баян. Сәяхәтнамә; М.Әгъләмов. Тукайдан хатлар). Шигъри роман (С.Баттал.Чирмешән якларында; Ә. Давыдов. Йокысыз төннән соң). Оратория (Р.Харис. Кеше). Либретто (Г.Рәхим. Каһәрләнгән мәхәббәт).<br>Табигый хис-тойгылар чагылыш тапкан лирик шигырьләр, көйгә салынып, киң яңгыраш алган җырлар булып китүе (С.Хәким. Башка берни дә кирәкми; Ш.Галиев. Раушанием, бәгърем; И.Юзеев. Яшь |

| | | |
|---|---|---|
| | | наратлар. Мәтрүшкәләр; Г.Зәйнашева. Китмә, сандугач; Р.Фәйзуллин. Аккошлар; Р.Вәлиев. Зинһар өчен кермә төшләремә һ.б.).<br>Г.Афзалның тормыш һәм иҗат юлы.<br>Г.Афзалның шигъри таланты. Шагыйрь поэзиясендә табигать культы ("Бу кырларда", "Апрель җиле!, "Кышкы урман" һ.б.).<br>Сюжетлы шигырьләрендә комик типлар тудыру осталыгы ("Сәләхетдин бабай сүзләре", "Сабирҗан хаты", "Шәрифулла күршем белән").<br>Сатирик поэзиянең төрле формаларына, жанрларына мөрәҗәгать итүе: фельетон, памфлет, мәсәл, җыр, эпиграмма, диалог, монолог һ.б.<br>Г.Афзал сатирасының төп үзенчәлеге булып халык иҗаты традицияләренең, чичәнлек рухының көчле булуы.<br>И.Юзеев иҗаты. Шагыйрьнең рус ("Последнее испытание", "Маленький рыжий кони") һәм башкорт ("Язылмаган поэма") телләренә тәрҗемә ителгән китаплары. Башлангыч чор иҗатында (шигырьләренең ритмикасында, сөйләм интонациясендә, лирик чигенешләрдә, композиция төзелешендә) Такташ йогынтысы. Шул җирлектә поэзиянең иң күркәм романтик һәм реалистик традицияләрен дәвам итүе. Поэмаларда уңышлы эшләве. И.Юзеев иҗатында лиро-эпик жанр, үсеш-үзгәреш кичереп, эпик вакыйгаларны кичерешләр байлыгы аша сурәтләү мөмкинлеге артуы сизелә. Тематик киңлек күзәтелү.<br>Поэмаларда стилистик төрлелек. Сюжетка корылган ("Фәрит-Фәридә"); лирик монолог ("Тормыш җиңә"); драматик легенда ("Соңгы сынау"); шигырь, дастан, парча, лирик чигенү, балладалар циклы ("Мәхәббәт китабы"); документальлек ("Таш диварлар авазы").<br>И.Юзеев драматургиясендә лирик агымның, романтик пафосның көчле булуы, җыр, музыка белән үрелеп килүе. Жанрлар төрлелеге: "Резидәкәй" (музыкальпьеса), "Сандугачлар килгән безгә" (драма), "Командировка" (моңсу комедия), "Очты дөнья читлегеннән", "Соңгы төн" (тарихи-революцион трагедия) һ.б.<br>И.Юзеев – комедияләр остасы ("Мәкәрҗәгә барган идек", "Кайтмый калсам – көтәрсеңме?" һ.б.).<br>Р.Фәйзуллин иҗаты. Кыска шигырьләр язу, "сүз белән рәсем ясау" осталыгы. Аларга тирән мәгънә, фәлсәфи эчтәлек салып халыкны тапкырлык, зирәклек юнәлешендә тәрбияләү һәм кыска үткен форманы үстерүдә уңышлары. Дөнья поэзиясендәге барлык төшенчәләрнең – намус, тугрылык, дуслык-туганлык, рух азатлыгы, бәйсезлек, коммунарлар, Буратино, ырымнар, Аллага табыну, иман ныклыгы, палач балталары, лазерлар, тәхетләр, хөкемдарлар, яшәү-сәгадәт, өмет-ышанычлар – барысының да поэмаларда |

| | | |
|---|---|---|
| | | урын алуы.<br>Р.Фәйзуллинның җыр жанрында, публицистикада, балалар әдәбиятында нәтиҗәле эшләве. Кол Гали, Тукай, Кутуй, Туфан иҗатына багышланып язылган монографик характерда хезмәтләре.<br>Поэмаларның жанр төрлелеге: "Көрәшчеләр" (фәлсәфи), "Сәйдәш" (шигъри повесть). Әдәби – публицистик мәкаләләре, иҗат портретлары. |
| 8.2 | Проза 65-85-х годов XX века | Чынбарлыкны күпъяклы һәм дөреслек белән сурәтләү тенденциясенең көчәя баруы. Эпик колач киңәю. Прозаның төп темалары. Тарихи темаларны яктырту. И.Газиның «Онытылмас еллар», Ф.Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романнарында халык тормышын яктыртудагы яңалыклар. Татар халкының үткәнендәге иҗтимагый-рухи тормышын һәм үсешен яктыртуда Н.Фәттахның «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар»; Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәрләре. Үткәндәге бөек тарихи шәхесләрне гәүдәләндерүдә А.Расихның «Ямашев»; Г.Шәрипованың «Гафур гаиләсе»; Ж.Тәрҗемәновның «Көмеш дага» романнары. Традицион авыл темасын сурәтләү үзенчәлекләре. Ф.Хөснинең «Утызынчы ел», Р.Рафиковның «Беренче яз», М.Хәсәновның «Язгы аҗаган» романнарында авылны коллективлаштыру проблемасы гәүдәләнеше. Кеше язмышына игьтибар арту. «Язгы авазлар» (А.Расих), «Йолдызым» (Р.Төхватуллин), «Яшьлегемне эзлим» (Ә.Баянов), «Берәү», «Күпер чыкканда» (В. Нуруллин), әсәрләрендә сугыштан соңгы авылның үсеш кыенлыклары. Шул елларда яшь кеше үсеше, формалашуы «Без 1941 ел балалары», «Фронтовиклар» (М.Мәһдиев), «Шинельсез солдатлар» (В.Нуруллин), «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турындагы хикәят» (А.Гыйләҗев) әсәрләрендә чагылу. Фәнни-техник революция һәм хәзерге авыл проблемаларының әдәбиятта гәүдәләнеше (Г.Бәширов «Җидегән чишмә»; Ә.Еники «Әйтелмәгән васыять»; М.Хәбибуллин «Чоңгыллар»; Х.Хәйруллин «Канатлар талмасын»).<br>Ватан сугышы темасын яктыртудагы яңалыклар. Г.Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше»; Ш.Маннурның «Муса»; Н.Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында»; Х.Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр»; М.Юнысның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна»; Ш.Рәкыйповның «Кайдан син Җан?», «Кызлар-йолдызлар» әсәрләре.<br>Заман темасын яктыртуда яңалыклар.<br>Эшчеләр темасын яктырту. «Сүнмәс утлар» (Г.Әпсәләмов), «Хәзинә», «Хуҗалар», (Г.Ахунов), «Тын елга буенда» (С.Рафиков), «Зәй энҗелре» (А. Гыйләҗев), «Ут һәм су» (Ә.Баянов, «Каты токым» ( Ш. Бикчурин) әсәрләре. Мораль – әхлак проблемаларына игътибар |

| | | |
|---|---|---|
| | | арту. Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» повесте, А.Расихның «Сынау» романы. Интеллигенция тормышын яктыртуда үзенчәлекләр (А.Расих «Ике буйдак»; Г.Әпсәләмов «Ак чәчәкләр», «Яшел яр»; А.Гыйләҗев «Урамнар артында яшел болын»). Роман һәм повесть өлкәсендә көчәюе. Прозада сюжет-композиция, тел-сурәт өлкәләрендә эзләнүләр. Иҗат көчләре мәсьәләре. Үсеш проблемалары. Тематик киңлек күзәтелүе. Татар халкының үткән тарихын, иҗтимагый-рухи тормышын аңларга омтылу (Н.Фәттах. Әтил суы ака торур. Сызгыра торган уклар; М.Хәбибуллин. Кубрат хан һ.б.).<br>Совет хакимиятенең төрле чорларында татар авылы кешеләрен сурәтләү, аларның яшәү рәвеше (Ф.Хөсни. Утызынчы ел; А.Гыйләҗев. Язгы кәрваннар; Г.Ахунов. Чикләвек төше; М.Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары. Кеше китә – җыры кала).<br>Бөек Ватан сугышы елларының каршылыкларын, фаҗигале вакыйга-хәлләрен яңа чор биеклегеннән бәяләү (Х.Камалов. Һәркемнең гомере бер генә; Ш.Рәкыйпов. Кайдан син, Жан? Кызлар-йолдызлар; М.Юныс. Шәмдәлләрдә генә утлар яна һ.б.)<br>Эшчеләр тормышы, производство мәсьәләләре (Г.Ахунов. Хәинә. Хуҗалар; А.Гыйләҗев. Зәй энҗеләре; Ә.Баянов. Ут һәм су).<br>Халкыбызга хас гадәт-йолаларның кимүе, әдип-әхлакның бозылуы өчен борчылу (Ә.Еники. Әйтелмәгән васыять; Х.Сарьян. Бер ананың биш улы; А.Расих. Сагыну; А.Гыйләҗев.Җомга көн кич белән һ.б.).<br>Фән кешеләре, зыялылар тормышын рухи-психологик планда ачу (А.Расих. Ике буйдак; Г.Әпсәләмов. Ак чәчәкләр. Яшел яр; А.Гыйләҗев. Урамнар артында яшел болын. Урталыкта һ.б.). |
| 8.3 | Драматургия 65-85-х годов XX века | Драматургиядә замандаш герой проблемасы.<br>Хәзерге драма иҗаты үсешендәге мөһим тенденцияләр, сыйфатлар. Мораль башлангычның көчәюе, сюжетта гаделлеккә омтылу, конфликтларның әхлакый планга корылу, фикер тыгызлыгы һәм үткенлеге, интеллектуальлек өстенлек алу.<br>Р.Ишморат («Яңа бистәдә»), Г.Насрый («Кадерле минутлар»), Н.Исәнбәт («Гүзәл») һ.б. драматурглар иҗатында кешеләр арасындагы яңа мөнәсәбәтләр проблемасы. Кеше психологиясен ачуның яңа чараларын эзләү. Ф.Хөсни һәм М.Әмир драмалары. Героик һәм тарихи-революцион тема. «Муса» (Н. Исәнбәт), «Давылга таба», «Үлмәс җыр» (Р.Ишморат), «Шамил Усманов» (А.Яхин, А.Гыйләҗев) пьесалары.<br>Драматургларның индивидуаль стильләре камилләшү.<br>Х.Вахит драматургиясенең төп сыйфатлары. «Беренче мәхәббәт», «Соңгы хат», «Туй алдыннан» әсәрләрендә яшьләр һәм әхлах проблемалары. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Ш.Хөсәеновның драма иҗатында чынбарлыкны сурәтләү үзенчәлекләре. «Зөбәйдә–адәм баласы», «Әни килде» әсәләренең художество эшләнеше.<br>Әдәби төрләр, жанрлар, жанр формалары үсеше.<br>Бу чор сәхнә әдәбиятында чын мәгънәсендә халыкчан образ-характерлар, замандаш сыйфатларын үзләрен туплаган типлар мәйданга чыгуы (Ш.Хөсәеновның «Әни килде» әсәрендә Ана, Т.Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәрендә Мәдинә, «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә Әлмәндәр, И.Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» әсәрендә Хәмзин һ.б.).<br>Х.Вахит – шагыйрь: «Безнең авыл», «Якты юллар», «Яз килә» җыентыклары. Либреттолар авторы: «Самат», «Дим буенда», «Җиһангир». Х.Вахит – үзенчәлекле драматург: «Беренче мәхәббәт», «Рәхим итегез», «Илһамия», «Карлыгач канат җәя», «Соңгы хат», «Туй алдыннан»,» «Мәхәббәтең чын булса», «Оныта алмасаң нишләрсең» һ.б. Драматургның сюжет төзү остасы булып танылуы, аның нигезен тәшкил иткән конфликт тормышчанлыгы, әхлакый һәм фәлсәфи киңлеге белән аерылып торуы. Җыр-музыка пьесаларының лейтмотивына әйләнүе. Тәрбия, әхлак мәсьәләләре, матур рухи башлангычларны яклавы, тормыштагы ямьсез күренешләрне, кешеләрдәге һәртөрле кимчелекләрне тәнкыйтьләве. Яшьлек темасы, яшь геройларның зур тормышка килү юлы, характеры формалашу шартлары, хезмәткә, мәхәббәткә, дуслыкка мөнәсәбәтләре кызыксындыруы. Художестволы форма һәм стиль өлкәсендәге эзләнүләр. Романтик сурәтлелек, музыкальлек, тамашалыкны яңа баскычка күтәреп, күпсанлы әдәбият-сәнгать сөючеләрне театр белән кызыксынуга этәрүе. |
| 8.4 | Пути и основные тенденции развития татарской литературы конца XX века | Сәнгатьнең бер тере буларак гасыр кичеше әдәбияты. Яшәешнең, дөньяның һәрвакыт үзгәрештә булуы, чорның әдәбият үсешенә, иҗат кешеләренең рухи-фикри эзләнүләренә тәэсир иткән соңгы ике дистә ел эчендәге әһәмиятле вакыйгалары. XX-XX1 гасыр цивилизациясе һәм мәдәнияте контекстында хәзерге татар әдәбияты. |
| 8.5 | Татарская поэзия в контексте общественно-исторических реалий | Җәмгыятьтә яңа иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр. Әдәбиятыбыздагы “ак тап”лар. Татар әдбәбият беле галимнәренең эшчәнлеге (И. Нуруллин, Ф.Хатипов, Ф Мусин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Сверигин, Ф.Галимуллин, Г. Гыйльман, М Вәлиев). |
| 8.6 | Новые направления в татарской прозе конца XX века | XX гасыр ахыры татар прозасы: стиль тенденцияләре, жанрлар төрлелеге: реалистик, романтик юнәлешләр, интеллектуаль тенденция, экзистенциаль фикерләү төре, неомифологизм. |
| 8.7 | Драматургия и театр конца XX века | Гасыр ахыры татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре. Т.Миңнуллин, З.Хәким, Аманулла, И.Зәйниев, Д.Салихов, Р.Зәйдулла иҗаты. |
| **9** | **Раздел 9. Современная татарская литература** | |

| | | |
|---|---|---|
| 9.1 | Современные тенденции развития татарской поэзии | Хәзерге татар поэзиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре, алшартлары. Хәзерге татар поэзиясендә реалистик юнәлеш.<br>Хәзерге татар поэзиясендә романтик юнәлеш. Соңгы еллар татар поэзиясендә интеллектуаль тенденция, модерн алымнар. Р.Харис иҗаты (1943). З.Мансуров иҗаты (1949). Р.Зәйдулла иҗаты. Яңа буын шагыйрьләр иҗаты. |
| 9.2 | Разнообразие литературных направлений и течений в татарской прозе | М.Кәбиров әсәрләрендә постмодернистик алымнар. Хәзерге татар прозасында интеллектуаль тенденция. (М.Кәбировның “Сары йортлар сере” повесте).<br>Хәзерге татар прозасында концептуализм күренеше (Г.Гыйльманның “Оча торган кешеләр” әсәре мисалында).<br>Хәзерге татар прозасында мифологик катламның вазифасы. (Н.Гыймадинова повестьлары). XXI йөз башы татар прозасында реалистик роман жанры. (З.Хәкимнең Бөек Ватан сугышы елларында совет коллаборационизмы темасына караган “Легионер” романында экзистенциаль мотив). |
| 9.3 | Основные тенденции и закономерности развития татарской драматургии | Хәзерге татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре. Т.Миңнуллин, З.Хәким, Аманулла, И.Зәйниев, Д.Салихов, Р.Зәйдулла иҗаты. “Яңа татар пьесасы” конкурсының татар драматургия үсешенә йогынтысы. Татар театрлары, аларның репертуары. Театраль фестивальләр. |

Курс практических/семинарских занятий

| № | Наименование раздела / темы дисциплины | Содержание |
|---|---|---|
| **1** | **Раздел 1. Древняя и средневековая татарская литература** | |
| 1.1 | Древнетюркская литература | Гомумтөрки (борынгы төрки) әдәбият. Борынгы төркиләр. Аларда язу барлыкка килү мәсьәләсе. Туран (һун), рун һәм уйгур графикалары.<br>Барлык төрки халыкларның уртак мирасы дип каралган «Орхон – Енисей» язмалары. Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет–төрк» (1073–1074) китабы. Йосыф Хас Хаҗиб Баласагуниның 1069–1070 елларда язылган «Котадгу белег» дидактик поэмасы. Әхмәд Йүгнәки (XII йөз). Аның дидактик характердагы «Һибәтел–хакаик» («Хаклыклар бүләге») поэмасы. Әхмәд Ясәви (1166 елда үлә) һәм Сөләйман Бакырганый (вафаты 1186 елда) – төрки суфыйчылык шигъриятенең күренекле вәкилләре. |
| 1.2 | Литература булгарского периода (X – середина XIII века) | Болгар–хәзәр чоры. Кол Гали һәм аның “Кыйссаи Йосыф” дастаны. Болгар мифологиясе һәм халык авыз иҗаты үрнәкләре: риваять–легендалар, мәкаль–әйтемнәр, җырлар. Болгарның борынгы Русь белән мөнәсәбәтләренә бәйләнешле риваятьләр. Болгар чоры |

| | | |
|---|---|---|
| | | язма әдәбиятының мәшһүр шагыйре Кол Гали һәм аның «халыкка җан азыгы булган кыйммәтле әдәби җәүһәре «Кыйссаи Йосыф» дастаны (поэмасы). |
| 1.3 | Литература периода Золотой Орды (с середины XIII века до середины XV века) | Алтын Урда чорында әдәбият. Суфыйчылык әдәбияты. Алтын Урда дәүләте чорында кыпчак һәм угыз, болгар телләре нигезендә уртак тел оеша башлау, язма әдәбият вәкилләренең төрле төрки төбәкләрдән чыгуы. Иҗат ияләренең башлыча гарәп һәм фарсы телле Көнчыгыш классикларына йөз тотуы. Котб, Харәзми, Сәйф Сараи кебек шагыйрьләрнең Хәйям, Фирдәүси, Әбүгалисина, Низами, Сәгъдиләрдән килә торган дөньяви мотивларны үстерүе. Мәхмүд бине Гали Әл–Болгари, Хисам Кятиб кебек язучыларның Газзали, Фәридеддин Гаттар иҗатыннан килгән суфичылык традицияләренә иярүләре. Суфичылык һәм аны  барлыкка китергән сәбәпләр. XlV нче йөзләрдә Идел–Урал буе төрки–татар әдәбиятында дини–мистик рухлы агымның көчәюе, моның социаль–тарихи сәбәпләре, идея–эстетик чыганаклары, «Диване Хикмәт», «Бакырган  китабы» дигән җыентыклар, «Кисекбаш», «Кыйссаи Сәкам», «Нәсыйхәт–әс–салихин» кебек дини–дидактик, дини–суфичыл, дини–каһарманлык   дастаннары барлыкка килү, аларда ислам диненең бөеклеген исбатларга омтылу.<br>Рабгузыйның “Кыйссасел–әнбия” китабы.  Котб “Хөсрәү вә Ширин” әсәре. Дастанның саклану һәм өйрәнелү тарихы, хәзергә кадәрге басмалары. Котб дастанының язылу урыны һәм шартлары. «Хөсрәү вә Ширин» дастанының сюжеты, композицион төзелеше, образлар системасы. Поэманың оптимистик рухы. Шагыйрьнең поэтик осталыгы. Харәзми “Мәхәббәтнамә” поэмасы. Поэманың язылу һәм саклану тарихы, кулъязма нөсхәләре. Әсәрнең сюжет үзенчәлеге, композицион төзелеше. Мәхмүд Болгари (Мәхмүд бине Гали) “Нәһҗел–фәрадис” әсәре. Әсәр күчермәләренең табылган урыннары, фәнни яктан өйрәнелү тарихы. Авторның кайсы төбәктән чыккан булуы, әсәрнең язылу вакыты һәм урыны. Идел–Урал буе төрки әдәбиятында хикәячелек жанрын үстерүдә «Нәһҗел–фәрадис» әсәренең урыны һәм роле, аның традицияләре. Хисам Кятиб “Җөмҗөмә солтан” дастаны. Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (1370) әсәренең язылу урыны һәм шагыйрь биографиясенең ачык булмавы. Дастан күчермәләренең таралу төбәкләре, басма нөсхәләре турында мәгълүмат. Әсәрнең шигъри төзелеше, поэтик нәфисләү чаралары, тасвир алымнарында халык эпосы традицияләре: сыйфатны сан зурлыгы (күләм) белән ачарга омтылу, шигырьдә мәкаль һәм әйтемнәрне иркен куллану. Сәйф Сараи “Гөлестан бит–төрки” әсәре “Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастаны. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (1394 ел) поэмасы. Әсәр сюжетының реаль җирлеге булу ихтималы, авторның |

| | | |
|---|---|---|
| | | «чынлык» тенденциясен алга сөрүе. Шагыйрь мирасының әһәмияте. Сайядинең «Дастан Бабахан» әсәренең таралу даирәсе, саклану һәм өйрәнелү тарихы. «Дастан Бабахан»ның татар әдәбияты үсешенә зур йогынты ясавы. Сайяди дастанының композициясе, сюжеты, образлар системасы, әдәби эшләнеше. |
| 1.4 | Литература периода Казанского ханства | Казан ханлыгы чоры татар әдәбияты. Мөстәкыйль дәүләт буларак, Казан ханлыгының барлыкка килүе. Казан шәһәре һәм казанлылар турында тарихи чыганаклар, риваятьләр, легендалар. Җирле халыклардан җырчы–чичәннәр, музыкантлар, рәссамнар, төрле әдип–шагыйрьләр һәм галимнәр үсеп чыгуы. (Гарифбәк, Колшәриф, Мөхәммәдшәриф, Касыйм, Нух, Мөхәммәдьяр). Көнчыгыш белән бәйләнештә Казанның роле. Бу чорда башка төбәкләрдәге төрки телле әсәрләрнең Идел–Урал буенда киң таралыш табуы (азәрбайҗан, үзбәк, госманлы, төркмән әдип һәм шагыйрьләреннән Әхмәди, Мир Хәйдәр, Дүрбәк, Лотфи, Мөхәммәд Чәләби, Вафи, Физули һәм Нәваи әсәрләре). Госманлылар, комыклар, татарлар һәм башкортлар үз шагыйре итеп санаган Өмми Камал (чын исеме Исмәгыйль) әсәрләренең Идел–Урал буенда яратып укылуы. Аның әсәрләренең идея–эстетик асылы, Казан татар әдәбиятына тәэсире. Мөхәммәдьяр “Нәсыйхәт” әсәре, “Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” поэмалары. Мөхәммәдьяр әсәрләренең табылу һәм саклану тарихы. Аның иҗатын өйрәнүче әдип һәм галимнәрнең эшчәнлеге (И.Березин, М.Иванов, Н.Исәнбәт, Ш.Абилов, Х.Миңнегулов һ.б.). Шагыйрь шәхесе турында мәгълүмат.Татар поэзиясен үстерүдә Мөхәммәдьяр иҗатының роле. Кадыйр Галибәк “Җәмигъ эт–тәварих” җыентыгы. Кадыйр Галибәкнең «Җәмигъ эт–тәварих» (1602) әсәре. Аның тәрҗемә әсәре булуы һәм оригинальлеге мәсьәләсе. Бу әсәрне өйрәнүгә өлеш керткән хәзерге галимнәрнең эшчәнлеге турында мәгълүмат. «Җәмигъ эт–тәварих»ның башка төрки халыклар культурасына мөнсәбәте. Әсәрдә гомумватанчылык идеясе; Борис Годуновка мәдхия җырлау; рус монархиясе кулы астында үзәкләшкән феодаль дәүләтне яклау. |
| 1.5 | Татарская литература XVII-XVIII веков | XVII йөз татар әдәбияты. Мәүлә Колый иҗаты. XVI йөзнең ахырында һәм XVII йөздә татар халкының иҗтимагый–сәяси хәле һәм мәдәнияте. Суфичылык идеяләренең яңадан җанлануы, моның сәбәпләре. Мәүла Колый әсәрләренең саклану тарихы, кульъязма нөсхәләрнең таралуы һәм аларны фәнни өйрәнүгә өлеш керткән әдип–галимнәрнең эшчәнлеге (Фазыл Туйкә, Г.Сәгъди, Г.Ибраһимов, Х.Хисмәтуллин, Х.Госман, К.Дәүләтшин, Г.Хөсәенов һ.б.). Мәүла Колый хикмәтләренең тематикасы, каршылыклы идея–эстетк табигате. Мәүла Колый хикмәтләренең лирик герое. |

| | | |
|---|---|---|
| | | 1990 елларда табылган ике поэмасы: «Берекәннәр сыйфаты» һәм «Хәләл ризык эстәгәннәр сыйфаты». Аларның идея–эстетик үзенчәлеге. XVIII йөздә татар халкының иҗтимагый тормышы. Халык тормышы һәм көнкүрешнең авыз иҗаты әсәрләрендә чагылышы: «Лашманчы зары» һәм «Лашман бәете», «Солдат бәете», «Никрутлар бәете», «Пугачев бәете», «Салават Юлай» һәм «Салават бәете». Елъязмалар тибындагы әсәрләр, сәяхәтнамәләр, васыятьнамәләр; «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе», «Мөхәммәд Әмин сәяхәтнамәсе»; Гаделшаһ бине Габдулла һәм Габдерахман бине Туймөхәммәд васыятьнамәләре; Аксак Тимернең Болгар шәһәрен җимерүе турындагы елъязмалар, Акай кузгалышы һәм Пугачев сугышы, Екатерина II нең Казанга килүе турында язмалар. Мөхәммәдрәхим бине Рәфыйк Казани тарафыннан төзелгән һәм күчереп язылган «Мәҗмугыл–хикәят» җыентыгы. Таҗетдин Ялчыгол (1768–1838). Тормыш юлы, иҗат мирасы, күпкырлы эшчәнлеге (педагог, текстолог, тарихчы, рухани, табиб һ.б.). Әдипнең Суфый Аллаяр иҗат иткән «Сөбател гаҗизин» китабын «Рисаләи Газизә» исеме белән шәрехләве (1806). XVIII гасырда татар прозасының тематикасы киңәюе һәм форма ягыннан төрләнүе. Габдрәхим Утыз Имәни иҗаты. Габдрәхим Утыз Имәнинең (Габдрәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырым әл–Болгари) – XVIII–XIX гасыр чикләрендә иҗат иткән күренекле шагыйрь, энциклопедик белемле галим һәм җәмәгать эшлеклесе булуы. Аның тормыш юлы, иҗат мирасы турында мәгълүмат. Шагыйрьнең иҗатын өйрәнүгә өлеш керткән әдип–галимнәрнең эшчәнлеге. Аның шигъри әсәрләрендә фикер азатлыгы, гыйльми–мәгърифәт мәсьәләләре. Мәсәлән: «Тәхфәт–ел–гьөрабаә вә ләтаиф–ел–гьәзае» (Горбәтлектә йөрүчеләргә бүләк һәм аларның хурлыкка калу вакыйгалары). «Горбәтнамә» (Читтә йөрүче хикәясе). «Гавариф–эз–заман» (Замана бүләкләре), «Тәнәиһ–ел–әфкяр фи Нәсаих–ел–әхйар» (Фикерләрне пакъләндерүче файдалы киңәшләр», «Мөһиммәт–эз–заман» (Заманның мөһим билгеләре) әсәрләренең идея–проблематик тирәнлеге. Аерым шигырьләренең үзәгенә авторның үз шәхесе, үз тормышы, үзе кичергән вакыйгалар килеп керүе; үзенчәлекле лирик герой гәүдәләнеше. Утыз Имәни иҗатына Габдулла Тукай мөнәсәбәте. Шагыйрь Габдрәхим Утыз Имәнигә багышланган хезмәтләр. |
| **2** | **Раздел 2. Татарская литература XIX в.** | |
| 2.1 | Татарская литература первой половины XIX в. | Россиядә феодаль – крепостнойлык тәртипләренең таркала баруы һәм капиталистик мөнәсәбәтләр үсеше. Татар халкының аңына, иҗтимагый фикер һәм культура үсешенә уңай йогынты ясаган факторлар, тарихи вакыйгалар. 1812 елгы Ватан сугышында һәм |

| | | |
|---|---|---|
| | | декабристлар восстаниесендә татарларның катнашуы. Аларның җыр– бәетләрдә һәм язма әдәбиятта чагылышы.<br>Казанда университет ачылу (1804), аның Идел һәм Урал буе халыклары, шул исәптән татарларның иҗтимагый–мәдәни үсешенә йогынтысы. Халкыбызның тарихын, этнографиясен, халык иҗаты әсәрләрен җыю, туплау һәм фәнни эшкәртүдә шәркыять галимнәренең роле (К.А.Фукс, А.К.Казембек, Х.Д.Френ, И.Н.Березин, Н.Ашмарин, Н.Катанов һ.б.). 1800 елда Казанда «Азия» типографиясе ачылу. Татар телендә китаплар басыла башлау.<br>Петербург һәм Казан университетларында, хәрби һәм махсус училиәеларда татар телен укыту. Татар теленең рәсми статусы киңәю. Университет галимнәре Ибраһим Хәлфин (1778–1829) һәм Гали Мәхмүдов (2824–1891) эшчәнлеге. Татар халкы арасында мәгърифәт тарату планнары. Әдәби телне гади халык теленә якынайту мәсьәләсе куелу. Әдәбият сөючеләр җитәкчесе Нигъмәт Ибраһимов.<br>Мәгърифәтчелек әдәбияты формалашу юлында яңа бер баскыч буларак беренче хрестоматияләр төзелү. Мартиниан Иванов һәм аның «Татар хрестоматиясе» (1842, 1856). Хрестоматиядә халык иҗаты. Язма әдәбият үрнәкләре, рус әдәбиятыннан беренче тәрҗемәләр – И.И.Хемницер, И.И.Дмитриев, И.А.Крылов мәсәлләре, В.И.Панаевның «Иван Костин» повесте. Салихҗан Кукляшев һәм аның «Диване хикәяте татар» җыентыгы (1859). Хрестоматиядә фольклор һәм язма әдәбият үрнәкләре.<br>Иҗтимагый–фәлсәфи фикернең акрын үсүе (самодержавие изүе, крепостной тәртипләр саклану; милли изү һәм чукындыру–христианлаштыру сәясәте Һ.б.). Халыкның рухи тормышында ислам диненең тоткан урыны (милләтне берләштерердәй бердәнбер идеология; милли изүгә каршы торырдай көч; халыкның яшәү рәвеше, гореф–гадәтләрнең дини карашлар белән бәйле булуы). Алдынгы карашлы шәхесләрнең консерватизмны, дини схоластиканы тәнкыйтьләп, мәгърифәткә, тәрәккыяткә өндәве. Шундыйларның берсе буларак, Г.Курсавиның (1776–1812) тәкълидне кире кагып, акылга ирек таләп иткән фикерләре. Тасаувыфка (суфыйчылыкка) каршылыклы мөнәсәбәте. «Иҗтиһад мөнкариз»не кире кагуы. Мәгърифәтне яклавы.<br>Абызагайлар хәрәкәте, аның асылы һәм шул чор әдәбиятында чагылышы.<br>XIX йөз башында культура һәм фикер өлкәсендә бер–берсенә капма–каршы ике юнәлеш. Акылга ирек таләп итү һәм мәгърифәтчелек омтылышлары.<br>Әдәбиятның халык авыз иҗаты һәм үзеннән алдагы әдәби традицияләргә таянып үсүе. Заман таләбе буларак, |

| | | |
|---|---|---|
| | | реалистик башлангычның торган саен киңрәк җәелүе. Әсәрләрнең, нигездә, шигъри характерда булуы. Шәрык әдәбияты йогынтысы. Фольклорга тартым, мавыктыргыч сюжетлы дастаннар, кыйссалар. «Кыйссаи Там», «Әбугалисина кыйссасы»(1836) һ.б. Гасыр урталарында басылып киң таралган проза үрнәкләреннән әкият тибындагы дөньяви әсәрләр. «Мәликә китабы»(1846). «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз...» дигән әсәр (1857). Белем һәм һөнәрле булу идеяләре. «Ләтаифе Хуҗа Насретдин» китабы (1845). Халыкчан юмор, патша, түрә, байлардан көлү, көр күңеллелек. Әдәбиятта дөньяви мотивларның ныгый баруы, публицистик башлангычның көчәюе (Г.Утыз Имәни Һ.б.).<br>Патша чиновникларын, түрә–морзаларны, сорыкорт муллаларны сатирик сурәтләү алымнары («Мүкән кантун», «Кәҗә бәете», «Биккенә шәкерт хикәяте», Г.Кандалыйның «Мулла белән абыстай» шигыре һ.б.). Крестьян тормышына, социаль тигесезлеккә, хатын–кыз хәленә игътибар. «Илаһи бәет, Удельный» әсәрендә мөһим темалар. Әдәбиятның тормышны реалистик танып белү функциясе активлашу. |
| 2.2 | Татарская поэзия первой половины XIX в. | Әдәбиятның, нигездә, шигъри характерда үсеше һәм аның төп юнәлешләре: а) дини–әхлакый; б) суфыйчыл; в) дөньяви. Аларың еш кына үзара керешен китүе. Поэзиядә публицистик яңгырашның көчәюе (Г.Утыз Имәни «Гавариф–әз–заман»). Чорга хас социаль вакыйгаларның киңрәк урын алуы («Иляһи бәетләр»). Әхлаксыз, надан дин әһелләрен, залим түрәләрне сатирик фаш иткән әсәрләр язылу («Мүкән кантун», Г.Кандалый «Тотынышып кулың кулга»). Крестьянның авыр тормышына, социаль тигезсезлеккә, хатын–кыз язмышына игътибар арту («Илаһи бәет. Уделный», Г.Кандалый «Сәхибҗәмал»). Фольклорга тартым мавыктыргыч дастан–кыйссаларның активлашуы («Бүз егет», «Тутыйнамә»).<br>Либераль аристократия карашларын чагылдыручы әсәрләр (Гомәр Мөхәммәд улының «Тәзкирәи мөфти Габдессәлам» (1832), «Сәфәрнамәи шаһзадә Александр» (1837) поэмалары).<br>Бу чор әдәбиятында жанр төрлелеге (мәдхия, мәрсия, мөнәҗәт, шигъри хат, шигъри хикәят, шигъри сатира, мәсәл, күңел лирикасы һ.б.). Сурәтләү алымнары. Җанлы сөйләмгә нигезләнгән әсәрләрнең киңрәк урын ала баруы.<br>XIX гасыр урталарына таба татар поэзиясендә дөньяви мотивларның, реализм элементларының һәм күпчелеккә аңлаешлы телдә язылган шигырьләрнең урын ала баруы. Татар тормышының реаль күренешләрен тасвирлый башлау. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.3 | Творчество А.Каргалыя, Х. Салихова | Әбелмәних Каргалый (1782–1833 елдан сон}. Әсәрләре. Сәяхәтнамә һәм лирик мөнәҗәтләре. Шигырьләрендә дөньяви мәсьәләләр. Пейзаж һәм күңел лирикасы. Лирик мөнәҗәтләре. Әсәрләрендә суфичылык мотивлары. Иҗатының әһәмияте.<br>Һибәтулла Салихов (1794–1867). Беренче мәрсияләре. «Тәндә җаным...» шигыре. Дини–суфичылык мотивлары. Әсәрләрендә әхлак, тәрбия, шәхес һәм тирәлек мәсьәлә–ләре. Тел–стиль һәм идея–художество үзенчәлекләре. |
| 2.4 | Творчество Ш. Заки и Кол Мухаммеда | Шәмсетдин Зәкинең (1821–1865) тормышы һәм иҗат мирасы. Фәлсәфи рухтагы шигырьләре. Шагыйрьнең образлы фикерләү үзенчәлекләре, поэтик осталыгы. Әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше.<br>Кол Мөхәммәд (1775.– 1845) Тәрҗемәи хәле һәм иҗади мирасы. Поэмаларында әхлаки мәсьәләләр. Шигырьләрендәге фәлсәфи фикерләве, дини тематикага өстенлек бирелүе. |
| 2.5 | Творчество Багави и Г. Кандалыя | Баһавиның «Бүз егет» (1842) дастаны. Әсәр сюжетында дөньяви күренешләрнең фантастик алымнарда бирелүе. Кешенең бәхеткә, шәхси иреккә хокукы, хатын–кыз язмышы һ.б. мәсьәләләрнең инсани планда хәл ителүе.<br>Габделҗәббар Кандалый (1797–1860) Тормышы һәм шәхесе турында мәгълүматлар. Иҗади мирасын туплау һәм өйрәнү. Әдипнең башлангыч чор иҗаты. Мәхәббәт лирикасы. Иҗатының төп яңалыклары. Шигырь техникасын баетуы. Иҗатының әһәмияте. |
| 2.6 | Татарская литература второй половины XIX в. | Гасыр уртасында җәмгыять үсешендә туган каршылыклар. 1861 елда крепостное право бетерелүе һәм Рәсәйнең, шул исәптән татар халкының, капиталистик үсеш юлына чыгуы. Азатлык хәрәкәтенең яңа этабы. Крестьян восстаниеләре. Тарихи социаль–икъдисади үзгәрешләрнең, иҗтимагый фикернең халыкларга тәэсире. Төрки халыкларда уяну хәрәкәтенә юл салучы эшлеклеләрнең мәйданга чыгуы: Азәрбайҗанда – Ахундов М.Ф., Казахстанда – Ч.Вәлиханов, А.Кунанбаев, татарларда – Х.Фәезханов, К.Насыйри һ.б.<br>Рус җәмгыятендә демократик көчләрнең татарлар тормышы белән кызыксынуы. «Современник» журналында П.И.Пашино мәкаләләре басылып чыгу. Казанда Татар укытучылар мәктәбе ачылу (1876). Аның педагогик кадрлар әзерләүдәге роле. Бу мәктәптә төрле елларда белем алган күренекле шәхесләр (Х.Ямашев, Г.Исхакый, С.Максуди, Г.Коләхмәтов һ.б.).<br>Казан университеты каршында оештырылган «Археология, тарих һәм этнография» җәмгыяте (1878) эшчәнлегендә рус һәм татар галимнәренең катнашуы (Н.Катанов, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри Һ.б.).<br>Татар телендә вакытлы матбугат чыгаруга омтылышлар һәм аларның тормышка ашмау сәбәпләре (И.Запольский, М.Никольский, П.Пашино, Х.Фәезханов, |

| | | |
|---|---|---|
| | | К.Насыйри, З.Бигиев, Ш.Әхмәров һ.б.). |
| 2.7 | Знаменитые татарский просветители и их деятельность | Күренекле мәгърифәтчеләр һәм аларның эшчәнлеге. Галим, тарихчы, рухани фәлсәфәче, педагог Шиһабеддин Мәрҗани (1818–1889) һәм аның хезмәтләре. Хөсәен Фәезхановның (1828–1866) педагогик һәм гыйльми эшчәнлеге. Исмәгыйль Гаспралының (1851–1914) тормышы, күпкырлы эшчәнлеге. Җәдитчелек хәрәкәтенең идеологы. «Тәрҗеман» газетасы чыгара башлавы. Каюм Насыйриның (1825–1902) тормыш юлы. Тәрҗемәчелек өлкәсендәге эшчәнлеге. Әдәби әсәрләре. Мәгърифәтче галим буларак эшчәнлеге. |
| 2.8 | Татарская поэзия второй половины XIX в. | Поэзиянең татар әдәби традицияләренә таянуы һәм шулай ук чынбарлыкка, халыкны борчыган мәсьәләләргә итүе. Тормыштагы үзгәрешләргә бәйле мәгърифәтчелек идеяләренең шигъриятькә тирән үтеп керүе. Халыкның үткәненә, олы шәхесләргә мөрәҗәгать итү көчәю (Г.Чокрый, Акмулла). Шәхеснең уй–кичерешләрен үзәккә кую аша белемлелек, әхлакый сыйфатлар макталу, социаль каршылыкларны күрсә-түнең публицистик яңгыраш алуы (Акмулла, Б.Вәисев). Яңа традицияләр эзләп рус поэзиясенә мөрәҗәгать итү (Я.Емельянов). Тәрбия, гаилә мәсьәләләренә игътибар арту һәм аның бигрәк тә шагыйрәләр иҗатында актив яңгыраш алуы (Г.Сәмитова, Бибигөлҗамал һ.б.). Дастан жанрының яңа биеклеккә күтәрелүе (Ә. Уразаев–Кормаши). Бу чор поэзиясенең яңа сыйфат үзгәрешләренә әзерлек чорын кичерүе. XVII йөз шагыйре Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» сюжеты нигезендә яңа Сәйфелмөлек дастаннары барлыкка килүе. Йосыфбик һәм М.Юмачиков дастаннары. «Эрбет бәете». «Мәкәрҗә бәете»нең (1860) язылу, басылу тарихы. Тормышны Мәкәрҗә ярминкәсе белән чагыштыру. Халыкның фәкыйрьлектә, авыр тормышта яшәвен реаль күренешләрдә тасвирлау. Моның өчен түрәләр гаепле дигән фикер үткәрелү. «Яхшыга бәхет, начарга җәза» фәлсәфәсенең яклануы. Гади халык яклауга мохтаҗ дигән нәтиҗә ясалу. Моның халык сабырлыгы, патшага тугрылыгы дигән фикер артына яшерелүе. Әсәрнең әһәмияте. |
| 2.9 | Творчество Мифтахеддина Акмуллы и Гали Чокрыя | Мифтахеддин Акмулланың (1831–1895) татар, казакъ, башкорт халыкларының уртак әдибе, мәгърифәтче, олы фикер иясе булып танылуы. Аның катлаулы тормыш һәм иҗат юлы, шәхесе. Әсәрләрендә мәгърифәтчелек идеяләре («Бәгъдәссәлам, Нургали мулла...» һ.б.). «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе»н дә гыйлем, әхлак мәсьәләләренең романтик рухта сурәтләнүе. Төрмәдә язган шигырьләрендә социаль мотивларның чагылуы. Лирик герой хис–кичерешләрендә тормыштагы гаделсезлекнең бирелүе («Урыным – |

| | | |
|---|---|---|
| | | зиндан...», «Гаҗәб: һәр кем гани булса...», «Минем кебек булыр микән бәхетсез» һ.б.). Әдипнең чын гыйлемлекне әхлакый сафлык белән бәйләп каравы («Иң әүвәл пакьләү кирәк эчнең керен...») һәм наданлыкка, комсызлыкка сатирасы («Бәланың күбе чыга эчемездән...», «Башка илне без күрәбез...»). Акмулла – чичән шагыйрь. Сәнгати осталыгы белән әдәбиятка ясаган йогынтысы.<br>Гали Чокрыйның (1826–1889) тормышы, әдәби мирасы. Иҗатында дини–суфыйчыл традицияләрнең дөньяви мотивлар белән үрелеп баруы. «Шәмгыз–зыя» (1883) китабында заманының күренекле шәхесләренә, руханиларга мөрәҗәгать итүе. Алар эшчәнлегенең әһәмиятен билгеләп, киләчәкнең шундый кешеләргә бәйле булуын күрсәтү. «Мәдхе Казан» (1889) китабында белем йорты, мәдәни учак буларак Казанның макталуы. «Хаҗнамә»дә (1876–1879) әдипнең фәлсәфи–публицистик уйланулары, фән–техника прогрессын яклавы чагылу. Туган як турындагы хис–кичерешләренең үзенчәлекле бирелеше. «Фосуле әрбага» циклында табигать күренешләренең кеше яшәешенә, аның рухи халәтенә бәйле сурәтләнүе. |
| 2.10 | Творчество Я.Емельянова и А.Уразаев–Курмаши | Яков Емельяновның (1843–1898) тормыш юлы, әдәби мирасы. Гади халыкның авыр тормышын, аянычлы көнкүрешен реалистик детальләрдә сурәтләве («Ярлы тормыш», «Кайгы» һ.б.). Шигырьләрдә үзара ярдәмләшүгә, изге гамәлләр кылуга, ата–ананы, өлкәннәрне хөрмәт итәргә чакыру һәм һәртөрле әхлаксызлыкны, усаллык–яманлыкны тәнкыйтьләү («Улыма», «Санлау», «Саран бай», «Әләк» һ.б.). Әдипнең яңа традицияләр эзләп рус поэзиясенә (И.Никитин иҗатына) мөрәҗәгать итүе. Шигырьләренең вакыйгачылыкка нигезләнүе. Җанлы сөйләм теленә таянган «сөйләм» жанрын үстерүе. Емельянов поэзиясенең үзенчәлекле сыйфатлары: теленең халыкча, тасвирның гади, ачык булуы. Шигырьне ритмик яктан баету һәм төрләндерү тәҗрибәсе. Халык авыз иҗаты белән бәйләнеше. Шагыйрьнең татар поэзиясендә тоткан урыны.<br>Әхмәт Уразаев–Кормаши (якынча 1855–1883) иҗатында романтик мәхәббәт сюжетына нигезләнгән дастан–кыйсса жанры үсеше. Баһави дастанына ияреп иҗат ителгән «Кыйссаи Бүз егет» (1874). Шигырь аралаш проза белән язылган «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» дә (1876) Сайяди әсәренең яңача үстерелеше. Шәхес азатлыгы, саф мәхәббәт өчен көрәшүче Таһир һәм Зөһрәнең кара көч символы булган ханга, аның властена капма– каршы сурәтләнүе. Коръәннән, Урта гасыр әдәбиятыннан килүче сабырлык, гаделлек, игелеклелек кебек сыйфатларның яклануы. Дини эчтәлек белән реаль вакыйгаларның үзара бәйләнеп килүе. Әсәрдә сурәтләү |

| | | |
|---|---|---|
| | | чаралары. |
| 2.11 | Творчество татарских поэтесс XIX века | XIX йөз татар әдәбиятында шагыйрәләр иҗаты Г.Биктимированың (1876–1906) «Тәргыйбел–бәнат» («Кыз балаларда укуга дәрт уяту»), «Мәгашәрәт адәбе» («Аралашу кагыйдәләре»), Х.Гыйсмәтуллинаның (XIX йөз ахыры– XX йөз башы) «Тәгъзия» («Юаныч»), «Төргыйб» («Кызыксындыру»), Г.Рәхмәтуллинаның (XIX йөз ахыры– XX йөз башы) «Аналарга яднамә», «Иҗмагъ ишеге» кебек әсәрләрендә, җыентыкларында гаилә мөнәсәбәтләре, кыз балаларны укыту, әхлак сыйфатлары тәрбияләү, хатын–кыз язмышы мәсьәләләренең үзенчәлекле чагылышы.<br>Бибигөлҗамалның «Бидгать–намә» әсәре, аның идея–эстетик үзенчәлекләре.<br>Газизә Сәмитованың (1862–1929) катлаулы тормыш юлы, иҗаты. Шагыйрәнең башлангыч чор иҗатына хас киләчәккә ышаныч, яшәеш турында уйлану, дусларын юату, сөйгәненнән аерылу мотивлары («Сәнең өчен», «Җан дустыма», «Күп сайрама, сандугач!» һ.б.). Бәхетсез язмышына бәйле хатын–кыз хокуксызлыгы, язмышка буйсынуның моңсулык белән, лирик кичерешләр рәвешендә тасвирлануы («Кыз тәкъдире», «Сагыш», «Ничек түзим?», «Зая  гомер»). Беренче рус инкыйлабы алдыннан  язган шигырьләренең оптимизм белен сугарылуы, белем–мәгърифәткә өндәве, туган телне зурлавы («Каләм», «Гыйлемлек  җанга юлдаш», «Төркем барга күркем бар» һ.б.). Иҗатының соңгы чорында рухи төшенкелек, әҗәл якынлашу, хәсрәттә үткән гомер турында уйланулары («Анда киткәч», «Хәсрәт күп күргәнгә язык юк», «Ютәл йөрәкне өзәдер» һ.б.). Шагыйрәнең икеюллык парчаларында яшәеш турында фәлсәфи фикерләве («Ялгыз торгынлыктан үлгән юк, Әмма ялгызлыкта иләм юк»). Халык иҗатына нигезләнеп язылган бәет–җырлары. |
| 2.12 | Татарская проза второй половины XIX в. | XIX йөзнең икенче яртысы татар әдәбиятындагы мөһим идея–эстетик үзгәрешләрнең аеруча чәчмә иҗатта зур урын алуы. Әдәбиятның заман таләпләренә йөз белән борылуы, реализм юлына чыгуы һәм мәгърифәтчелек прозасы формалашуы, аның сәбәпләре, эволюциясе. Аның шәрык әдәбияты традицияләренә (дастан, кыйсса, хикәят) һәм халык авыз иҗатына (әкият, мәзәк һ.б.) нигезләнүе.<br>К.Насыйри, Г.Фәезханов, Ф.Халиди һ.б.ларның тәрҗемәчелек эшчәнлеге («Тутыйнамә», «Кәлилә вә Димнә», «Мең дә бер кичә» һ.б.) Ияреп язу үрнәкләре («Мең дә бер сәхәр»). Аларның укучы  әдәби–эстетик зәвыгын үстерүдәге, әдипләргә тәҗрибә үрнәге булудагы роле. Кысалы кыйсса турында төшенчә.<br>Рус һәм Аурупа әдәбиятлары йогынтысы. Тәрҗемә эшенең киңәюе (К.Насыйри, В.Радлов, Таип Яхин һ.б.). |

| | | |
|---|---|---|
| | | Беренче проза әсәрләренең рус һәм Аурупа авторлары йогынтысында язылуы (М.Акъегетзадә, З.Бигиев). Мәгърифәтчелек прозасының идея–эстетик үзенчәлекләре: чынбарлыкка нигезләнгән вакыйга–күренешләрне тасвирлау һәм аларның кайда, кайчан баруы күрсәтелү; укучыга якынрак булу максатында, әдипнең әледән–әле аңа мөрәҗәгать итүе яисә хикәяләүгә катнашып китүе; публицистика стилен иркен куллану; үзәккә укымышлы герой алыну һәм аның шәхес ирекен яклавы, милләткә хезмәт итү идеясе белән яшәве; шәхесне «тәрбия җимеше» итеп карау, шуңа бәйле ата–ана тәрбиясенә һәм мәктәп–мәдрәсәләрдә укыту–тәрбия эшенең торышына зур игътибар бирелү, икенче яктан, кешенең әйләнә–тирә йогынтысында формалашуын күрсәтү; хатын–кыз язмышының җитди проблема итеп күтәрелүе; яңа жанрлар барлыкка килү, әмма аларның теоретик яктан тиешенчә өйрәнелмәве, шуңа бәйле атамаларда каршылыклар булу; сәяхәтнамә жанрының активлашуы, аның мәгърифәтчелек идеяләренә хезмәт итүе; тел–сурәтләү чараларының камилләшүе. |
| 2.13 | Творчество М.Акъегет и З.Бигиева | Муса Акъегетзадәнең (1864–1923) тормыш һәм иҗат юлы. Аның Европа әдәбияты тәэсирендә булуы. «Хисамеддин менла» (1886) әсәре. Жанры (повесть – роман) турында бүгенге фәндәге карашлар. Әсәрдә кадимчелек һәм җәдитчелек каршылыгы үзәккә куелуы. Күтәрелгән төп мәсьәләләр: шәхес, мәхәббәт ирекe һәм милләт мәнфәгате; гаилә тәрбиясе һәм мәдрәсәдә укыту; халыкчылык идеясе. Аларның Хисамеддин, Әбүзәр Дәүләтгилдиев, Гайса Зурколаков, Мохтар образларының эш–хәрәкәтендә хәл ителеше. Авторның шәхес ирекенә омтылу мәсьәләсен күтәрүдәге кыюлыгы, кешене горур итеп күрергә теләү мотивын сурәтләве. Хатын–кыз язмышының Хәнифә образына бәйле рәвештә бирелеше. Тискәре геройларны берьяклы гына сурәтләү.<br>Романның композициясе һәм сюжет үстерелеше. Мәхәббәт, көнкүреш һәм иҗтимагый–социаль каршылыкларның үзара бәйләнештә бирелүе. Аның рус–Аурупа әдәбиятлары йогынтысында язылуы. Әсәрдә иҗтимагый мәсьәләләрнең шәхси һәм тормыш–көнкүреш күренешләре белән аралашып килүе. Публицистик һәм лирик чигенешләрнең төп идеягә хезмәт итүе. Портрет, пейзаж кебек алымнарның, этнографик детальләрнең роле. Тел–сурәтләү чараларын кулланудагы үзенчәлекләр. Геройларның эчке дөньясын ачу алымнары, психологик анализ ягалгылары. Татар әдәбиятында беренче реалистик роман буларак әһәмияте.<br>Заһир Бигиевнең (1870–1902) тормышы һәм иҗат эшчәнлеге. Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятларын яхшы белгән шәхес буларак формалашуы. Берничә |

| | | |
|---|---|---|
| | | кульязмасының әлегәчә табылмавы. Туганы дин белгече Муса Бигиевнең эшчәнлеге һәм язмышы турында мәгълүмат.<br>«Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887) романы. Аның татар әдәбиятында детектив жанрдагы тәүге әсәрләрнең берсе булуы. Җинаять эшен тикшерү мәсьәләсенең гаилә, әхлакый сыйфатлар, хатын–кыз язмышы белән бәйлелектә бирелүе. Акча (Меңнәр) өчен көрәшүче Муса һәм Габденнасыйр каршылыгының чишелешендә әхлакый хөкемнең тантана итүе. Зөләйха һәм Хәдичә образларында хатын–кыз бәхете, иреге мәсьәләсенең М.Акъегетзадә фикеренә каршы планда хәл ителеше: ата–ана фатихасын алмаган Зөләйханың бәхетсезлеккә дучар булуы, өлкәннәр сүзеннән чыкмаган Хәдичәнең бәхеткә ирешүе. Әсәрдә суд һәм тикшерү органнарында эшләүчеләрнең каршылыклы бирелеше һәм аларның образ буларак ачылу дәрәҗәсе. Хикәяләү вакыйгалылыкка корылган романда психологик анализның йомшак булуы. Җәмгыять асылының романда объектив рәвештә реалистик чагылышы. Әсәрдәге фаҗигаларның сәбәпләренә язучының мәгърифәтчел карашлары. Әсәрнең композицион үзенчәлеге һәм теле.<br>«Зур гөнаһлар» («Гөнаһе кәбаир», 1890) романында вакыйгаларның ике сюжет сызыгы буенча үстерелеше. Габделгафурның җинаятькә килү юлын гаилә тәрбиясе һәм мәдрәсә тормышы фонында күзәтү. Маһруйны «зур гөнаһларга» китергән сәбәпләрне реалистик планда, җәмгыятьтәге шартларга бәйләп ачу. Җиһангир – уңай герой идеалы. Әлеге ике образда «Коръән»нән һәм Урта гасыр татар әдәбиятыннан килгән карашларның яклануы. Романда Ягъкуб һәм Ибраһим Галиевлар, акушерка карчык, Мәмәт образлары. Эш–хәрәкәтләренең ышандыру көченә күбрәк ия булуы. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше.<br>«Мавәраэннәһердә сәяхәт» (1893) әсәренең язылу тарихы. Сәяхәтнамәдә заманга бәйле иҗтимагый, мәдәни, милли, дини, сәяси, әхлакый мәсьәләләрнең куелышы һәм шулар аша мәгърифәтчелек карашларын пропагандалау. Әдип үзе булган, күргән, чагыштырып бәя биргән күренешләрнең лирик–публицистик уйланулар белән кушылып килүе. Әсәрнең татар публицистикасы һәм сәяхәтнамә жанры үсешендәге урыны. З.Бигиев иҗаты турында Г.Тукай, Ф. Әмирхан, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов һ.б. |
| 2.14 | Творчество Р.Фахретдинова и Ф.Карими | Күренекле мәгърифәтче, дин галиме, тарихчы, педагог, журналист һәм әдип Ризаэддин Фәхреддиннең (1859–1936) тормышы һәм мәдәни–гыйльми эшчәнлеге. Белем–тәрбия, әхлак («Тәрбияле ава» (1898), «Тәрбияле бала» (1898), «Шәкертлек әдәбе» (1899), тарих («Болгар вә Казан төрекләре», «Алтын Урда ханнары» һ.б.) |

| | | |
|---|---|---|
| | | мәсьәләләренә караган һәм биобиблиографик характердагы күптомлык «Асар» («Эзләр») h.б. хезмәтләре. Татарлар өчен китапханә һәм газета кирәклеген яклавы. Р.Фәхреддин мөхәррирлек иткән атаклы «Шура» (1908–1917) журналының татар халкы тормышындагы роле.<br>«Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898) повестенда иҗтимагый тормышның әһәмиятле мәсьәләләре күтәрелү. Татар шәкерте һәм идеаллаштырылган Сәлимә образында намуслы, дөрес яшәеш кешегә бәхет китерә дигән фикернең яклануы. Әсәрнең, синкретик характеры. Сурәтләү чаралары.<br>«Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) повестеның маҗаралы сюжеты. Конфликтның искелек–яңалык, яхшылык–явызлык каршылыгына нигез–ләнүе. Габбас хәзрәт, Гайшә абыстай, Әсма образлары. Аларның эш–гамәленнән чыга торган нәтиҗәләр. Сәлим бабай, Салих бай, Шәкерт (мөгаллим) кебек эпизодик образларга салынган эстетик йөкләмә. «Тәрәккый тормозлары»ның гамәлгә күрә җәза алуы. Күтәрелгән мәсьәләләрнең, геройлар язмышының мәгърифәтчелек идеологиясе кысаларында хәл ителүе. Р.Фәхреддин әсәрләренең философик нигезләре. «Милләт анасы» төшенчәсе һәм шул яктылыкта хатын–кыз образларының гәүдәләнеше. Язучы иҗатының әһәмияте.<br>Фатих Кәриминең (1870–1937) тормыш юлы һәм әдәби–публицистик эшчәнлеге. Әсәрләренең синкретик характеры (әдәби хикәяләү, тасвир һәм публицистик, педагогик фикерләрнең, тарихи–географик мәгълүматларның бергә үрелүе. Аның иҗатына рус һәм Аурупа әдәбияты, фәлсәфәсе йогынтысы. Оренбургта «Вакыт» газетасында мөхәррилек итүе.<br>Мәхәббәт, гаилә кору мәсьәләләрен үз эченә алган, аларны гуманистик планда һәм романтик чаралар ярдәмендә хәл иткән «Салих бабайның өйләнүе» (1897) әсәрләре. «Шәкерт илә студент» (1899), «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы» (1898), «Нуреддин хәлфә» (1900) повесть–хикәяләрендә иске тип мәдрәсәләрне, әдәпсезлек–әхлаксызлыкны, кадимчелекне тәнкыйтьләү һәм яңача укытуны, башка халыклардан үрнәк алуны, дөньяви белемне, «европача» яшәүне яклау, мәхәббәт һәм гаилә турында гуманистик идеяләр. Романтик мәхәббәтне сурәтләүгә багышлаган «Морза кызы Фатыйма» (1901) әсәре. Аның татар әдәбиятында беренче документаль–биографик повесть булуы. Әсәрләрдә чор җәмгатьчелегендә бәхәсләр уяткан «Коръән» тәгълиматын дөрес аңлау, мөселманлыкның асылы, милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге турында уйланулар. Романтик утопия жанрында язылган «Хыялмы? Хакыйкатьме?» (1908) әсәрендә мөселман бердәмлегенә бәйле И.Гаспралы фикерләренең яклануы. |

| | | |
|---|---|---|
| | | «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902), «Кырымга сәяхәт» (1903) әсәрләрендә мәгърифәтчелек карашлары. Әдипне борчыган мәсьәләләрнең әдәби–публицистик планда бирелүе. |
| 2.15 | Творчество З.Хади и Ш.Мухахамедова | Закир Һадиның (1863–1933) тормыш юлы һәм иҗаты. «Бәхетле кыз», «Бәхетсез кыз» хикәяләрендә тормыш–көнкүреш картиналарының реалистик планда бирелүе. «Бәхетле кыз»да хатын–кыз язмышына бәйле иске гореф–гадәтләрне, әхлаксызлыкны, надан руханиларны тәнкыйть итү. Искелек тарафдарлары булган Ибәт абызагай, Сәлим муллаларга капма–каршы рәвештә Габбас мулла һәм Гайшәнең идеаллаштырылган образларын бирү. М.Акъегетзадә идеяләре белән аваздашлык. «Бәхетсез  кыз» да Хәнифә фаҗигасе сәбәпләрен ата–ана тәрбиясенә һәм руханиларның үз вазифаларын тиешенчә башкармаулары аркасында әйләнә–тирәдә хөкем, сөргән начар гадәтләргә бәйле ачу. Әдипнең тәрбия һәм мәгърифәт көченә тирән ышануы. «Мәгъсүм» (1906) хикәясендә иске тип мәдрәсәләрне фаш итү. Мәгъсүмнең фаҗигале үлеменә китергән сәбәпләрне кеше һәм тирәлек мөнәсәбәтендә реалистик ачу. Әсәрдә тасвирлылык һәм психологизм.  Пейзажның, әдәби һәм этнографик детальләрнең роле.<br>«Яңа әсхабе кәһәф» (1908) – кадими уку йортларына сатира. Сәфәргали, Миңлешаһ, Тимербайның язмышына, эш–гамәленә бәйле шул чор татар тормышын, яшәү рәвешен күрсәтү һәм милләт фаҗигасен  аңларга омтылу. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне идеаллаштырып бирү.<br>«Җиһанша хәзрәт» (1908) повестенда З.Һадиның биографизм принцибына мөрәҗәгать итүе. «Ясаган тар юлы заманга ярашмас» булган Җиһанша ишан образы. Автор идеалы чагылышы буларак Хәсән мулла. Төп геройларның Фәхрелбәнатка мөнәсәбәттә бәяләнүе. Әсәрдә типиклаштыру алымнары.<br>Язучы әсәрләре телендә ирония һәм сарказм. З.Һади иҗатында реализм тенденцияләренең ныгуы.<br>Шакир Мөхәммәдевнең (1865–1923) тормышы, күпкырлы иҗаты. Әдип һәм журналист буларак уңышлы эшләве. Сатирик «Карчыга» (1906–1907) журналы мөхәррире.<br>«Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай» (1901) повестенда беренче тапкыр татар сәүдәгәре тормышы сүрәтләнү. Искелек, наданлык, әхлаксызлыкның нәтиҗәсен гыйбрәт буларак тасвирлау. Галиәкбәр «эшчәнлеген» фаш итүдә әдәби детальләрнең роле.<br>«Яфрак асты, яки Мәкәрҗә ярминкәсе» (1901) повестенда сәүдә буржуазиясе вәкиле булган Әхмәтсафаның банкротлыкка чыгу сәбәпләрен тормыштан артта калу белән аңлату. Фән–техника прогрессының һәм  мәгърифәтле булуның яклануы. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Әдипнең мәгърифәтчелек идеалын чагылдырган Гали Акчурин образы. Тормыш–көнкүреш вакыйгаларының төп идеяне ачуга хезмәт итүе.<br>«Япон сугышы, яки доброволец Батыргали агай» (1905) повестенда сатирик планда Батыргалинең «патриотизмын» ачу. Вакыйгаларның капма–каршылыкка бәйле бирелеше. Төп геройны төрле яклап характерлаганда кулланылган алымнар (үз–үзенә бәя бирү, башкаларның бәя бирүе, гадәттән тыш арттыру һ.б.). Авторның рус–япон сугышының чын асылын аңлап бетерә алмавы.<br>«Япон сугышы...» – татар прозасында беренче сатирик повесть. Татар демократик сатирасының үсешендә әсәрнең роле. Кеше образын тудыру, сюжет кору һәм әсәрләрен композицион яктан оештыруда Ш.Мөхәммәдевнең үзенчәлеге.<br>«Яңа бәдәвам китабы» исемле шигъри тупланмасы (1903). Шартлы сюжетка нигезләнгән «Хан кызы» (1904) әсәре. Новелла һәм кечкенә фельетоннары. Язучының теле. Әдипнең журналистик һәм публицистик эшчәнлеге. Ш.Мөхәммәдев – әдәби сатирага нигез салучыларның берсе. Иҗатының әһәмияте. |
| 2.16 | Первые образцы татарской драматургии. Творчество Г.Ильяси и Ф.Халиди | XIX йөзнең соңгы чирегендә әдәбиятта драма төре барлыкка килү. Аның шактый соңарып формалашу сәбәпләре (иҗтимагый фикернең акрын үсүе; төр үзенчәлекләренә бәйле әдипләрдән билгеле бер осталык, тәҗрибә соралу; татар театры булмау). Бу чорда драма төренең мәйдан яулый башлавына этәргеч ясаган шартлар (иҗтимагый, икътисади тормыштагы үзгәрешләр, мәгърифәтчелек хәрәкәте җәелү; әдәбияттагы эчке хасият һәм сыйфат үзгәрешләренең логик нәтиҗәсе; халык авыз иҗатына һәм җырлы–биюле уеннарга, диалог–монологларга киң урын биргән әдәби әсәрләргә таяну; Казан рус театрының уңай йогынтысы).<br>Мәгърифәтчелек хәрәкәтенең сәнгатьләр үсешендә җанлану уятуы, нәтиҗәдә өй театрлары, җәдит мәдрәсәләрендә сәхнәләр корылуы. Казан укытучылар мәктәбендә һәм «Мөхәммәдия» дә укучы яшьләрнең театрга омтылышлары. Театр эшенә әзерлек чаралары турында рус матбугаты. Касыймда һәм Бакчасарайда беренче спектакльләр уйналу. И.Кудашев–Ашказарский эшчәнлеге. Беренче ачык спектакльләр куелу: а) 1906 елның 21 апрелендә Уфада Г.Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш»ы; б) 1906 елның 5 маенда Казанда «Кызганыч бала», «Гыйшык бәласе» (Г.Камал һәм Г.Кәрәм тәрҗемәләре); в) 1906 елның 22 декабрендә шул ук пьесалар. Милли театрның драматургия үсешендәге роле.<br>Милли театр өчен пьесалар язу ихтыяҗы туу. Г.Ильяси («Бичара кыз», 1887), Ф.Халиди («Рәдде «Бичара кыз», |

| | | |
|---|---|---|
| | | 1888), Минһаҗеддин Әл–Казаный («Ихтыярлы кыз ихтыярсыз улмыш», 1898), Г.Камал («Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет», 1900), Г.Исхакый («Өч хатын белән тормыш», 1900), Ярулла Вәли («Оят яки Күз яше», 1902) пьесалары дөнья күрү. Төрекчәдән «Хөсет баба» (1893), «Кызганыч бала» (1900), «Гыйшык бәласе» (1902), русчадан «Комедия Чистайда» (1895), «Ревизор» (1902), «Өйләнү» (1903), «Наданлык илә галимлек» (1905) әсәрләре тәрҗемә ителү.<br>Беренче драма әсәрләрендә гаилә кору, хатын–кыз язмышы, социаль, милли тигезлек мәсьәләләренең үзәккә куелуы. Конфликтның әхлакый яссылыкта хәл ителүе. Әсәрләрнең сәнгатьлелек ягыннан йомшак булуы. Беренче татар пьесаларының үз чоры өчен әһәмияте.<br>Габдрахман Ильясиның (1856–1895) тормышы, әдәби–мәдәни эшчәнлеге. «Бичара кыз» (1887) пьесасының сюжеты. Яңалык һәм искелек көрәшенә нигезләнгән конфликтның әхлакый планда һәм схематик хәл ителеше. Маһитапның мәҗбүри никахтан котылып, теләгән кешесенә кияүгә чыгуы – М.Акъегетзадә карашларының яңа тормыш материалында һәм әдәби төр кысаларында чагылышы. Төп геройларның эш–хәрәкәте, характер буларак ачылу дәрәҗәсе. Хатын–кыз азатлыгы проблемасы. Маһитап образы, аның уй–кичерешләрендә ирекkә, яктыга омтылу чаткылары, консерватив татар байларын, семьядагы деспотизмны күрсәтүдә Биктимер образы. Конфликтның характеры һәм чишелеш үзенчәлеге. Җантимерне комик сурәтләү. Җанбай образы. Белемле, актив шәхес концепциясе.<br>Сюжетның схематик булуы. Каршылыкларны хәл итүдә логик эзлеклелекнең җитмәве. Образларга хас сыйфатларның автор сөйләве аша ачыклануы. Беренче драма әсәре буларак әһәмияте.<br>Фатих Халиди (1850–1923). Тормышы һәм иҗаты. Аның тәрҗемәләре («Мең дә бер кичә»,»Ләйлә вә Мәҗнүн кыйссасы», «Былбыл кошы» һ.б.) һәм календарьләре. «Рәдде «Бичара кыз» (1881) әсәрендә хатын–кыз бәхете мәсьәләсенә яхшылык һәм начарлык төшенчәсеннән чыгып якын килү. Әсәрдә шәһәр ярлылары һәм сәүдәгәрләре тормышын күрсәтүдә реализм элементлары. Бу пьесаның «Бичара кыз» әсәренә мөнәсәбәте, уртак һәм аермалы яклар. Автор идеалын гәүдәләндерү ягыннан Хәлимә образы. «Яхшыга – бәхет, яманга – җәза» концепциясе. Закир образы.<br>Ф.Халидинең Г.Ильяси карашлары белән каршылыкка керүе. «Рәдде «Бичара кыз»ның театр тәнкыйте рәвешендә язылуы. Әсәрнең реалистик нигезе һәм уңай идеалның хыял дөньясы аша бирелүе. Хәлимә образын сурәтләгәндә, Кол Гали традицияләренә таянуы. Геройларның эш–гамәлләрен психологик нигезләүнең, мотивлашты–руның йомшак булуы. Сәнгатьчә |

| | | |
|---|---|---|
| | | сурәтләүдән бигрәк, хикәяләүнең өстенлек итүе. «Морад Сәлимов» (1905) драмасында мәгърифәт белән наданлык» тәрбиялелек белән әхлаксызлык каршылыгының Морад һәм Якуп бай улы Сабир эш–хәрәкәтләрендә ачылуы. Әдәпле булуны, максатка ирешүне белем нәтиҗәсе итеп аңлату. «Яманга – җәза» фикеренең яклануы. Морад Сәлимов – идеаллаштырылган образ. Әсәрдә сабырлык сыйфатының макталуы. Баланы тәрбияләүдә ата–ана роле. Кыз баланың бәхете ата–ана фатихасына бәйле булу идеясен яклау. Драманың сәнгатьчә эшләнеше. Ф.Халидинең «Саран, надан Теллә бай» (1906) пьесасында Теллә бай һәм Байтирәкнең эш–гамәлләренә бәйле наданлык, саранлык кебек сыйфатларның тәнкыйтьләнүе. Җамал ярдәмендә Теллә бай кызларының теләкләренә ирешүе. Иганәчелекнең, белемгә омтылышның яклануы. Конфликтның зәгыйфьлеге, бик җиңел хәл ителүе. «Мәхрусә ханым» (1906) әсәрендә наданлык–әхлаксызлыкның мәгърифәткә, әдәп–әхлакка каршы куелып, конфликтның мәгърифәтчел принципларда хәл ителүе. «Мең дә бер сәхәр» (1903–1904) исемле кысалы кыйссасы. Ф.Халиди иҗатының әһәмияте. «Комедия Чистайда» (1895) әсәрнең рус әдәбияты үрнәгендә язылган булуы. XIX йөз ахыры мещан тормыш–көнкүреше сурәтләнү. Кызының бәхете, киләчәге турында кайгыртмыйча, аны мескен хәлдә калдырган Хәйрибикәнең сатира объекты итеп алынуы. Асрау Хөснинең башкаларга караганда акыллырак булуы. Конфликтның комедиячел характеры. Ибраһим, Әфләтун, Мәрфуга образларының берьяклы гына ачылуы. Әсәрнең теле, гуманистик асылы. Әсәрнең чагыштырмача уңышлы теле, татарларда беренче комедия буларак әһәмияте. |
| **3** | **Раздел 3. Татарская литература начала XX века** | |
| 3.1 | Татарская поэзия начала XX века | XX йөз башы татар әдәбияты курсының предметы, максат-бурычлары, хронологик чикләре. Чор әдәбиятының өйрәнелү тарихы, этаплары. Татар шигъриятенең күпгасырлык тарихы, традицияләре. Шигърияткә Г.Тукай, Н.Думави, М.Укмаси, З.Бәшири, М.Гафури кебек шагыйрьләрьнең килеп керүе. 10 елларда татар поэзиясенә шагыйрьләрнең икенче буыны килү: С.Сүнчәләй, З.Ярмәки, М.Фәйзи, Н.Исәнбәт, Ф.Бурнаш, Г.Сәмитова. Ш.Бабич, С.Сүнчәләй, М.Фәйзи, һ.б. |
| 3.2 | Творчество Габдуллы Тукая | Шагыйрь, прозаик, балалар язучысы, әдәби тәнкыйтьче, публицист, журналист, методист, җәмәгать эшлеклесе. Шагыйрь иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе. Җ.Вәлиди, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Г.Сәгъди, Я.Агишев, М.Гайнуллин, И.Нуруллин, Г.Халит, Р.Ганиева һ.б. |

| | | |
|---|---|---|
| | | карашлары. 1905-1907 елгы инкыйлаб елларында Тукайның шагыйрь буларак формалашуы. Журналистлык эшчәнлеге. Тукайның башлангыч чор иҗатында мәгърифәтчелек идеяләренең, үгет-нәсихәтчелекнең чагылышы, мәгърифәтчелек романтикасы өстенлек итү. Тукайга Казан әдәби мохитенең йогынтысы. «Әль-ислах», «Яшен», «Ялт-йолт», газета, сатирик журналларында эшчәнлеге. Тукай шигырьләрендәге лирик геройның рухи дөньясы катлаулану, кайгы-хәсрәт, төшенкелек, өметсезлек мотивлары килеп Шагыйрь иҗатында күзәтелгән романтизмның чыганаклары, эстетик табигате, Урта гасыр татар, рус һәм Аурупа поэзиясенең традицияләре. Тукай сатирасының иң югары ноктага күтәрелүе, идея-тематик һәм сәнгатьчелек ягыннан төрлеләнүе. Г.Тукайның дини-шәригать кануннарына, Аллага, Коръәнгә мөнәсәбәте. Тукайның һәр дәвер иҗатында Коръән, Ислам мәдәниятеннән килгән мотивларның күзәтелүе. Тукайның татар шигъриятен реалистик юнәлештә үстерүе. Шагыйрь лирикасында төрки-татар поэзиясе, халык авыз иҗаты, рус һәм Көнбатыш Аурупа әдәбиятлары традицияләренең синтезлашуы һәм аларның милли җирлектә үстерелеше. |
| 3.3 | Творчество Мажита Гафури | Әдипнең тормыш юлы. Талантлы шагыйрь, прозаик һәм публицист. Башлангыч иҗатының тематикасы. Шигъриятендә тарихи барышка мөнәсәбәтнең, социаль мотивларның тирәнлеге, реалистик «аклылык, публицистик аһәң көчәю. М.Гафуриның оста аллегорик-мәсәлче булып танылуы. М.Гафуриның 1908-1913 нче еллар лирикасында идея-эстетик үзгәрешләр: тематик киңлек, хис-кичерешләр тирәнлеге, күңел һәм фәлсәфи лириканың  өстенлек итүе, лирик геройның күңел дөньясы романтик сурәтлелеккә төрелеп бирелү, шагыйрь поэзиясенең дидактизм, үгет-нәсихәттән арынуы. Авторның шигърияткә параллель рәвештә прозада уңышлы эшләп килүе. Милли әдәбиятка гади халык, авыл, шәһәр ярлыларының, көнлекчеләрнең авыр тормышын, ачлык темасын сурәтләүне алып килүе. М.Гафури иҗатында жанр байлыгы, тел үзенчәлеге. |
| 3.4 | Творчество Сагита Рамеева | С.Рәмиев - романтик шагыйрь, прозаик һәм драматург, публицист һәм тәнкыйтьче, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе.  Журналистлык эшчәнлеге. С.Рәмиевиең башлангыч чор иҗаты. «Таң вакыты» шигыре. Лирик геройның кайгыру, борчылу сәбәпләре, бу хәлдән чыгу юллары турындагы уйланулары. Әсәр исеменең символик мәгънәсе. С.Рәмиевнең реакция  еллары шигъриятендә ярсу йөрәкле, шашкын, бунтарь, гыйсъянчы, лирик геройның бирелеше. С.Рәмиевнең үз каләм көчен драматургия төрендә сынап каравы. «Яшә Зәбәйдә, яшим мин» пьесасы. С.Рәмиевнең унынчы елларда прозага мөрәҗәгать итүе. «Нәҗметдин агай бәйрәме», «Галәветдин хаҗи корбаны – Җаек Хәдичә» |

| | | |
|---|---|---|
| | | хикәяләре. Әдипнең автобиографик характердагы төгәлләнми калган «Ул исерек түгел иде» повесте. |
| 3.5 | Творчество Дэрдменда | Талантлы шагыйрь, тыйнак һәм укымышлы зыялы, милләт хадиме. Иҗатының әдәби-эстетик юнәлеше һәм әдипнең үзенчәлекле иҗтимагый хәле. Дәрдемәнднең татар поэзиясендә классик романтик шагыйрь буларак танылуы. 1902-1903 елларда шигырь һәм хикәя жанрында беренче тәҗрибәләр ясавы. Дәрдемәнд лирикасының төп хасиятләре: шигъри таланты, кинаяле сөйләмгә, фикри тирәнлеккә, символик сурәтлелеккә осталыгы сиземләнү. Әсәрләрендә кеше һәм вакыт, урын (пространство), дөньяның бакыйлыгы, гомернең фанилыгы (чикләнгәнлеге), гомер агышы, тәкъдир, яшәү һәм үлем турында фәлсәфи уйлануларның әдип иҗатында кызыл җеп булып сузылуы «Кораб» шигырендә гәүдәләнеше. Шагыйрь иҗатының экзистенциализм фәлсәфәсе һәм импрессионистик стиль билгеләре белән бәйләнеше. Дәрдемәнднең робагый; фәрд, газәл, мәдхия, мәсәл кебек жанрларда эш итүе. Шагыйрь поэзиясендә мәгънәви тирәнлек, шигъри нәфислек, сүзләрне файдалануда үзгә осталык, кыскалык, сурәтләү чараларының муллыгы. |
| 3.6 | Творчество Нажиба Думави | Н.Думавиның катлаулы тормыш юлы. Аның лирик һәм эпик төрдәге уңышлы иҗаты. Әдәби тәнкыйть, публицистика өлкәсендәге эшчәнлеге. Н.Думави шигырьләрендә социаль контрастлар, тәнкыйди башлангычның көчәюе, чынбарлыкка мөнәсәбәтнең субъектив гәүдәләнеше күзәтелү. Шагыйрь иҗатының экспрессионистик агымга мөнәсәбәте. Н.Думавиның 10-елларда төрле фәлсәфи, мәдәни-тарихи мәктәпләргә мөрәҗәгать итүе: Көнбатыш һәм Көнчыгыш фәлсәфәсен, позитивизм философиясен өйрәнүе, аңа романтизм һәм экспрессионизм кебек әдәби юнәлешләрнең тәэсире, яшәешкә, акыл көченә шик белдерүе, рухи чистарыну кебек толстойчылык һәм руссоистик карашларны яклавы һ.б. Сугыш темасының әдип иҗатында чагылышы. «Ватан каһарманы яки агач аяк» (1916) хикәясе. «Сугыш» (1908), «Сугыш тәэссораты» (1916), «Головка» (1917) әсәрләре. Әдипнең тарихи риваять, хикәя-легендаларга нигезләнеп иҗат ителгән «Су кызы» (1915), «Болгар кызы Тойгы туташ» (1915) хикәяләре. Соңгы хикәясендә Идел буе болгарларының тормышы, гореф-гадәтләре, йолалары, уен-бәйрәмнәре җанландырылу. Н.Думавиның әдәби, фәлсәфи, гыйльми карашларын чагылдырган мәкаләләре. Аның иҗатын өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләре. |
| 3.7 | Творчество Шайхзады Бабича | Шәехзадә Бабич - талантлы шагыйрь, үткен телне публицист, оста педагог, фольклорчы. Ш.Бабичның шигъри иҗаты. Иҗатында жанрлар төрлелеге, идея-тематик киңлек Бабичның шигъриятендә сәнгатьчә фикерләүнең романтик төре өстенлек итү. Шагыйрь поэзиясендә Тукай темасының зур урын тотуы. Ш.Бабич |

| | | |
|---|---|---|
| | | иҗатында юмор һәм сатира, аның иҗтимагый-социаль эчтәлеге тирәнәю, максат-бурычларының киңәюе. «Кандала» (1916) поэмасының сюжеты, идея-эчтәлеге. «Газазил» (1916) әсәре. Поэманың эпик киңлеге, образларның конкретлылыгы, ирония һәм сарказмның үткенлеге, фантазиягә байлыгы. Ш.Бабичның публицистик мәкаләләре, аларда күтәрелгән проблемалар. |
| **4** | **Раздел 4. Татарская проза начала XX века** | |
| 4.1 | Творчество Гаяза Исхаки: проза, драматургия, публицистика | Яңа реалистик татар әдәбиятына нигез салучы күренекле прозаик, драматург, ялкынлы публицист, журналист, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче. Әдип иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе. «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер», «Кәләпүшче кыз», «Бай углы» әсәрләре. «Өч хатын белән тормыш» драмасы, «Ике гыйшык» пьесасы һәм «Очрашу яки Гөлгыйзар» повесте. Әсәрләренең жанр төрлелеге һәм сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте, жанры, сюжет-композициясе, проблематикасы, стиль үзенчәлеге. Татар халкының милләт буларак бетү, юкка чыгу куркынычы, аның сәбәпләре, милләтнең бүгенге хәле һәм киләчәге турында уйланулар. Г.Исхакыйның иҗтимагый-сәяси карашларында һәм әдәби-эстетик фикерендә чагылган борылыш. «Зиндан» повесте. «Алдым-бирдем» драмасы. «Тартышу», «Мөгаллим» драмалары. «Теләнче кыз» романы «Калош», «Фамилия сәгадәте», «Сөннәтче бабай» хикәяләрендә гаилә, кеше бәхете мәсьәләләре. «Мәдрәсә җимеше», «Шәкерт абый» кебек хикәяләрдә психологизм. «Тормышмы бу?» романы. Әсәрдә күтәрелгән проблемалар. «Мулла бабай» романы «Зөләйха» фаҗигасе «Ул икеләнә иде», «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрләрендә милләтара никахлар, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләре. «Локман Хәким», «Көз», «Өйгә» таба» һ.б. әсәрләре, аларның жанр үзенчәлекләре, идея эчтәлеге. «Дулкын эчендә» пьесасында дөнья сугышы, сыйнфый, инкыйлаби вакыйгаларның кеше язмышы, бәхете, гаилә тормышы мәсьәләләре. «Җан Баевич» комедиясендә милли мәсьәләсе. «Олуг Мөхәммәд» драмасы, аның жанр үзенчәлеге. Г.Исхакыйның татар әдәбияты тарихы һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге. Г.Исхакый һәм XX йөз татар әдәбияты. |
| 4.2 | Творчество Фатиха Амирхана: проза, драматургия, публицистика | Талантлы әдип, тәнкыйтьче һәм публицист, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. Ф.Әмирханның тормыш юлы. Аның журналистлык эшчәнлеге. «Гарәфә кич төшемдә» хикәясе. «Бәйрәмнәр» әсәре. «Фәтхулла хәзрәт» повестенда көлү һәм фаш итү объектлары. «Хәзрәт үгетләргә килде», «Габделбасыйр гыйшкы», «Сәмигулла абзый» һ.б. хикәяләре. «Картайдым» хикәясе. Әдипнең «Урталыкта» романы. Ф.Әмирхан иҗатында хатын-кыз темасының гәүдәләнеше: «Татар кызы» нәсере; «Хәят» |

| | | |
|---|---|---|
| | | повесте. «Ай өстендәге Зөһрә» кыз» романтик рухлы хикәясе. «Хәкарәт саналган мәхәббәт», «Бер харабадә», «Сүнгәч» хикәяләре. Аларның идея эчтәлеге. «Яшьләр», «Тигезсезләр» драмалары. Аларның жанр, сюжет, төзелеш үзенчәлеге. |
| 4.3 | Творчество Галимджана Ибрагимова: проза, драматургия, публицистика | Г.Ибраһимовның тормыш юлы, гаҗәеп күпкырлы эшчәнлеге турында белешмә: әдип, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, публицист һәм журналист, тарихчы һәм тел белгече, методист һәм педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче. Әдипнең иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе. Язучының 1907-1912 еллардагы әдәби эшчәнлеге. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе. «Татар хатыны ниләр күрми» (вариантлары) повесте. Язучының иҗатында психологизмга, әдәби геройларның эчке дөньясын, хис-кичерешләрен, табигать, пейзаж, хатын-кыз матурлыгын, рухи мәхәббәт темаларын сурәтләүгә игътибарның көчәюе, Гареб романтизмының әдип иҗатында Шәрык традицияләре белән үрелеп үсүе. «Яз башы», «Дингездә», «Сәю-сәгадәт» һ.б. хикәяләре. «Карак мулла» әсәре. «Яшь йөрәкләр» романы. Әдәби метод, әдәби юнәлеш ягыннан катлаулануы: реалистик юнәлештә үсеп китүе, реализм белән романтизмның синтезы күзәтелү, реализмның романтик алымнар, чаралар белән баетылуы. «Карт ялчы», «Көтүчеләр» хикәяләре. «Безнең көннәр» романы. Аның катлаулы сюжеты, төзелеше һәм образлар системасы. Г.Ибраһимовның тәнкыйди, гыйльми, педагогик-методик эшчәнлеге. «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә күтәрелгән мәсьәләләр. Авторның бәхәсле карашлары. |
| 4.4 | Творчество Шарифа Камала | Әдипнең тормыш юлы. «Вакыт», «Шура» газета-журналларында эшчәнлеге. «Сулган гөл», «Уяну», «Буранда», «Сукбай», «Бәхет эзләгәндә» һ.б. әсәрләре. «Бер картның тойгылары», «Нәфисә», «Эч пошулы» һ.б. инсаният идеясенең сурәтләнүе. Ш.Камал иҗатында психологизм. «Уяну», «Буранда», «Сулган гөл», «Курай тавышы», «Буранда», «Бер картның тойгылары», «Козгыннар оясында» хикәяләре. «Акчарлаклар» повесте. Аның вакытлы эшчеләр (балыкчылар) тормышын сурәтләве. Ш.Камал иҗатында сатира һәм юмор үрнәкләре. «Сәмруг кош», «Депутат» фельетон-хикәяләре. Ш.Камалның татар драматургиясен үстерүгә керткән өлеше. «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясе |
| 4.5 | Зарождение татарского театра и его влияние на развитие татарской драматургии | Татар драматургиясе тарихын чорларга бүлү мәсьәләсе: 1887-1905 еллар; 1906-1911 еллар; 1912-1917 еллар. Яшь көчләр килүе. Драматургиянең тарихи темаларга мөрәҗәгать итүе, идея эчтәлеге баеуы, жанрлар системасы төрләнүе.<br>Милли профессиональ театр барлыкка килү һәм татар драматургиясенең, тагын да ныгып, яңа баскычка күтәрелеше, бу уңайдан рус һәм Гареб драматурглары иҗатына мөрәҗәгать итү.<br>“Сәйяр”, “Нур” театрларының барлыкка килүе. |

| | | |
|---|---|---|
| 4.6 | Творчество Галиасгара Камала | Г.Камал - реалистик татар драматургиясенә нигез салучы, хикәяче һәм шигырьләр авторы, тәнкыйтьче, публицист, журналист, тәрҗемәче, рәссам, театр эшлеклесе. Камалны драматургиягә алып килгән алшартлар. Драматургның әдәби иҗаттагы беренче тәҗрибәләре «Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет» пьесалары һәм «Сабир хәзрәт» хикәясе. Г.Камалның әдәби һәм журналистлык эшчәнлеге «Уйнаш» драмасы. «Беренче театр» комедиясе. Әсәрнең төп һәм ярдәмче конфликтлары. «Бүләк өчен», «Банкрот» комедияләре. «Өйләнәм... ник өйләндем» трагикомедиясе. Г.Камал драма һәм комедияләренең бай сәхнә тарихы. Аның әдәби тәнкыйди эшчәнлеге |
| 4.7 | Творчество Гафура Кулахметова | Тормыш юлы. Аның инкыйлаби эшчәнлеге, марксистик тәгълиматны өйрәнүе. Милли телдә марксистик әдәбият, инкыйлаби матбугат тудыруда аның роле, Аның милли театрны оештыруга, үстерүгә керткән өлеше, педагогик эшчәнлеге. Г.Коләхмәтовның әдәби мирасы. Аның проза һәм драма төрләрендә эшләве, әсәрләрендә пролетариат әдәбиятының нигезе салыну. «Ике фикер» фәлсәфи драмасы. Пьесада күтәрелгән мәсьәләләр. «Яшь гомер» драмасы. Аның конфликты. Әдипнең эпик әсәрләре. «Уалган мол» нәсере. «Ник уйгандым» хикәясе. Хикәянең дини-мифологик сюжетка корылуы. |
| 4.8 | Творчество Мирхайдара Файзи | Татар әдәбияты тарихында драматург буларак танылуы, шигырь һәм хикәя жанрларында да мирас калдыруы. Аның тормыш сукмаклары. Татар драматургиясе өлкәсендә, беренче тәҗрибәләре: «Татар туе», «Ике Хәсән» пьесалары. Беренче шигырьләре. «Минем шигырьләрем», «Яшь күңел» шигырь китаплары. Шагыйрь поэзиясендә романтик иҗат принциплары. М.Фәйзинең драматургия төрендәге эшчәнлеге. «Яшьләр алдатмыйлар» водевиле. «Кызганыч» романтик драмасы. «Тәкъдирнең шаяруы», «Авыл бәйрәме» пьесасы. «Галиябану» музыкаль драмасы. Пьесаның жанр үзенчәлеге, сюжеты, композиция бөтенлеге, камиллеге. Драманың образлар системасы: Драманың сәнгатьчә эшләнеше. |
| **5** | **Раздел 4. Татарская литература 20-х годов (1917-1929 гг.)** | |
| 5.1 | Творчество Мажита Гафури | Башкортостанның халык шагыйре, татар һәм башкорт әдәбияты классигы буларак М.Гафури.<br>М.Гафуриның шигырьләрендә көн темаларына мөрәҗәгать итүе. «Бетсен империалистлар сугышы», «Икмәк», «Хөрriяткә каршы торучыларга», «Аждаһа» кебек шигырьләрендә Вакытлы хөкүмәтне, аның халыкка каршы политикасын фаш итүе. Изүчеләрне халык хөкеменә тарту пафосы белән сугарылган «Хисап көне», «Бай абзый» шигырьләре.<br>М.Гафуриның идея-эстетик үсешен күрсәтү ягыннан «Эшче» поэмасының беренче һәм икенче вариантлары. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Татар опера сәнгатенә нигез салудагы роле.<br>М.Гафури – прозаик. Нигездә реализмга өстенлек бирүе.<br>«Кара йөзләр» повесте. Әсәрнең төп проблемасы.<br>Галимә образының типиклыгы, халыкчан характеры.<br>Әсәрдә дини фанатизм белән аек акылның конфликтка керүе. Сәнгатьчә эшләнештә психологизмны оста файдалану. Персонажларның һәм хикәяләүченең индивидуаль теле. Әсәрнең тәнкыйди рухы.<br>«Тәрҗемәи хәлем», «Шагыйрьнең алтын приискасында» повестьларында яшь кеше образлары. Капиталистик чынбарлыкта түбән катлау яшьләренең авыр хәлен күрсәтеп бирү. Эшчеләр белән прииска хуҗаларын капма-каршы итеп сурәтләү.<br>«Тормыш баскычлары» повесте. Вахит Җәгъфәровның революцион чынбарлыкта актив көрәшче булып җитешүе. Нури Сәгыйтов, Ефимов, Нәгыйм Әминев образлары. Уңай образларны сурәтләүдәге җитешсезлекләр. Мәхмүт образы, аның типиклыгы. Хезмәт ияләренең авыр тормышын дөрес күрсәтү.<br>М.Гафуриның публицистикасы. М.Гафури иҗаты турындагы фәнни әдәбиятка күзәтү. |
| 5.2 | Литературная и общественная деятельность Галимджана Ибрагимова | Г.Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлы.<br>Г.Ибраһимовның совет чоры әдәбияты үсешенә ясаган тәэсире. «Кызыл чәчәкләр» повесте. Социаль чыгыш һәм революциягә мөнәсәбәт мәсьәләсенең образларда дөрес ачылуы. Шаһбаз, Солтан, Гыйлаҗи образларына каршы куелган Фазыйл белән Гали. Кызыл чәчәк образының символик булуы. Әсәр тукымасының халык авыз иҗатына якын яклары. Дуслык, намуслы хезмәт белән тормышны матурлау идеяләре.<br>«Тирән тамырлар» романы. Сыйнфый көрәшнең яңа формалары. Фәхри һәм Вәли Хәсәнов образы. Кеше концепциясенең яңаруы. Шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәте. Сюжет-композиция үзенчәлекләре. Символик образларның роле.<br>“Алмачуар” хикәясе. Кеше һәм табигать мөнәсәбәте, әхлакый мәсьәләләрне күтәрүе. “Адәмнәр” повесте натуралистик сурәтләрдә ачлык фаҗигасын тасвирлау.<br>Г.Ибраһимовның язучы буларак осталыгын күрсәткән «Казакъ кызы» романы. Тормыш материалының яңалыгы. Тугандаш казакъ халкының тарихи үткәнен реаль итеп сурәтләү. Карлыгач-Сылу, Арсланбай образларының реальлеге һәм романтиклыгы.<br>Г.Ибраһимов – татар әдәбияты классигы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе. Февраль һәм Октябрь инкыйлабларыннан соңгы иҗтимагый эшчәнлеге. “Яңа кешеләр” пьесасы. Сыйнфый көрәш һәм яңа хакимияткә мөнәсәбәт.<br>Г.Ибраһимовның язучы, галим булып җитлегүендә башка халыклар әдәбияты, фәне, мәдәнияте тәэсире. |

| | | |
|---|---|---|
| 5.3 | Творчество Хади Такташа | Иҗатының беренче чорына (1916-1922) хас үзенчәлекләр. Җәмгыятьтәге явызлыкны, рәхимсезлекне ләгънәтләү, аларга каршы чыгу протестының абстрактлыгы. Романтик сурәтләү, бунтарьлык рухы өстенлек итү. Дини-мифологик, символик образларның үзәктә торуы һәм шулар аша җир тормышын, яшәү мәгънәсен аңларга омтылу («Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр», «Янар таулар», «Җир уллары трагедиясе»). Мәхәббәттә янучы лирик герой («Урман кызы», «Таң кызы», «Зәңгәр күзләр»). Гомумкешелек кыйммәтләрен яклавы, фәлсәфи эчтәлек («Мәңгелек әкият»).<br>Иҗатының икенче чорына (1923-1931) хас үзенчәлекләр. Реалистик сурәтләү өстенлек итү. Гыйсъянчы лирик герой («Такташ үлде», «Син дә үл инде», «Әйдә, энем»). Чынбарлыкка, яңа җәмгыятькә бәя, мөнәсәбәт бирелү («Болай... гади җыр гына», «Ак чәчәкләр», «Мокамай»). Объектив һәм субъектив эчтәлек, форма яңалыгы, иҗтимагый тормыштагы социаль-психологик каршылыклар («Киләчәккә хатлар», «Бүгенге матурлык»). Яшьлек, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләренә мөрәҗәгать итү («Алсу», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Югалган матурлык»). Халыкчанлык, тел бизәкләре байлыгы, юмор («Нәни разбойник»). Еш кына романтизм белән реализм үрелеп килү; сөйләм шигыренең уңышлы формаларын табуы.<br>Һ.Такташ иҗатының новаторлыгы.<br>Һ.Такташ – драматург һәм прозаик. «Күмелгән кораллар», «Камил», «Югалган матурлык» драмалары. «Таң җиле» романының язылган кадәресе. “Караборынның дусты”, “Кияү” хикәяләре. Әсәрләренең проблематикасы.<br>Хәзерге татар совет шигъриятенә Һ.Такташ иҗат мәктәбенең тәэсире. |
| 5.4 | Творчество Карима Тинчурина | К.Тинчурин иҗатының үзенчәлеге, характерлар тудырудагы, сюжет корудагы аермалы яклары. К.Тинчуринның «Мәрҗәннәр» китабы, әсәрдә авторның прозаик буларак ачылуы. Драматургиядә К.Тинчурин тудырган традицияләр, аларның башка авторлар тарафыннан үстерелүе.<br>Музыкаль драма жанры үсешенә зур өлеш кертүе («Зәңгәр щәл», «Сүнгән йолдызлар», «Ил»). Иҗат үзенчәлекләре: беренче иҗат тәҗрибәләрен «Сәйяр» труппасында артист булып эшләгәндә ясый: «Хәләл кәсеп», «Беренче чәчәкләр», «Назлы кияү», «Соңгы сәлам» һ. б.; |
| 5.5 | Творчество Фатхи Бурнаша | Ф.Бурнашның романтик поэзиясе. Героик-патриотик поэзияне үстерүдә Ф.Бурнаш иҗаты. Аның әсәрләренең романтик характеры, халык иҗатына якынлыгы. Ф.Бурнашның революцион матбугаттагы эшчәнлеге. |

| | | |
|---|---|---|
| | | “Чәчәктән һәйкәл”, “Гөлчәчәк”, “Сахра каны”, “Ак каен”, “Әҗәл” поэмалары. Шигырьләре. “Таһир-Зөһрә” трагедиясе һәм “Яшь йөрәкләр” драмасының Ф.Бурнашны талантлы драматург итеп танытуы. Ф.Бурнашның шигъриятта сатирик юнәлешне үстерүгә керткән өлеше. |
| 5.6 | Творчество Махмута Галяу | М.Галәүнең тормыш юлы. Вакытлы матбугатта актив катнашуы. Тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге. Дәреслекләр төзүдә, уку-укыту кулланмалары язуда, аң-белем таратуда катнашуы. М.Галәүнең хикәяләре, драма әсәрләре. «Канлы тамгалар» эпопеясы. Әсәрнең беренче һәм икенче кисәкләре – «Болганчык еллар» («Ил тыныч чакта»), «Мөһаҗирләр» (Ил өреккәндә») романнары. Аларның темалары, күтәргән проблемалары, сурәтләнгән образлар.<br>М.Галәү иҗаты турында фәнни хезмәтләр. |
| **6** | **Раздел 5. Татарская литература 30-х годов (1930-1941 гг.)** | |
| 6.1 | Творчество Шарифа Камала и Тази Гиззат | Шәриф Камалның тормыш һәм иҗат юлы. Ш.Камал – прозаик. «Матур туганда» романы. Ш.Камалның публицистикасы, аның актуальлеге<br>Ш.Камал – татар әдәбияты классигы, татар совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе булуы. Язучының башлангыч чор иҗатында идея-эстетик эволюциясе. Ш.Камал – прозаик. «Матур туганда» романы. Драматургның тормыш юлы. «Тәрҗемәи хәлем», «Мин ничек артист һәм драматург булдым» исемле язмалары. Т.Гыйззәтнең драматург буларак үсеш этаплары, аның иҗатындагы төп темалар.<br>1917 елга кадәрге татар авылы, андагы стихияле ңәм оешкан сыйнфый көрәшне тасвирлау. Тарихи-революцион драмалары: «Наемщик», «Чаткылар», «Ялкын», «Ташкыннар», «Бишбүләк» һ.б. Тулаем алганда бу әсәрләрдә татар крестьяны үткән юлның тарихи эзлеклелектә бирелүе. |
| 6.2 | Творчество Кави Назми и Гаделя Кутуя | Язучының тормышы һәм иҗаты. К.Нәҗминең иҗтимагый эшчәнлеге. Яңа әдәби юнәлешләр белән кызыксынуы. «Чыныгу» (1923), «Иң соңгысы» (1924), «Шобага» (1925), «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» (1926), «Таштугайга кайтмыйбыз!» (1928) кебек хикәяләре һәм аеруча хезмәт ияләренең революция, гражданнар сугышы аша социализмга килүен, яңа тормыш төзи башлавын реалистик картиналар һәм образлар аша сурәтләгән «Яр буенда учаклар» (1928), «Якты сукмак» (1929), «Кояшлы яңгыр» (1930) повестьлары. Бөек Ватан сугышы елларында К. Нәҗми. Әдип совет кешеләренең тылдагы һәм фронттагы батырлыгын, ватандарлык хисләрен әдәби образларда чагылдырган «Хәят апа» (1941), «Сагыну хаты» (1942), «Снайпер Мәрдән» (1943), «Фәридә» (1943-1944) кебек |

| | | |
|---|---|---|
| | | поэмаларын һәм күп санлы патриотик шигырьләре. «Язгы җилләр» исемле тарихи-революцион романы. Утызынчы еллардагы идея-эстетик үсеше, шуның күрсәткече буларак, «Җавап», «Шатлык җыры» пьесалары. Әдипнең барлык жанрлар өлкәсендә дә актив эшләве. Шигырь (“Иртәнге уйлар” һ.б.), поэма (“Талантлар ватаны” һ.б.), повесть (“Тапшырылмаган хатлар”, нәсер (“Без – сталинградчылар” һ.б.) очерк (“Берлин юлында очрашу”), тәрҗемә (Лермонтовның “Маскарад”ы, Маяковскийның “Сул марш”ы һ.б.), «Солтанның бер көне», «Нишләргә?», «Вөҗдан газабы» хикәяләре, аларда сурәтләнгән интеллигенция вәкилләре образлары. «Тапшырылмаган хатлар» повесте. |
| 6.3 | Татарская литература периода Великой отечественной войны (1941-1945 гг.) | Бөек Ватан сугышы елларында татар әдәбияты. Чор һәм әдәбият. Аңа хас үзенчәлекләр. Әдәбиятның агитатор һәм пропагандист вазифаларын үти башлавы: төп максат-бурычы: халыкны изге көрәшкә чакыру, бердәмлеккә өндәү, җиңүгә ышаныч тәрбиләү, фашизмга нәфрәт хисе уяту һ.б. Татар язучылырының күпчелеге фронтка китүе; 30 дан артыгы сугыш кырында яисә дошман әсирлегендә һәлак булуы (М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, К.Басыйров, М.Гаяз, Р. Ильяс, Х.Мөҗәй, Д.Фәтхи һ.б.). 1942 елдан башлап төрле фронтларда 16 исемдә татарча газета чыгуы. Аларда Г.Кутуй, А.Шамов, Ә.Ерикәй, Р.Ишморат, Г.Әпсәләмов, И.Гази, Ш.Маннур, Ә.Фәйзи, Ш.Мөдәррис, М.Хөсәен һ.б. әдипләрнең журналист булып хезмәт итүе. ВКП(б) ҮКның 1944 ел 9 август карары нигезендә татар әдәбиятында һәм сәнгатендә тарихи темаларны яктыртуга зур киртә куелуы. Сугыш чоры таләпләренә иң тиз яраклашучы төрнең лирика булуы, төп мотивлар. Әдәбиятның агитатор һәм пропагандист вазифаларын үти башлавы: төп максат-бурычы: халыкны изге көрәшкә чакыру, бердәмлеккә өндәү, җиңүгә ышаныч тәрбиләү, фашизмга нәфрәт хисе уяту һ.б. Татар язучылырының күпчелеге фронтка китүе; 30 дан артыгы сугыш кырында яисә дошман әсирлегендә һәлак булуы (М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, К.Басыйров, М.Гаяз, Р. Ильяс, Х.Мөҗәй, Д.Фәтхи һ.б.).1942 елдан башлап төрле фронтларда 16 исемдә татарча газета чыгуы. Аларда Г.Кутуй, А.Шамов, Ә.Ерикәй, Р.Ишморат, Г.Әпсәләмов, И.Гази, Ш.Маннур, Ә.Фәйзи, Ш.Мөдәррис, М.Хөсәен һ.б. әдипләрнең журналист булып хезмәт итүе. ВКП(б) ҮКның 1944 ел 9 август карары нигезендә татар әдәбиятында һәм сәнгатендә тарихи темаларны яктыртуга зур киртә куелуы.<br>Сугыш чоры таләпләренә иң тиз яраклашучы төрнең лирика булуы, төп мотивлар Поэзиядә жанрлар торышы. Традицияләрне баетырга омтылу. Бу өлкәдәге бәхәсләр. Прозада хикәя, очерк, повесть кебек жанрлар алгы планга чыгуы. Прозада жанр төрлелеге. Хикәя |

| | | |
|---|---|---|
| | | (Г.Әпсәләмов. Ватан улы. Үлемнән көчлерәк; Ә.Еники. Бала. Ана һәм кыз; И.Гази. Алар өчәү иде). Повесть (Ф.Кәрим. Язгы төндә. Разведчик язмалары). Маҗаралы повесть (Г.Кутуй. Рөстәм маҗаралары). Нәсер (Г.Кутуй. Сагыну. Без – сталинградчылар). Фронт көндәлеге (Х.Мөҗәй. Сугышчы язмалары). Драматургиядә халык героизмын, патриотизмын, партизаннар хәрәкәтен чагылдырган драмалар дөнья күрү (М. Әмир. Партизан Иван; Т.Гыйззәт. Төнге сигнал; Н.Исәнбәт. Мәрьям). Халыкның тылдагы фидакарь хезмәтен сүрәтләү (Р.Ишморат. Кайту; М.Әмир. Гөлҗамал. Миңлекамал). Тарих һәм заман темасына бәйле олы шәхесләрнең мәһабәт образлары тудырылу (Н.Исәнбәт. М.Вахитов; М.Гали, Х.Уразиков. К.Насыйри). |
| 6.4 | Творчество Мусы Джалиля | Иҗатының башлангыч чорында әсәрләрендә күтәрелгән проблемалар. Азат тормышка, хезмәткә дан җырлау, яңа әхлакны яклау, яшьләрне социалистик төзелешкә рухландыру. Кызыл Армияне данлау, иске тормышны фаш итү. “Барабыз” (1925), “Иптәшкә” (1929) җыентыклары.<br>“Бәхет”, “Үткән юллар”, “Кызыл каһарман”, “Сугышта” һ.б. әсәрләрендә яшәү һәм көрәш мәгънәсе турында уйланулар. Егерменче елларда шагыйрьнең эзләнүләре, иҗат кыенлыклары. Аның поэзиягә алып килгән яңалыгы, шигъри осталыгы камилләшүе. “Орденлы миллионнар”, “Шигырьләр һәм поэмалар”, “Шигырьләр” җыентыклары. Егерменче-утызынчы еллар яшьләренең героик-романтик рухын чагылдырган әсәрләре: “Походка”, “Батыр егет турында җыр”, “Унсигез”, “Сәрби әби”, “Күк юрга”, “Комсомолларга”, “Яшьләр”, “Урожай”, “Походка”, “Арыш кырында”, “Яшьлек”, “Колхоз кызына”, “Зәйнәп”.<br>“Хат ташучы” поэмасының темасы һәм идеясе. Сәнгатьчә эшләнеше. Тимербулат һәм Фәйрүзә образлары, әсәрнең идеясен ачуда аларның әһәмияте. Поэмада халыкчан традицияләренең оста файдаланылуы.<br>Халык-ара тормышка, дөнья эшче сыйныфы бердәмлегенә багышлап язылган “Парчалар”, “Еларгамы-көләргәме”, “Джем” әсәрләре.<br>М.Җәлилнең татар опера театрын оештыруда күрсәткән хезмәтләре. “Алтынчәч”, “Илдар” либреттолары. “Алтынчәч” героик-романтик драмасының идея-эстетик кыйммәте. Әсәрнең сәхнә тарихы.<br>М.Җәлилнең әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышлап язган мәкаләләре.<br>Бөек Ватан сугышы елларында М.Җәлилнең көрәше һәм иҗаты. “Тупчы анты” (1942) җыентыгына кергән әсәрләренең төп пафосы, сәнгатьлелек дәрәҗәсе, актуальлеге. М.Җәлил – хәрби корреспондент, сугышчы, шагыйрь. |

| | | |
|---|---|---|
| | | М.Җәлилнең әсирлек шартларындагы шигъри һәм гражданлык батырлыгы. “Моабит дәфтәре” җыентыгы. Шигырьләрендә патриот шагыйрьнең лирик образы. Әсәрләрдәге конфликт, аларның кискенлеге. Биредә тупланган әсәрләрнең темасы – коммунист шагыйрьнең туган илгә, халыкка биргән антына тугрылыгын, рухи көчен күрсәтү. “Җырларым”, “Ышанма”, “Кичер, илем”, “Кошчык”, “Ирек” әсәрләрендә кичерешләр, коммунистик идеялелеген күрсәтүдә “Егет көче”, “Үлемгә”, “Катыйльгә” һ.б. әсәрләре. “Ана бәйрәме”, “Сандугач һәм чишмә” балладаларының идея-эстетик көче. Аллегорик образлар тудыруда М.Җәлилнең новаторлыгы. Лирик герой уйларындагы фәлсәфи тирәнлек.<br>Фашизмның ерткыч асылын, кешелек дошманы булуын аяусыз фаш итүдә “Бүреләр”, “Вәхшәт”, “Сакчы” һ.б. әсәрләре. Совет солдатының гуманизм һәм фашистларның кабахәтлеген ачуда шагыйрь кулланган контрастлык чаралары. “Моабит дәфтәре”ндә интернационализм идеясе. Шагыйрьнең киләчәккә ышаныч белән каравын белдергән “Сугыштан соң”, “Төзүче”, “Яңа ел теләкләре”, “Шатлыкны каршылап” шигырьләре. Юмористик шигырьләре: “Хәдичә”, “Томаулы гыйшык”, “Гашыйк һәм сыер”, “Табут”, “тозлы балык”, “Борча” һ.б.<br>“Моабит дәфтәре”нең совет һәм дөнья әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше. Муса Җәлил иҗаты турында илебез һәм чит ил язучылары, галимнәре. |
| 6.5 | Творчество Фатиха Карима | 20 нче еллар уртасында шигърияткә килеп, яңа тормышка, яшьләргә, хезмәткә дан җырлавы; комсомол рухы алып килүе. Төрле вакыйгаларга мөнәсәбәтен шигырь аша белдерүе, укучыга ниндидер хәбәр җиткерү формасында язуы. Көрәш дәрте белән мавыгу, декоратив сөйләүгә, коры риторикага, яңа формалар белән мавыгуга китерүе; образлылык кимүе, сүрәт чаралары ярлылануы («Безнең һәйкәл», «Закон). 30 нчы елларда шигъри осталыгы, әдәби зәвыгы үсүе, киңәю; шигыръләрендә лирик җылылык, мөләемлык, табигыйлек артуы («Зәйтүнә», «Беренче бала», «Кемгә сөйлим серләремне»). Бу чор иҗатының төп тема-мотивлары: социалистик хезмәт, бәхетле киләчәк, совет кешесенең гуманистик сыйфатлары («Җиденче мич», «Тавышлы таң»); илне саклау («Чайка башыңны», «Пулеметчы», «Аникин»). Тоткынлык чоры иҗаты (1938-1941). Әсәрләрендә тоткынлыкның ачы газабы, рәнҗетелү хисләре өстенлек итү («Я көн генә була, я төн генә...»). Шигырьләренең төп мотивлары: лирик геройның борчылуы, сыкрануы ңәм якыннарын, туган җирен сагыну хисләре («Ант», «Көзге яңгырлы төн»). Лирик геройның, ялгыз калып, хатыны,балалары турында уйлануы («Кадрия», «Сагынып кайтам сине»). |

| | | |
|---|---|---|
| | | Символик образларга, чагыштыру, арттыру, антитеза һ.б. алымнарга иркен мөрәҗәгать итүе («Кыр казы»).<br>Сугыш чоры иҗаты (1941-1945). Җиңүгә тирән ышаныч белән илен сакларга ант итү («Ант»). Лирик геройның рухи дөньясы баю, ул кешелекле, нык ихтыярлы («Теләк», «Иптәш»). Яшәү һәм үлем турында фәлсәфи уйлануы («Сөйләр сүзләр бик күп алар...»). Фашизмга нәфрәт, ләгънәт яңгырау («Бездә яздыр»). Тыл тормышы, фронт һәм тыл бердәмлеге («Сагынып көтәм», «Газиз әнкәй»). Поэма һәм баллада жанрларында иҗаты иң югары ноктага җитү («Гөлсем», «Идел егете», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Үлем уены», «Партизан хатыны», «Өмет йолдызы», «Тимер һәм тимерче». Прозада һәм драматургиядә сугыш афәтен, совет солдатының батырлыгын күрсәтү («Язгы төндә», «Разведчик язмалары» повестьлары, «Шакир Шигаев» пьесасы). |
| **7** | **Раздел 6. Татарская литература 40-65-х годов XX века** | |
| 7.1 | Поэзия 40-65-х годов | Сугыштан соңгы әдәбият (1945-1965).<br>Тыныч хезмәткә күчүнең беренче елларында әдәбият алдында торган яңа бурычлар. Татарстан язучыларының икенче (1950) һәм өченче (1954) съездларының әдәби хәрәкәттәге әһәмияте.<br>Тоталитар җәмгыятьнең катгый сәяси катып калган таләпләре өстенлек иткән шартларда әдәбият үсешендәге кыенлыклар. Әдәбият, сәнгатьтә «космополитик» күренешләрен гаепләү. «Конфликтсызлык» теориясе. Уңай герой, заман темасы.<br>Шәхескә табыну күренешләренең әдәбият үсешенә тискәре йогынтысы. Әсәрләрдә тема ярлылыгы. Күп яктан чикләнгән, кыен шартларда татар әдәбияты ирешкән кайбер уңышлар. Прозада «Тукай» (Ә.Фәйзи), «Намус» (Г.Бәширов), «Рәхмәт, иптәшләр» (Ә.Еники) кебек уңышлы әсәрләрнең дөнья күрүе.<br>Илленче еллар уртасында шәхескә табыну күренешләрен фаш итү. Моның әдәбият үсешенә уңай йогынтысы. Әдәбиятның катгый, катып калган таләпләр чикләреннән котыла башлавы. 50 нче еллар уртасында М.Җәлил һәм репрессияләнгән әдипләрнең (Г.Ибраһимов, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Ш.Усманов, Ф.Сәйфи-Казанлы, Х.Туфан, С.Рәфыйков һ.б.) иҗаты халыкка кайту.<br>Әдәби тормышта дискуссия һәм бәхәсләрнең, ачыктан-ачык сөйләшү рухының көчәюе.<br>Әдәби тәнкыйтьтә кимчелекләрне кыю ачкан мәкаләләр күренә башлау. |
| 7.2 | Проза 40-65-х годов | Татар прозасында үзгәртеп кору процессын чагылдырган әсәрләрнең дөнья күрә башлавы. А.Гыйләҗев, М.Хәсәнов, М.Мәһдиев, һ.б. язучыларның яңа роман һәм повестьлары, драмалары һәм поэмалары. М.Хәсәновның «Язгы аҗаган» романында сурәтләнгән образлар. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Темалар һәм жанр ягыннан төрлелеге.Фронттагы һәм тылдагы батырлык (Г.Әпсәләмов. Газинур; Г.Бәширов. Намус; М.Әмир. Саф күңел). Дошман әсирлегендәге хәлләрне, фаҗигале язмышларны сурәтләү (Н.Дәүли. Яшәү белән үлем арасында; Г.Әпсәләмов. Мәңгелек кеше). Тыныч тормышны сурәтләүдә заман рухының тирәнәюе (Ә.Еники. Саз чәчәге. Рәшә; Ф.Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы; И.Гази. Гади кешеләр). Тарихка мөрәҗәгать итү (К.Нәҗми. Язгы җилләр; И.Гази. Онытылмас еллар; Ә.Фәйзи. Тукай). Хикәя (Ә.Еники. Кем җырлады?; А.Шамов. Миңнур карт). Повесть (Г.Әпсәләмов. Ак төннәр; Н.Дәүли. Яшәү белән үлем арасында; Ә.Еники. Саз чәчәге). Роман (Г.Әпсәләмов. Газинур. Алтын йолдыз; Г.Бәширов. Намус). Тарихи роман (К.Нәҗми. Язгы җилләр; И.Гази.Онытылмас еллар). Тарихи-биографик роман (Ә.Фәйзи. Тукай). Роман һәм повесть өлкәсендә эзләнүләрнең көчәюе. Прозада сюжет-композиция, тел-сурәт өлкәләрендә эзләнүләр. Иҗат көчләре мәсьәләләре. Үсеш проблемалары.<br>Үзгәртеп коруның драматургиядә зур җанлану тудыруы. Тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть, ачыктан-ачык сөйләшү рухының әдәби хәрәкәткә үтеп керүе. Язучыларның иҗтимагый-политик тормышта актив катнашулары. Язучылар күтәргән актуаль мәсьәләләр буенча дәүләт күләмендә әһәмиятле карарлар кабул ителү. Героик һәм тарихи-революцион тема. |
| 7.3 | Драматургия 40-65-х годов XX века | Драматургиядә замандаш герой проблемасы. Драматургларның индивидуаль стильләре камилләшү. "Муса" (Н.Исәнбәт); "Давылга табан", "Үлмәс җыр" (Р.Ишморат); Шамил Усманов, А.Яхин, А.Гыйләҗев пьесалары. |
| **8** | **Раздел 8. Татарская литература 65-85-х годов XX века** | |
| 8.1 | Поэзия 65-85-х годов XX века | 1965-85 еллар әдәбияты. Идеологик басымның кимүе. Чынбарлыкны күпъяклы һәм дөреслек белән сурәтләү тенденциясенең көчәя баруы. Эпик колач киңәю. Прозаның төп темалары. Тарихи темаларны яктырту. Традицион авыл темасын сурәтләү үзенчәлекләре. Ватан сугышы темасын яктыртудагы яңалыклар. Заман темасын яктыртуда яңалыклар. (Г.Ахунов, Н.Фәттах, Ф.Хөсни, Ә.Еники, М.Мәһдиев, Р.Төхвәтуллин һ.б.). «Хрущев җепшеклеге» исеме белән тарихка кергән хәбәрдарлык, демократия күренешләренең 60 нчы еллар әдәбият-сәнгатенә уңай йогынты ясавы; идеологик басымның бераз кимүе, әмма тиздән партия йогынтысы яшәешнең бөтен өлкәләренә үтеп керүе; ил тормышында торгынлык чоры башланауы.<br>Милләтләр дуслыгы, интернационализм идеяләре җирлегендә совет халкы формалашуы; рус теленең зур тизлек белән башка телләрне аралашудан кысрыклап чыгаруы. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Талантлы каләм ияләренең, хакимият идеологиясен читләтеп үтеп, әдәбиятының эстетик асылына мөрәҗәгать итүе, халыкның гасырлар дәвамында тупланып килгән әхлакый кыйммәтләрен яклап чыгуы һәм сәнгати югары әсәрләр иҗат итүе (Ә.Еники.Әйтелмәгән васыять. Туган туфрак; А.Гыйләҗев. Өч аршын җир. Җомга көн кич белән; Т.Миңнуллин. Әлдермештән Әлмәндәр һ.б. Әсәрләрендә социалистик җәмгыятенең чын асылы ачылуы, эзоп теле белән тәнкыйть ителүе; кеше һәм система каршылыгы әдәби чаралар ярдәмендә тасвирлануы (А.Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә; Ә.Баянов. Тау ягы повесте һ.б.). С.Хәким, Т.Миңнуллин Россия Дәүләт бүләгенә лаек булулары; иң уңышлы әсәрләре рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителүе.<br>Поэзиядә уйланучан башлангычның көчәюе, лирик каһарманның рухи дөньясы катлаулануы, зиһен һәм фикер эшчәнлеген тулырак ачарга омтылыш. Замандашыбызның рухи тәҗрибәсен тулырак ачкан олы образын тудыруда төп юнәлешләр, идея-тематик үзгәрешләр. Кеше шәхесенә игътибар арту. Лирик агымның көчәюе. Өлкән буын шагыйрьләренең иҗат активлыгы үсүе (Х.Туфан, С.Хәким, Ш.Маннур, М.Садрый, З.Нури, Н.Арсланов һ.б).<br>Ә.Давыдов һәм З.Маннур иҗаты. Тарихи-революцион тематика һәм поэтик М.Ногман поэмалары. И.Юзиев, Ш.Галиев, Х.Камал, Г.Афзал поэзияләренең үзенчәлекләре. Поэзия өлкәсендә эзләнүләр. Яңа буын шагыйрьләрнең әдәбиятка килүе (Ә.Баянов, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалимов, Р.Гатауллин). Җыр һәм романслар (С.Хәким, Н.Арсланов, М.Ногман, Г.Зәйнәшева, Л.Айтуганов, Р.Әхмәтҗанов, М.Әгъләмов). Поэзиядә сатира һәм юмор. Декларативлыкка, схематизмга, шаблонлыкка каршы көрәш. Поэтик жанрлар ңәм аларның үсешендәге яңалыклар. Традицияләр һәм новаторлык мәсьәләре.<br>Лиро-эпик жанрның үсеш-үзгәреш кичерүе.<br>Баллада (Зөлфәт. Ике ат турында баллада. Фатыйма. Кара күбәләк; М.Галиев. Чишмә караучы карт; И.Юзеев. Унөченче; Р.Әхмәтҗанов. Таш елады). Эпик поэма (С.Хәким. Кырыгынчы бүлмә; И.Юзеев. Әнкәй. Өчәү чыктык ерак юлга; Ә.Баян. Сәяхәтнамә; М.Әгъләмов. Тукайдан хатлар). Шигъри роман (С.Баттал.Чирмешән якларында; Ә. Давыдов. Йокысыз төннән соң). Оратория (Р.Харис. Кеше). Либретто (Г.Рәхим. Каһәрләнгән мәхәббәт).<br>Табигый хис-тойгылар чагылыш тапкан лирик шигырьләр, көйгә салынып, киң яңгыраш алган җырлар булып китүе (С.Хәким. Башка берни дә кирәкми; Ш.Галиев. Раушаниям, бәгърем; И.Юзеев. Яшь наратлар. Мәтрүшкәләр; Г.Зәйнашева. Китмә, сандугач; Р.Фәйзуллин. Аккошлар; Р.Вәлиев. Зинһар өчен кермә |

| | | |
|---|---|---|
| | | төшләремә һ.б.).<br>Г.Афзалның тормыш һәм иҗат юлы.<br>Г.Афзалның шигъри таланты. Шагыйрь поэзиясендә табигать культы (“Бу кырларда”, “Апрель җиле!, “Кышкы урман” һ.б.).<br>Сюжетлы шигырьләрендә комик типлар тудыру осталыгы (“Сәләхетдин бабай сүзләре”, “Сабирҗан хаты”, “Шәрифулла күршем белән”).<br>Сатирик поэзиянең төрле формаларына, жанрларына мөрәҗәгать итүе: фельетон, памфлет, мәсәл, җыр, эпиграмма, диалог, монолог һ.б.<br>Г.Афзал сатирасының төп үзенчәлеге булып халык иҗаты традицияләренең, чичәнлек рухының көчле булуы.<br>И.Юзеев иҗаты. Шагыйрьнең рус (“Последнее испытание”, “Маленький рыжий кони”) һәм башкорт (“Язылмаган поэма”) телләренә тәрҗемә ителгән китаплары. Башлангыч чор иҗатында (шигырьләренең ритмикасында, сөйләм интонациясендә, лирик чигенешләрдә, композиция төзелешендә) Такташ йогынтысы. Шул җирлектә поэзиянең иң күркәм романтик һәм реалистик традицияләрен дәвам итүе.<br>Поэмаларда уңышлы эшләве. И.Юзеев иҗатында лиро-эпик жанр, үсеш-үзгәреш кичереп, эпик вакыйгаларны кичерешләр байлыгы аша сурәтләү мөмкинлеге артуы сизелә. Тематик киңлек күзәтелү.<br>Поэмаларда стилистик төрлелек. Сюжетка корылган (“Фәрит-Фәридә”); лирик монолог (“Тормыш җиңә”); драматик легенда (“Соңгы сынау”); шигырь, дастан, парча, лирик чигенү, балладалар циклы (“Мәхәббәт китабы”); документальлек (“Таш диварлар авазы”).<br>И.Юзеев драматургиясендә лирик агымның, романтик пафосның көчле булуы, җыр, музыка белән үрелеп килүе. Жанрлар төрлелеге: “Резидәкәй” (музыкальпьеса), “Сандугачлар килгән безгә” (драма), “Командировка” (моңсу комедия), “Очты дөнья читлегеннән”, “Соңгы төн” (тарихи-революцион трагедия) һ.б.<br>И.Юзеев – комедияләр остасы (“Мәкәрҗәгә барган идек”, “Кайтмый калсам – көтәрсеңме?” һ.б.).<br>Р.Фәйзуллин иҗаты. Кыска шигырьләр язу, “сүз белән рәсем ясау” осталыгы. Аларга тирән мәгънә, фәлсәфи эчтәлек салып халыкны тапкырлык, зирәклек юнәлешендә тәрбияләү һәм кыска үткен форманы үстерүдә уңышлары. Дөнья поэзиясендәге барлык төшенчәләрнең – намус, тугрылык, дуслык-туганлык, рух азатлыгы, бәйсезлек, коммунарлар, Буратино, ырымнар, Аллага табыну, иман ныклыгы, палач балталары, лазерлар, тәхетләр, хөкемдарлар, яшәү-сәгадәт, өмет-ышанычлар – барысының да поэмаларда урын алуы.<br>Р.Фәйзуллинның җыр жанрында, публицистикада, балалар әдәбиятында нәтиҗәле эшләве. Кол Гали, Тукай, |

| | | |
|---|---|---|
| | | Кутуй, Туфан иҗатына багышланып язылган монографик характерда хезмәтләре.<br>Поэмаларның жанр төрлелеге: “Көрәшчеләр” (фәлсәфи), “Сәйдәш” (шигъри повесть). Әдәби – публицистик мәкаләләре, иҗат портретлары. |
| 8.2 | Проза 65-85-х годов XX века | Чынбарлыкны күпъяклы һәм дөреслек белән сурәтләү тенденциясенең көчәя баруы. Эпик колач киңәю. Прозаның төп темалары. Тарихи темаларны яктырту. И.Газиның «Онытылмас еллар», Ф.Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романнарында халык тормышын яктыртудагы яңалыклар. Татар халкының үткәнендәге иҗтимагый-рухи тормышын һәм үсешен яктыртуда Н.Фәттахның «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар»; Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәрләре. Үткәндәге бөек тарихи шәхесләрне гәүдәләндерүдә А.Расихның «Ямашев»; Г.Шәрипованың «Гафур гаиләсе»; Җ.Тәрҗемәновның «Көмеш дага» романнары. Традицион авыл темасын сурәтләү үзенчәлекләре. Ф.Хөснинең «Утызынчы ел», Р.Рафиковның «Беренче яз», М.Хәсәновның «Язгы аҗаган» романнарында авылны коллективлаштыру проблемасы гәүдәләнеше. Кеше язмышына игътибар арту. «Язгы авазлар» (А.Расих), «Йолдызым» (Р.Төхватуллин), «Яшлегемне эзлим» (Ә.Баянов), «Берәү», «Күпер чыкканда» (В. Нуруллин), әсәрләрендә сугыштан соңгы авылның үсеш кыенлыклары. Шул елларда яшь кеше үсеше, формалашуы «Без 1941 ел балалары», «Фронтовиклар» (М.Мәһдиев), «Шинельсез солдатлар» (В.Нуруллин), «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турындагы хикәят» (А.Гыйләҗев) әсәрләрендә чагылу. Фәнни-техник революция һәм хәзерге авыл проблемаларының әдәбиятта гәүдәләнеше (Г.Бәширов «Җидегән чишмә»; Ә.Еники «Әйтелмәгән васыять»; М.Хәбибуллин «Чоңгыллар»; Х.Хәйруллин «Канатлар талмасын»).<br>Ватан сугышы темасын яктыртудагы яңалыклар. Г.Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше»; Ш.Маннурның «Муса»; Н.Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында»; Х.Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр»; М.Юнысның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна»; Ш.Рәкыйповның «Кайдан син Җан?», «Кызлар-йолдызлар» әсәрләре.<br>Заман темасын яктыртуда яңалыклар.<br>Эшчеләр темасын яктырту. «Сүнмәс утлар» (Г.Әпсәләмов), «Хәзинә», «Хуҗалар», (Г.Ахунов), «Тын елга буенда» (С.Рафиков), «Зәй энҗелре» (А. Гыйләҗев), «Ут һәм су» (Ә.Баянов, «Каты токым» ( Ш. Бикчурин) әсәрләре. Мораль – әхлак проблемаларына игътибар арту. Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» повесте, А.Расихның «Сынау» романы. Интеллигенция тормышын яктыртуда үзенчәлекләр (А.Расих «Ике |

| | | |
|---|---|---|
| | | буйдак»; Г.Әпсәләмов «Ак чәчәкләр», «Яшел яр»; А.Гыйләҗев «Урамнар артында яшел болын»). Роман һәм повесть өлкәсендә көчәюе. Прозада сюжет-композиция, тел-сурәт өлкәләрендә эзләнүләр. Иҗат көчләре мәсьәләре. Үсеш проблемалары. Тематик киңлек күзәтелүе. Татар халкының үткән тарихын, иҗтимагый-рухи тормышын аңларга омтылу (Н.Фәттах. Әтил суы ака торур. Сызгыра торган уклар; М.Хәбибуллин. Кубрат хан һ.б.).<br>Совет хакимиятенең төрле чорларында татар авылы кешеләрен сурәтләү, аларның яшәү рәвеше (Ф.Хөсни. Утызынчы ел; А.Гыйләҗев. Язгы кәрваннар; Г.Ахунов. Чикләвек төше; М.Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары. Кеше китә – җыры кала).<br>Бөек Ватан сугышы елларының каршылыкларын, фаҗигале вакыйга-хәлләрен яңа чор биеклегеннән бәяләү (Х.Камалов. Һәркемнең гомере бер генә; Ш.Рәкыйпов. Кайдан син, Жан? Кызлар-йолдызлар; М.Юныс. Шәмдәлләрдә генә утлар яна һ.б.)<br>Эшчеләр тормышы, производство мәсьәләләре (Г.Ахунов. Хәинә. Хуҗалар; А.Гыйләҗев. Зәй энҗеләре; Ә.Баянов. Ут һәм су).<br>Халкыбызга хас гадәт-йолаларның кимүе, әдип-әхлакның бозылуы өчен борчылу (Ә.Еники. Әйтелмәгән васыять; Х.Сарьян. Бер ананың биш улы; А.Расих. Сагыну; А.Гыйләҗев.Җомга көн кич белән һ.б.).<br>Фән кешеләре, зыялылар тормышын рухи-психологик планда ачу (А.Расих. Ике буйдак; Г.Әпсәләмов. Ак чәчәкләр. Яшел яр; А.Гыйләҗев. Урамнар артында яшел болын. Урталыкта һ.б.). |
| 8.3 | Драматургия 65-85-х годов XX века | Драматургиядә замандаш герой проблемасы.<br>Хәзерге драма иҗаты үсешендәге мөһим тенденцияләр, сыйфатлар. Мораль башлангычның көчәюе, сюжетта гадиллеккә омтылу, конфликтларның әхлакый планга корылу, фикер тыгызлыгы һәм үткенлеге, интеллектуальлек өстенлек алу.<br>Р.Ишморат («Яңа бистәдә»), Г.Насрый («Кадерле минутлар»), Н.Исәнбәт («Гүзәл») һ.б. драматурглар иҗатында кешеләр арасындагы яңа мөнәсәбәтләр проблемасы. Кеше психологиясен ачуның яңа чараларын эзләү. Ф.Хөсни һәм М.Әмир драмалары. Героик һәм тарихи-революцион тема. «Муса» (Н. Исәнбәт), «Давылга таба», «Үлмәс җыр» (Р.Ишморат), «Шамил Усманов» (А.Яхин, А.Гыйләҗев) пьесалары.<br>Драматургларның индивидуаль стильләре камилләшү.<br>Х.Вахит драматургиясенең төп сыйфатлары. «Беренче мәхәббәт», «Соңгы хат», «Туй алдыннан» әсәрләрендә яшьләр һәм әхлах проблемалары.<br>Ш.Хөсәеновның драма иҗатында чынбарлыкны сурәтләү үзенчәлекләре. «Зөбәйдә–адәм баласы», «Әни килде» әсәләренең художество эшләнеше. |

| | | |
|---|---|---|
| 8. | | Әдәби төрләр, жанрлар, жанр формалары үсеше. Бу чор сәхнә әдәбиятында чын мәгънәсендә халыкчан образ-характерлар, замандаш сыйфатларын үзләрен туплаган типлар мәйданга чыгуы (Ш.Хөсәеновның «Әни килде» әсәрендә Ана, Т.Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәрендә Мәдинә, «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә Әлмәндәр, И.Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» әсәрендә Хәмзин һ.б.). Х.Вахит – шагыйрь: «Безнең авыл», «Якты юллар», «Яз килә» җыентыклары. Либреттолар авторы: «Самат», «Дим буенда», «Җиһангир». Х.Вахит – үзенчәлекле драматург: «Беренче мәхәббәт», «Рәхим итегез», «Илһамия», «Карлыгач канат җәя», «Соңгы хат», «Туй алдыннан»,» «Мәхәббәтең чын булса», «Онытa алмасаң нишләрсең» һ.б. Драматургның сюжет төзү остасы булып танылуы, аның нигезен тәшкил иткән конфликт тормышчанлыгы, әхлакый һәм фәлсәфи киңлеге белән аерылып торуы. Җыр-музыка пьесаларының лейтмотивына әйләнүе. Тәрбия, әхлак мәсьәләләре, матур рухи башлангычларны яклавы, тормыштагы ямьсез күренешләрне, кешеләрдәге һәртөрле кимчелекләрне тәнкыйтьләве. Яшьлек темасы, яшь геройларның зур тормышка килү юлы, характеры формалашу шартлары, хезмәткә, мәхәббәткә, дуслыкка мөнәсәбәтләре кызыксындыруы. Художестволы форма һәм стиль өлкәсендәге эзләнүләр. Романтик сурәтлелек, музыкальлек, тамашалыкны яңа баскычка күтәреп, күпсанлы әдәбият-сәнгать сөючеләрне театр белән кызыксынуга этәрүе. |
| 8.4 | Пути и основные тенденции развития татарской литературы конца XX века | Сәнгатьнең бер тере буларак гасыр кичеше әдәбияты. Яшәешнең, дөньяның һәрвакыт үзгәрештә булуы, чорның әдәбият үсешенә, иҗат кешеләренең рухи-фикри эзләнүләренә тәэсир иткән соңгы ике дистә ел эчендәге әһәмиятле вакыйгалары. XX-XX1 гасыр цивилизациясе һәм мәдәнияте контекстында хәзерге татар әдәбияты. |
| 8.5 | Татарская поэзия в контексте общественно-исторических реалий | Җәмгыятьтә яңа иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр. Әдәбиятыбыздагы “ак тап”лар. Татар әдбәбият беле галимнәренең эшчәнлеге (И. Нуруллин, Ф.Хатипов, Ф Мусин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Сверигин, Ф.Галимуллин, Г. Гыйльман, М Вәлиев). |
| 8.6 | Новые направления в татарской прозе конца XX века | XX гасыр ахыры татар прозасы: стиль тенденцияләре, жанрлар төрлелеге: реалистик, романтик юнәлешләр, интеллектуаль тенденция, экзистенциаль фикерләү төре, неомифологизм. |
| 8.7 | Драматургия  и театр конца XX века | Гасыр ахыры татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре. Т.Миңнуллин, З.Хәким, Аманулла, И.Зәйниев, Д.Салихов, Р.Зәйдулла иҗаты. |
| **9** | **Раздел 9. Современная татарская литература** | |
| 9.1 | Современные тенденции развития татарской поэзии | Хәзерге татар поэзиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре, алшартлары. Хәзерге татар поэзиясендә реалистик юнәлеш. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Хәзерге татар поэзиясендә романтик юнәлеш. Соңгы еллар татар поэзиясендә интеллектуаль тенденция, модерн алымнар. Р.Харис иҗаты (1943). З.Мансуров иҗаты (1949). Р.Зәйдулла иҗаты. Яңа буын шагыйрьләр иҗаты. |
| 9.2 | Разнообразие литературных направлений и течений в татарской прозе | М.Кәбиров әсәрләрендә постмодернистик алымнар. Хәзерге татар прозасында интеллектуаль тенденция. (М.Кәбировның “Сары йортлар сере” повесте). Хәзерге татар прозасында концептуализм күренеше (Г.Гыйльманның “Оча торган кешеләр” әсәре мисалында). Хәзерге татар прозасында мифологик катламның вазифасы. (Н.Гыймадинова повестьлары). XXI йөз башы татар прозасында реалистик роман жанры. (З.Хәкимнең Бөек Ватан сугышы елларында совет коллаборационизмы темасына караган “Легионер” романында экзистенциаль мотив). |
| 9.3 | Основные тенденции и закономерности развития татарской драматургии | Хәзерге татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре. Т.Миңнуллин, З.Хәким, Аманулла, И.Зәйниев, Д.Салихов, Р.Зәйдулла иҗаты. “Яңа татар пьесасы” конкурсының татар драматургия үсешенә йогынтысы. Татар театрлары, аларның репертуары. Театраль фестивальләр. |

## 5. Учебно-методическое обеспечение для самостоятельной работы обучающихся по дисциплине (модулю)

Учебно-методическое обеспечение для самостоятельной работы обучающихся по дисциплине (модулю)

### Перечень вопросов для экзамена:

**1 курс, 2 семестр**

1. Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятын гыйльми өйрәнү тарихы.
2. Төрки-татар әдәбиятының төп чыганаклары: мифология һәм фольклор, рун язулы истәлекләр, сүзлекләр һ.б.
3. Борынгы төркиләр. Аларда язу барлыкка килү мәсьәләсе. Туран (һун), рун һәм уйгур графикаларындагы борынгы ядкарьләр.
4. Ислам дине белән берлектә төркиләргә гарәп язуының керүе. «Коръән» һәм татар әдәбияты.
5. Мәхмүд Кашгарийның «Диване лөгатет-төрк» (1072-1074) хезмәтенә гомуми күзәтү.
6. Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» (1069) поэмасы  борынгы төрки әдәбиятның тиңсез ядкяре.

7. Әхмәд Йүгнәки (XII йөз). Аның дидактик характердагы «Һибәтел-хакаик» («Хаклыклар бүлеге») поэмасы.

8. Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый  төрки суфыйчылык шигъриятенең күренекле вәкилләре. Аларның иҗатына гомуми күзәтү.

9. Кол Гали һәм аның «Кыйссаи Йосыф» дастаны. Авторның тәрҗәмәи хәле. «Кыйссаи Йосыф» китабының язылу вакыты, кулъязма һәм басма нөхәләре, өйрәнелү тарихы.

10.«Кыйссаи Йосыф» сюжетының һәм образларның мифология, фольклор, изге китаплар, Шәрык язма әдәбияты белән бәйләнешле булуы. Йосыф темасына язылган әсәрләр. Кол Гали әсәренең сюжеты, төзелеше. Күтәрелгән мәсьәләләр. Йосыф, Зөләйха образларының бирелеше.

11.Алтын Урда чорында әдәбият. Чорга тарихи-мәдәни күзәтү. Ибне Батута, Ибне Гарәбшаһ һәм кайбер башка чит ил сәяхәтчеләренең язмалары. Мисыр мәмлүкләре хакында белешмә.

12.Алтын Урдага бәйле язма истәлекләр: ярлыклар, каберташ язмалары, сүзлекләр, сәяхәтнамәләр, фәнни һәм әдәби ядкярләр. «Коман мәҗмугасы» сүзлеге. Андагы табышмаклар.

13.Алтын Урда чоры төрки-татар әдәбиятына хас сыйфатлар. Суфыйчылык, аның фәлс´фи-эстетик асылы, татар әдәбиятында гәүдәләнеше. Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия»(1310) китабы. Аның төзелеше, кыйссалары, образлары, идея-эстетик үзенчәлекләре, халыкта киң таралышы.

14.Котб һәм аның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре. Шагыйрьнең тормышы хакында фикерләр.

15.Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәренең басылу, өйрәнелү тарихы. Әсәрнең сюжеты. Котб «Хөсрәү вә Ширин»нең идея - эстетик үзенчәлекләре, образлары, жанр хосусияте.

16.Харәзми (XIV йөз). Шагыйрьнең фарсыча һәм төркичә иҗат итүе. «Мәхәббәтнамә» поэмасы. «Мәхәббәтнамә» поэмасының үзенчәлекле төзелеше. Әсәрдә мәхәббәткә дан җырлау.

17.Мәхмүд Болгари «Нәһҗел-фәрадис» әсәре. Аның кулъязмалары, басмалары, өйрәнелү тарихы.

18.Хисам Кятиб һәм аның «Җөмҗөмә солтан» дастаны. Авторы, әсәрнең язылу, таралу, басылу һәм өйрәнелү тарихы хакында мәгълүматлар. Дастанның борынгы легендага нигезләнгән сюжеты, образлары. Әсәрнең төзелеше, идея эчтәлеге.

19.Сәйф Сараиның иҗат мирасын тупланган «Китабе Гөлестан бит-төрки», «Ядгярнамә» кулъязмалары. Аларның төзелү, саклану, өйрәнелү, басылу тарихы.

20.«Гөлестан бит-төрки» әсәре. Аның фарсы телендәге «Гөлестан»га нигезләнеп язылуы.

21.Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны. Дастанның эчтәлеге, идея-эстетик табигате.

22.«Идегәй» дастаны, аның вариантлары, таралышы, өйрәнелүе һәм басылу тарихы.

23.«Идегәй» әсәренең тарихи нигезе, төп сюжеты, образлары. Идегәйнең каршылыклы язмышы.

24.«Кисекбаш» дастаны. Аның сюжеты, образлары, эстетик үзенчәлеге.

25.«Кисекбаш» дастанындагы инсани идеяләр.

26.Сайядинең «Бабахан дастаны» – төрки халыкларның уртак мирасы. Татар әдәбиятында бу сюжетка язылган башка әсәрләрләр.

27.Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек кыйссасы». Әсәрнең сюжет чыганаклары, вариантлары, сәнгатьчә үзенчәлеге.

28.Шәриф Гамидинең «Төрки Шаһнамә» әсәре. Эчтәлеге, идея-эстетик кыйммәте, әдәби-тарихи әһәмияте. «Төрки Шаһнамә» әсәре һәм Мәмлүкләр Мисыры.

29.Казан ханлыгы чоры татар әдәбиятының тарихи-хронологик чикләре. Казан ханлыгы чорында фольклор әсәрләре һәм язма истәлекләр (ярлыклар, кабер таш язмалары).

30.Казан ханлыгы чоры шагыйрьләре (Хәсән Кайгы, Казтуган, Дүсмәмбәт, Мөхәммәд Әмин). Казан ханлыгы чоры шагыйре, рухани һәм җәмәгать эшлеклесе Колшәриф.

31.«Бакырган китабы» һәм анда кергән шагыйрьләрнең дини-суфыйчыл әсәрләре.

32.Өмми Кәмалның иҗади мирасы. Аның басылу һәм өйрәнелү тарихы.

33.Өмми Кәмал шигырьләрендә дини-суфыйчыл мотивлар, аларның поэтик камиллеге, жанр төрлелеге.

34.Мөхәммәдъяр Мәхмүт Хаҗи углының тормыш юлы, иҗат мирасы.

35.Мөхәммәдъяр Мәхмүт Хаҗи углының «Нәсихәт» әсәре.

36.Мөхәммәдъяр Мәхмүт Хаҗи углының «Төхфәи мәрдан» поэмасы. Аның сюжет үзенчәлеге, образлары.

37.Мөхәммәдъяр Мәхмүт Хаҗи углының «Нуры содур» поэмасы.

38.XVII йөз татар әдәбиятына күзәтү. Бәетләр, васыятьнамәләр, тәрҗемә-шәрехләр.

39.XVII- XVIII йөздәге әдәби әсәрләр. Кадир Галибәкнең «Җәмигъ эт-тәварих» җыентыгы. Аның төзелеше, идея эчтәлеге, әдәби үзенчәлеләре.

40.Шәрәфетдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» әсәре.

41.Суфый Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин» әсәре һәм аның дини-суфыйчыл эчтәлектә булуы.

42.Мәүла Колыйның тәрҗемәи хәле һәм иҗади мирасы. Шагыйрь хикмәтләренең идея-тематикасы һәм сәнгати үзенчәлекләре.

43.Котб һәм аның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре. Поэмада хатын-кыз образларының гәүдәләнеше.

44.XVIII йөз татар әдәбиятына тарихи-мәдәни күзәтү. XVIII йөздә халык тормышы һәм көнкүрешенең авыз иҗаты әсәрләрендә чагылышы.

45.XVIII йөз татар әдәбиятында жанрлар төрлелелеге.

46.XVIII йөз татар әдәбиятының тарихи һәм әдәби ядкяре буларак «Батырша хаты».

47.XVIII йөз татар әдәбиятында хикәят жанры. «Мәҗмугыл хикәят» җыентыгы.

48.«Мәҗмугыл хикәят» тәге хикәятләрнең жанр үзенчәлекләре, сюжет корылышы, образлары, идея-эстетик табигате.

49.XVIII йөз татар әдәбиятында жанрлар (сәяхәтнамә, хикәят, илаһи бәет, мәдхия-мәрсия).

50.XVIII йөздә иҗат иткән әдипләр. Габдессәлам иҗаты.

51.Габдессәламның тормышы һәм иҗат юлы. Шигырьләренең халык җырларына якынлыгы, тел-сурәтләү чараларына байлыгы.

52.XVIII йөздә иҗат иткән әдипләр. Габделмәннан Мөслим углы, Әхмәдбик иҗаты.

53.Таҗетдин Ялчыголның иҗаты һәм аның «Тәварихе Болгария» әсәре.

54.Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» әсәре. Аның дини-әхлакый эчтәлеге.

55.Габдерәхим Утыз Имәнинең тормыш юлы һәм иҗаты. Габдерәхим Утыз Имәнинең поэмалары (Гаварифез-заман», «Мөһимматез-заман», Горбәтнамә»).

56.Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятында нәзирәчелек. Новаторлык һәм традицияләр бердәмлеге мәсьәләсе.

**2 курс 4 семестр**

**Вопросы для зачета**

1. XIX гасыр татар әдәбиятының тарихи-хронологик чикләре. Иҗтимагый-тарихи вакыйгалар һәм әдәби хәрәкәт.

2. Казан университеты ачылу һәм аның татар тормышына ясаган йогынтысы. Казан университеты галимнәре И.Хәлфин һәм Г.Мәхмүдов. Кульязма әдәби-тарихи ядкярләрне бастыру.

3. Көнчыгышны өйрәнү фәненең үсеше. Көнчыгышны өйрәнече рус галимнәренең (И.Н.Березин, К.А.Фукс һ.б.) хезмәтләре.

4. XIX гасыр башында культура һәм фикер өлкәсендә ислам идеологиясе һәм дөньяви прогрессив идеология.

5. Әдәбиятта дөньяви мотивларның ныгый баруы, публицистик башлангычның көчәюе.

6. Фольклорга тартым, мавыктыргыч сюжетлы дастаннар, кыйссалар («Кыйссаи Там», «Әбугалисина кыйссасы» һ.б.)

7. Татар халкының әдәби мирасына игътибар көчәюе. М.Иванов һәм С.Кукляшев хрестоматияләре.

8. XIX гасырның беренче яртысында татар поэзиясе. Төп юнәлешләре, үзенчәлекләре.

9. XIX гасыр шагыйрьләре иҗатында суфичылык идеологиясе йогынтысы.

10. XIX гасырның беренче яртысы поэзиясендә мәдхия, мәрсия, касыйдә һ.б. жанрлар.

11. XIX йөздә татар әдәбиятында проза жанрының активлашуы һәм моның сәбәпләре.

12. XIX йөз ахырында прозаның тормышка якынлаша баруы, реалистик повесть, роман жанрлары мәйданга чыгуы.

13. XIX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятына гомуми күзәтү.

14. Ш.Мәрҗәninең татар мәгърифәтчелеген үстерүдәге эшчәнлеге.

15. Сәяхәтнамә жанрының активлашуы һәм аның идея-эстетик үзенчәлекләре.

16. К.Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» китабы.

17. Ә.Каргалый иҗатына гомуми күзәтү. Аның иҗатында дини-суфичыл мотивлар, пейзаж лирикасы.

18. Һ.Салихов иҗатына гомуми характеристика. «Тәндә җаным» әсәренә анализ.

19. М.Акмулланың тормышы һәм иҗаты.

20. Г.Кандалыйның тормышы һәм иҗаты. «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» әсәрендәге фәлсәфи эзләнүләр.

21. К.Насыйри, И.Гаспралы, Х.Фәезхановларның гыйльми һәм иҗтимагый эшчәнлеге.

22. Г.Чокрыйның тормышы һәм иҗаты. «Мәдхе Казан» әсәре, «Хаҗнамә» сәяхәтнамәсе.

23. Ш.Зәкинең тормышы һәм иҗат мирасы.

24. Шагыйрь Кол Мөхәммәд иҗаты.

25. Баһавиның «Бүз егет китабы» (1842). Әсәрнең идея-эстетик кыйммәте.

26. Г.Кандалый иҗаты. Аның «Сәхибҗамал» поэмасы.

27. Ә.Уразаев-Кормашиның «Таһир илә Зөһрә» кыйссасы (1876).

28. Акмулланың шигъри осталыгы. «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәре.

29. Ә.Уразаев-Кормашиның «Бүз егет» әсәренә анализ.

30. Я.Емельянов иҗаты.

31. К.Насыйриның новелла-анектодлары. «Кырык вәзир», «Әбугалисина» кыйссалары.

32. М.Акъегетнең тормышы һәм эшчәнлеге. Татар әдәбиятында беренче реалистик повесть (роман) «Хисаметдин менла» әсәре. Әсәрнең идея-эстетик эчтәлеге (тема, проблема, идея), сюжет-композициясе, сәнгати үзенчәлеге.

**4 курс 7 семестр**

## Вопросы для зачета

1. XX йөз башы татар әдәбиятының тарихи-хронологик чикләре. Бу чор татар әдәбиятына хас төп үзенчәлекләр.
2. XX йөз башында татар прозасының гомуми торышы. (Тематик үзенчәлекләре. Жанр хассияте).
3. XX йөз башы татар прозасында милләт, халык язмышы темалары. (Конкрет әсәрләре мисалында).
4. XX йөз башы татар прозасында кеше рухына игътибар арту. (Конкрет әсәрләр мисалында).
5. XX йөз башы татар драматургиясенең үзәгендә торган проблемалар. (Конкрет әсәрләр мисалында).
6. XX йөз башы татар әдәбиятында проза жанрының үсеше. (Конкрет әсәрләр мисалында).
7. XX йөз башы татар прозасында пейзаж поэтикасы (Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Ф. Әмирхан). (Конкрет әсәрләр мисалында).
8. XX йөз башы милли татар прозасында тема һәм образлар.
9. XX йөз башы татар прозасында уртаклыкта калган герой психологиясе (Ф.Әмирхан "Уртаклыкта", Г. Ибраһимов " Уты сүнгән җәһәннем" һ.б).
10. XX йөз башы татар драматургиясенә гомуми характеристика. (Тематика, проблематика, жанр)
11. XX йөз башы татар әдәбиятында рмантизм иҗат методы һәм аның төп сыйфатлары.
12. XX йөз башы татар әдәбиятында мәгърифәтчелек иҗат методы принципларның чагылышы.
13. Татар әдәбиятында критик реализм методының формалашуы. Бүгенге фәндәге бәхесләр.
14. Профессиональ театр барлыкка килү һәм аның әдәбият үсешенә йогынтысы.
15. 1905-1907 елларда татар телендә вакытлы матбугат үсеше. (Матбагалар. Нәшерләр. Тематик юнәлешләр).
16. 1905-1907 елларда әдәби хәрәкәт һәм татарларда иҗтимагый фикер үсеше.
17. 1905-1912 елларда татар драмаургиясенең үсеше. (Г.Камал, С.Рәмиев,Г.Исхакый һ.б.).
18. 1912-1917 елларда татар драматургиясенең үсеше (М.Фәйзи, К.Тинчурин, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ф. Бурнаш һ.б)
19. 1914-1917 елгы империалистик сугыш кәннәрендә әдәби хәрәкәт. Татарлар арасында сугышка төрле мөнәсәбәт һәм аның әдәбиятта чагылышы. (Проза, драматургия, шигърият).
20. Г. Исхакыйның тормышы һәм иҗат юлы. Публицистика, журналистик эшчәнлеге.
21. Г. Исхакыйның тормышы һәм иҗат юлы.Аның пьесаларның сәнгәтьчә эшләнеше "Кәләпүшче кыз" драмасына тулы анализ. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет-композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).
22. Г. Исхакыйның "Ике йөз елдан соң инкыйраз" үсүе, аның татар халкының милли үзаңын үстерүдәге роле.
23. Г. Исхакый "Теләнче кызы" әсәре. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет- композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).
24. Г. Исхакыйның "Локман хәким" әсәре. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет-композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).
25. Г. Исхакыйның" Зөләйха" пьесасында хатын кыз образы гәүдәләнеше.

26. Г. Исхакыйның “Алдым-бирдем” драмасы. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет-композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).

27. Г. Исхакый “Зиндан”, ”Сөннәтче бабай”, “Кәҗүл читек” әсәсрләрнең идея-проблематикасы.

28. Г. Исхакый - тәнкыйтче. Аның әдәби-тәнкыйть һәм әдәби-эстетик карашлары.

29. Г. Исхакый иҗатында рус-татар мөнәсәбәтләре. (Конкрет әсәрләр мисалында).

30. Г. Исхакыйның “Мөгалимә” драмасы. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет-композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).

31. Г. Ибраһимовның “ Татар хатыны ниләр күрми” әсәре. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет-композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).

32. Г. Ибраһимовның тормышы һәм иҗат юлы. “ Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы” хикәясе. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет-композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).

33. Г. Ибраһимовның “Яз башы”, “Диңгездә” хикәяләрендә табигатҗ тасвирының идея-эстетик роле.

34. Г. Ибраһимовның иҗатында хатын-кыз азатлыгы проблемасы. “Татар хатыны ниләр күрми” хикәясе.

35. Г. Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романы. Әсәрдә шәхес һәм җәмгыять проблемасының хәл ителеше.

36. Г. Ибраһимовның романтик һәм реалистик рухта сугарылган әсәрләре. (”Көтүчеләр”, “Карт ялчы”, “Табигать балары”). Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).

37. Ф. Әмирханның тормыш һәм иҗат юлы. Публицистикасы.

38. Ф. Әмирханның “Татар кызы” нәсере. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюже-композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).

39. Ф. Әмирхан- татар реалистик әдәби тәнкыйтенә нигез салучы.

40. Ф. Әмирхан иҗатында хатын-кыз темасы “Хәят” повесте. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет-композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).

41. Ф. Әмирханның драма әсәрләре “Яшьләр”, “Тигезсезләр” һ.б. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет-композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).

42. Ф. Әмирханның “Фәткулла хәзрәт” сатирик повесте. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет-композициясе. Сәнгатьчә эшләнеше).

43. Ш. Камалның башлангыч чор ибатында хас сыйфатлар.Хикәяләрендә бәхет темасының бирелеше (“Бәхет эзләгәндә”, “Сукбай”, “Чит илдә” һ.б.)

44. Ш. Камалның “ Акчарлаклар” повестенда сезонлы эшчеләр образы.

45. С. Җәләл “Дим буенда” әсәре. (Тема. Проблема. Идея. Жанр үзәнчелеге. Сюжет-композициясе. Сәнгәтьчә эшләнеше).

46. Г. Камалның тормышы һәм иҗат юлы.

47. Г. Камалның “Беренче театр”,”Бүләк өчен” комедияләрендә көлке алымнары.

48. XX йөз башы прозасында иҗади юнәлешләр (экзистенциализм, натурализм, экспрессионизм, символизм, акмеизм һәм импрессионизм.)

49. М. Фәйзинең “ Галиябану” драмасына идея-художество анализ.

50. М. Фәйзинең тормышы һәм иҗаты. Аның әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше.

**4 курс 8 семестр**

**Вопросы для экзамена**

1. Гражданнар сугышы елларында татар әдәбияты.
2. Егерменче еллар татар шигърияте.
3. Гражданнар сугышы елларындагы татар әдәбиятында ике юнәлеш: шәфкатьлелек, әхлак темалары һәм идеологияне пропагандалау, көрәш темасы.
4. Егерменче еллар татар прозасы.
5. Утызынчы еллар татар шигърияте.
6. Егерменче-утызынчы еллар татар әдәбиятының төп үзенчәлекләре.
7. Утызынчы еллар татар прозасы.
8. Егерменче-утызынчы елларда драматургия.
9. Гражданнар сугышы елларында драматургия.
10. Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романына анализ.
11. К.Тинчурин. «Зәңгәр шәл» мелодрамасында конфликт. Авторның персонажларга мөнәсәбәте.
12. К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасына анализ.
13. К.Тинчурин. Тормыш юлы һәм күпкырлы эшчәнлеге.
14. Г.Ибраһимовның Октябрь инкыйлабыннан соңгы иҗатына хас үзенчәлекләр.
15. К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасы. Әсәрдәге конфликтлар һәм аларның үзара бәйләнеше.
16. К.Тинчуринның «Американ» комедиясе. Яшьләр образы.
17. М.Гафуринең «Эшче», «Кеше ашаучылар» поэмалары.
18. Г.Кутуй. «Тапшырылмаган хатлар». Әсәрдәге эчке конфликт.
19. Ш.Камал. «Матур туганда» романына анализ.
20. М.Галәүнең «Болганчык еллар» романына анализ.
21. Г.Ибраһимов. «Тирән тамырлар» романы. Әсәрдә кеше язмышын социаль шартларга буйсынуы.
22. Г.Ибраһимов иҗатын чорларга бүлү һәм үзенчәлекләре.
23. Т.Гыйззәт пьесаларында сыйныфлар каршылыгы.
24. Г.Ибраһимов. «Кызыл чәчәкләр» повесте.
25. М.Гафури. «Кара йөзләр» повесте. Усаллык һәм шәфкатьлелек темасының яңача ачылуы.
26. М.Әмирнең «Агыйдел» повестенә анализ.
27. Х.Туфанның егерменче елларда язылган поэмаларында күтәрелгән тема-проблемалар.
28. Г.Бәшировның «Сиваш» повестенә анализ.
29. Т.Гыйззәт. «Чаткылар» пьесасы.
30. Г.Ибраһимов. «Адәмнәр» повесте.
31. Х.Туфан. «Ант» поэмасын катламнар буенча анализлау.
32. Х.Туфанның тормыш һәм иҗат юлы.
33. Ш.Усманов. «Гает корбаны», «Ачылган йозак» хикәяләренә анализ.
34. Һ.Такташ. «Җир уллары трагедиясе»ндә геройлар бирелеше.
35. Һ.Такташ. «Мокамай» әсәрендә шәфкатьлелек темасы.
36. Һ.Такташ. «Ак чәчәкләр» шигыренә анализ.

**5 курс 9 семестр**

**Вопросы для зачета**

1. Алтмышынчы-сиксәненче еллар татар драматургиясе.
2. Алтмышынчы-сиксәненче еллар татар прозасында төп юнәлешләр.
3. Алтмышынчы-сиксәненче елларда татар поэзиясенең төп үзенчәлекләре.

4. Алтмышынчы-сиксәненче еллар прозасында милли йолалар чагылышы (Гомәр Бәширов «Туган ягым – яшел бишек» һ.б.).
5. Алтмышынчы-сиксәненче еллар прозасында тарихи шәхесләр.
6. Татар әдәбиятында шәхес культы темасы.
7. Әхмәт Фәйзи – шагыйрь һәм прозаик. «Тукай» романы.
8. Ибраһим Гази иҗаты. «Онытылмас еллар» трилогиясе.
9. Габдрахман Әпсәләмов иҗаты. «Ак чәчәкләр» романы.
10. Туфан Миңнуллин драматургиясе. «Үзебез сайлаган язмыш» драмасы.
11. Нурихан Фәттах иҗаты. «Кичү» романы.
12. Гариф Ахунов иҗаты. «Хәзинә» романы.
13. Әмирхан Еники иҗаты. «Әйтелмәгән васыять» повесте.
14. Әмирхан Еники иҗаты. «Саз чәчәге» повесте.
15. Хәсән Сарьян иҗаты. «Бер ананың биш улы» повесте.
16. Нурихан Фәттах иҗаты. «Итил суы ака торур» романы.
17. Аяз Гыйләҗев иҗаты. «Өтәч менгән читәнгә» романы.
18. Аяз Гыйләҗев иҗаты. «Җомга көн, кич белән» повесте.
19. Мөхәммәт Мәһдиев иҗаты. «Без – кырык беренче ел балалары» повесте.
20. Мөхәммәт Мәһдиев иҗаты. «Кеше китә - җыры кала» повесте.
21. Туфан Миңнуллин иҗаты. «Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясе.
22. Равил Фәйзуллин иҗаты. «Нюанслар иле» циклы.
23. Сибгат Хәким поэзиясе. Поэмалары.
24. Илдар Юзеев иҗаты. Поэмалары.

**5 курс 10 семестр**

**Вопросы для экзамена**

1. Татар сүз сәнгате тарихында аерым баскыч буларак хәзерге әдәбият, аның чикләре мәсьәләсе.
2. Бүгенге әдәби процесс. Әдәбият үсешенә, әдипләрнең сәнгати фикеренә, рухи халәтенә тәэсир ясаган әһәмиятле вакыйгалар, XX-XXI гасыр чигендәге иҗтимагый-сәяси вазгыять.
3. 80 нче елларның икенче яртысыннан башланган демократик үзгәрешләр. Аларның әдәбият белеменә, матур әдәбиятка йогынтысы.
4. Сәнгатьчә фикерләү һәм сурәтләүдәге яңа алым, формаларның тууы. Хәзерге әдәбият белемендә бу турыдагы бәхәсләр.
5. Ике гасыр чигендә әдәби тәнкыйтьнең торышы. Әдәбиятның үткән чорларына яңача, заманча ноктадан торып бәя бирергә омтылыш.
6. Хәзерге татар әдәбиятның торышы, милли сүз сәнгатендәге тематик төрлелек, образлар бирелешендәге үзгәрешләр.
7. Хәзерге татар әдәбиятнда иҗат юнәлешләренең, агымнарының яңаруы. Детектив, публицистик, мемуар-автобиографик жанрларның үсеше. Хикәя, повесть, роман жанрларының төрләнү-тармаклануы.
8. Бүгенге татар прозасында “традицион”, шартлы-метафорик һәм яңа дулкында иҗат ителгән чәчмә әсәрләр. Шартлы-метафорик әдәбиятның киң колач алуы.
9. Татар әдәби фикерендә “Милли реализм” төшенчәсе, аңа карашлар төрлелеге. Бу юнәлештә иҗат ителгән әсәрләрнең милли үзаңны торгызуда әһәмияте, яңа тип идеалның күтәрелүе (Г.Исхакый һ.б.). Ф.Латыйфиның “Ишелеп төшкән бәхет” (1999) романы.

10. Татар прозасында классик (чиста) реализм төшенчәсенең янәдән әйләнешкә керүе, Совет хакимияте сәясәтенә тәнкыйди карашның көчәюе. Шәхес культы темасының активлашуы (А.Гыйләҗевнең “Өч аршын җир” (1962), И.Сәләховның “Колыма хикәяләре” (1981), А.Гыйләҗевның “Ягез, бер дога” (1990) әсәрләре).

11. Хәзерге реалистик әсәрләрдә 1917 елгы инкыйлабын, колхозлашу елларын, тоталитар системаның кешелексезлеген ачарга омтылыш (М.Хәсәновның “Язгы аҗаган”, Р.Мөхәммәдиевнең “Сират күпере” һ.б. әсәрләре).

12. 20-30 нчы елларда язылып та, озак вакыт дәвамында басылмаган М.Гафуриның “Кеше ашаучылар” (1921), Г.Ибраһимовның “Адәмнәр” (1921) әсәрләренең дөнья күрүе.

13. Яңадан кайткан әдәбият, “ак таплар”ның бетә баруы, мөһаҗирлек әдәбияты төшенчәсе (Г.Исхакый һ.б.).

14. Совет системасының кеше тормышына тискәре йогынтысын ачкан, әхлакый идеалны югары күтәргән әсәрләр (Ф.Садриевның “Таң җиле” (1994), А.Гыйләҗевның “Балта кем кулында” (1988-1989) романы).

15. Татар реалистик әдәбиятында шәхеснең үзбилгеләнүе өчен көрәш темасының алга чыгуы, заманның әхлаксызлыгы турында уйланулар (Т.Галиуллинның “Тәүбә” (1996-1997), “Элмәк” (1998) “Төнге юллар” романнары).

16. Татар прозасында лирик башлангычның, сентиментальлекнең көчәюе (М.Мәһдиевнең “Бәхилләшү” (1987), Р.Сибатның “Ялгызак” (1999) әсәрләре).

17. Чәчмә әсәрләрдә милли үзаң үсеше белән бәйләнештә тарихи теманың гәүдәләнеше (Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” (1977-1985), М.Хәбибуллинның “Кубрат хан” (1985), Ф.Латыйфиның “Хыянәт” (1999) романнары).

18. Татар прозасында “яңартылган” реализм, психологик реализм, магик реализм. Аларның асылы, төп үзенчәлекләре (Ф.Бәйрәмова “Болын” (1982), “Битлек” (1983), Н.Гыйматдинованың “Сихерче” (1990), “Ак торна каргышы” (1995) повестьлары).

19. Татар прозасында интеллектуаль реализм агымы, анда шәхеснең фәлсәфи эзләнүләр аша яшәешне аңлауы, хакыйкатьне табуга омтылышы (Ф.Бәйрәмованың “Алыплар илендә” (2002) повесте).

20. Хәзерге татар прозасында романтизм юнәлешенең үсеше (М.Галиевның “Алтын тотка” (1987-1988), Ф.Садриевның “Кыргый алма әчесе” (2003) повестьлары).

21. Хәзерге әдәбиятта постмодернизм юнәлеше. Татар әдәбиятында постмодернистик концепция, постмодернистик элементлар белән баетылган әсәрләре (Г.Гыйльмановның “Албастылар” (1990-2001) хыялый кыйссасы, М.Кәбировның “Сары йортлар сере” (2001) повесте).

22. Фәлсәфи-романтик тенденцияләрнең хәзерге татар поэзиясендә дәвам иттерелеше (И.Юзеев, Р.Фәйзуллин һ.б.).

23. Романтик шигъриятә символлар аша яшәешкә бирелгән бәя, тормыш, дөнья, тарих турында уйланулар. Милли бәйсезлек темасының чагылышы, милли идеалның бирелеше (Зөлфәт).

24. Поэзиядә гражданлык мотивларының, публицистик башлангычның көчәюе, мөстәкыйльлек өчен көрәш белән бәйләнештә романтик шигърияттә тарихи темага игътибарның артуы (Р.Харисның “Ант суы” (1988), Ә.Рәшитнең “Мөхәммәдъяр” (1996) поэмалары).

25. Реалистик шигърияттә тарихи шәхесләргә яңача мөнәсәбәт. (М.Әгъләмовның “Акмулла арбасы” (1981), “Тукайдан хатлар” (1985) поэмалары).

26. Татар поэзиясендә яңа юнәлешләрнең тууы, яңа агымнарга мөнәсәбәт, экспрессионистик (Р.Зәйдулла, Р.Әймәт), импрессионистик (Ш.Анак), постмодернистик (Сөләйман) алымнар, элементларның урын алуы.

27. Драматургиядә иҗат мәйданына яшь көчләр буларак З.Хәким, Д.Салихов, М.Гыйләҗев, Аманулла, Г.Каюмовларның килүе.

28. Сүз сәнгатенең драма төрендә яңа тема-проблемаларның урын алуы, (М.Гыйләҗевның “Бичура” (1988-1989) драмасы, Т.Миңнуллинның “Шәҗәрә” (2001) драмасы).

29. Романтизм ысулының үзгәреп, драматургиядә милләт фаҗигасен ачуга юнәлтелүе. Катнаш никахлар проблемасының фәлсәфи яссылыкта хәл ителеше (Т.Миңнуллинның “Илгизәр+Вера” (1994) драмасы).

30. Хәзерге драматургиядә тәнкыйди фикернең үткенәюе, рус һәм көнбатыш сүз сәнгатенә хас, традицион булмаган сурәт-образларга, алымнарга мөрәҗәгать итүе (З.Хәкимнең “Юләрләр йорты” (1996) трагикомедиясе).

**Образец экзаменационного билета:**

**Билет № 1.**

1. Гражданнар сугышы елларында татар әдәбияты.
2. М.Гафуринең «Эшче», «Кеше ашаучылар» поэмалары.

**Критерии оценки (в баллах):**

- **25-30 баллов** выставляется студенту, если студент дал полные, развернутые ответы на все теоретические вопросы билета, продемонстрировал знание функциональных возможностей, терминологии, основных элементов, умение применять теоретические знания при выполнении практических заданий. Студент без затруднений ответил на все дополнительные вопросы. Практическая часть работы выполнена полностью без неточностей и ошибок;

- **17-24 баллов** выставляется студенту, если студент раскрыл в основном теоретические вопросы, однако допущены неточности в определении основных понятий. При ответе на дополнительные вопросы допущены небольшие неточности. При выполнении практической части работы допущены несущественные ошибки;

- **10-16** баллов выставляется студенту, если при ответе на теоретические вопросы студентом допущено несколько существенных ошибок в толковании основных понятий. Логика и полнота ответа страдают заметными изъянами. Заметны пробелы в знании основных методов. Теоретические вопросы в целом изложены достаточно, но с пропусками материала. Имеются принципиальные ошибки в логике построения ответа на вопрос. Студент не решил задачу или при решении допущены грубые ошибки;

- **0-10 баллов** выставляется студенту, если он отказался от ответа или не смог ответить на вопросы билета, ответ на теоретические вопросы свидетельствует о непонимании и крайне неполном знании основных понятий и методов. Обнаруживается отсутствие навыков применения теоретических знаний при выполнении практических заданий. Студент не смог ответить ни на один дополнительный вопрос.

**Планы практических (семинарских) занятий**

| № | Наименование раздела /темы дисциплины | Содержание |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1. | **Раздел 1. Древняя и средневековая татарская литература (2 семестр)** | |
| 1.1. | Древнетюркская литература | Гомумтөрки (борынгы төрки) әдәбият. Борынгы төркиләр. Аларда язу барлыкка килү мәсьәләсе. Туран (һун), рун һәм уйгур графикалары.<br><br>Барлык төрки халыкларның уртак мирасы дип каралган *«Орхон – Енисей»* язмалары. Мәхмүд Кашгариның *«Диване лөгатет–төрк» (1073–1074*) китабы. Йосыф Хас Хаҗиб Баласагуниның 1069–1070 елларда язылган *«Котадгу белег»* дидактик поэмасы. Әхмәд Йүгнәки (XII йөз). Аның дидактик характердагы «Һибәтел–хакаик» («Хаклыклар бүләге») поэмасы. Әхмәд Ясәви (1166 елда үлә) һәм Сөләйман Бакырганый (вафаты 1186 елда) – төрки суфыйчылык шигърияте нең күренекле вәкилләре. |
| 1.2. | Литература булгарского периода (X – середина XIII века) | Болгар–хәзәр чоры. Кол Гали һәм аның "Кыйссаи Йосыф" дастаны. Болгар мифологиясе һәм халык авыз иҗаты үрнәкләре: риваять–легендалар, мәкаль–әйтемнәр, җырлар. Болгарның борынгы Русь белән мөнәсәбәтләренә бәйләнешле риваятьләр. Болгар чоры язма әдәбиятының мәшһүр шагыйре Кол Гали һәм аның «халыкка җан азыгы булган кыйммәтле әдәби җәүһәре «Кыйссаи Йосыф» дастаны (поэмасы). |
| 1.3. | Литература периода Золотой Орды (с середины XIII века до середины XV века) | Алтын Урда чорында әдәбият. Суфыйчылык әдәбияты. Алтын Урда дәүләте чорында кыпчак һәм угыз, болгар телләре нигезендә уртак тел оеша башлау, язма әдәбият вәкилләренең төрле төрки төбәкләрдән чыгуы. Иҗат ияләренең башлыча гарәп һәм фарсы телле Көнчыгыш классикларына йөз тотуы. Котб, Харәзми, Сәйф Сараи кебек шагыйрьләрнең Хәйям, Фирдәүси, Әбүгалисина, Низами, Сәгъдиләрдән килә торган дөньяви мотивларны үстерүе. Мәхмүд бине Гали Әл–Болгари, Хисам Кятиб кебек язучыларның Газзали, Фәридеддин Гаттар иҗатыннан килгән суфичылык традицияләренә иярүләре. Суфичылык һәм аны барлыкка китергән сәбәпләр. XlV нче йөзләрдә Идел–Урал буе төрки–татар әдәбиятында дини–мистик рухлы агымның көчәюе, моның социаль–тарихи сәбәпләре, идея–эстетик чыганаклары, «Диване Хикмәт», «Бакырган китабы» дигән җыентыклар, «Кисекбаш», «Кыйссаи Сәкам», «Нәсыйхәт–әс–салихин» кебек дини–дидактик, дини–суфичыл, дини–каһарманлык дастаннары барлыкка килү, аларда ислам диненең бөеклеген исбатларга омтылу.<br>Рабгузыйның "Кыйссасел–әнбия" китабы. **Котб "Хөсрәү вә Ширин" әсәре.** Дастанның саклану һәм өйрәнелү тарихы, хәзергә кадәрге басмалары. Котб дастанының язылу урыны һәм шартлары. «Хөсрәү вә Ширин» дастанының сюжеты, композицион төзелеше, образлар системасы. Поэманың оптимистик рухы. Шагыйрьнең поэтик осталыгы. Харәзми "Мәхәббәтнамә" поэмасы. Поэманың язылу һәм саклану тарихы, кульязма нөсхәләре. Әсәрнең сюжет үзенчәлеге, композицион төзелеше. Мәхмүд Болгари (Мәхмүд бине Гали) "Нәһҗел–фәрадис" әсәре. Әсәр күчермәләренең табылган урыннары, фәнни яктан өйрәнелү тарихы. Авторның кайсы төбәктән чыккан булуы, әсәрнең язылу вакыты һәм урыны. Идел–Урал буе төрки әдәбиятында хикәячелек жанрын үстерүдә «Нәһҗел–фәрадис» әсәренең урыны һәм роле, аның традицияләре. Хисам Кятиб "Җөмҗөмә солтан" дастаны. Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (1370) әсәренең язылу урыны һәм шагыйрь биографиясенең ачык булмавы. Дастан күчермәләренең таралу төбәкләре, басма нөсхәләре турында мәгълүмат. Әсәрнең шигъри төзелеше, поэтик нәфисләү чаралары, тасвир алымнарында халык эпосы традицияләре: сыйфатны сан зурлыгы (күләм) белән ачарга омтылу, шигырьдә мәкаль һәм әйтемнәрне иркен куллану. Сәйф Сараи "Гөлестан |

| | | |
|---|---|---|
| | | бит–төрки” әсәре “Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастаны. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (1394 ел) поэмасы. Әсәр сюжетының реаль җирлеге булу ихтималы, авторның «чынлык» тенденциясен алга сөрүе. Шагыйрь мирасының әһәмияте. Сайядинең «Дастан Бабахан» әсәренең таралу даирәсе, саклану һәм өйрәнелү тарихы. «Дастан Бабахан»ның татар әдәбияты үсешенә зур йогынты ясавы. Сайяди дастанының композициясе, сюжеты, образлар системасы, әдәби эшләнеше. |
| 1.4. | Литература периода Казанского ханства | Казан ханлыгы чоры татар әдәбияты**.** Мөстәкыйль дәүләт буларак, Казан ханлыгының барлыкка килүе. Казан шәһәре һәм казанлылар турында тарихи чыганаклар, риваятьләр, легендалар. Җирле халыклардан җырчы–чичәннәр, музыкантлар, рәссамнар, төрле әдип–шагыйрьләр һәм галимнәр үсеп чыгуы. (Гарифбәк, Колшәриф, Мөхәммәдшәриф, Касыйм, Нух, Мөхәммәдьяр). Көнчыгыш белән бәйләнештә Казанның роле. Бу чорда башка төбәкләрдәге төрки телле әсәрләрнең Идел–Урал буенда киң таралыш табуы (азәрбайҗан, үзбәк, госманлы, төркмән әдип һәм шагыйрьләреннән Әхмәди, Мир Хәйдәр, Дүрбәк, Лотфи, Мөхәммәд Чәләби, Вафи, Физули һәм Нәваи әсәрләре). Госманлылар, комыклар, татарлар һәм башкортлар үз шагыйре итеп санаган Өмми Камал (чын исеме Исмәгыйль) әсәрләренең Идел–Урал буенда яратып укылуы. Аның әсәрләренең идея–эстетик асылы, Казан татар әдәбиятына тәэсире. Мөхәммәдъяр “Нәсыйхәт” әсәре, “Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” поэмалары. Мөхәммәдьяр әсәрләренең табылу һәм саклану тарихы. Аның иҗатын өйрәнүче әдип һәм галимнәрнең эшчәнлеге (И.Березин, М.Иванов, Н.Исәнбәт, Ш.Абилов, Х.Миңнегулов һ.б.). Шагыйрь шәхесе турында мәгълүмат.Татар поэзиясен үстерүдә Мөхәммәдьяр иҗатының роле. Кадыйр Галибәк “Җәмигъ эт–тәварих” җыентыгы**.** Кадыйр Галибәкнең «Җәмигъ эт–тәварих» (1602) әсәре. Аның тәрҗемә әсәре булуы һәм оригинальлеге мәсьәләсе. Бу әсәрне өйрәнүгә өлеш керткән хәзерге галимнәрнең эшчәнлеге турында мәгълүмат. «Җәмигъ эт–тәварих»ның башка төрки халыклар культурасына мөнсәбәте. Әсәрдә гомумватанчылык идеясе; Борис Годуновка мәдхия җырлау; рус монархиясе кулы астында үзәкләшкән феодаль дәүләтне яклау. |
| 1.5. | Татарская литература XVII-XVIII веков | XVII йөз татар әдәбияты. Мәүлә Колый иҗаты. XVI йөзнең ахырында һәм XVII йөздә татар халкының иҗтимагый–сәяси хәле һәм мәдәнияте. Суфичылык идеяләренең яңадан җанлануы, моның сәбәпләре. Мәүла Колый әсәрләренең саклану тарихы, кулъязма нөсхәләрнең таралуы һәм аларны фәнни өйрәнүгә өлеш керткән әдип–галимнәрнең эшчәнлеге (Фазыл Туйкә, Г.Сәгъди, Г.Ибраһимов, Х.Хисмәтуллин, Х.Госман, К.Дәүләтшин, Г.Хөсәенов һ.б.). Мәүла Колый хикмәтләренең тематикасы, каршылыклы идея–эстетк табигате. Мәүла Колый хикмәтләренең лирик герое. 1990 елларда табылган ике поэмасы: «Берекәннәр сыйфаты» һәм «Хәләл ризык эстәгәннәр сыйфаты». Аларның идея–эстетик үзенчәлеге.<br>XVIII йөздә татар халкының иҗтимагый тормышы. Халык тормышы һәм көнкүрешнең авыз иҗаты әсәрләрендә чагылышы: «Лашманчы зары» һәм «Лашман бәете», «Солдат бәете», «Никрутлар бәете», «Пугачев бәете», «Салават Юлай» һәм «Салават бәете». Елъязмалар тибындагы әсәрләр, сәяхәтнамәләр, васыятьнамәләр; «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе», «Мөхәммәд Әмин сәяхәтнамәсе»; Гаделшаһ бине Габдулла һәм Габдерахман бине Туймөхәммәд васыятьнамәләре; Аксак Тимернең Болгар шәһәрен җимерүе турындагы елъязмалар, Акай кузгалышы һәм Пугачев сугышы, Екатерина II нең Казанга килүе турында язмалар. Мөхәммәдрәхим бине Рәфыйк Казани тарафыннан төзелгән һәм күчереп язылган «Мәҗмугыл–хикәят» җыентыгы. Таҗетдин Ялчыгол (1768–1838). Тормыш юлы, иҗат мирасы, күпкырлы эшчәнлеге (педагог, текстолог, тарихчы, рухани, табиб һ.б.). Әдипнең Суфый Аллаяр иҗат |

| | | |
|---|---|---|
| | | иткән «Сөбател гаҗизин» китабын «Рисаләи Газизә» исеме белән шәрехләве (1806). XVIII гасырда татар прозасының тематикасы киңәюе һәм форма ягыннан төрләнүе. Габдрәхим Утыз Имәни иҗаты. Габдрәхим Утыз Имәнинең (Габдрәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырым әл–Болгари) – XVIII–XIX гасыр чикләрендә иҗат иткән күренекле шагыйрь, энциклопедик белемле галим һәм җәмәгать эшлеклесе булуы. Аның тормыш юлы, иҗат мирасы турында мәгълүмат. Шагыйрьнең иҗатын өйрәнүгә өлеш керткән әдип–галимнәрнең эшчәнлеге. Аның шигъри әсәрләрендә фикер азатлыгы, гыйльми–мәгърифәт мәсьәләләре. Мәсәлән: «Тәхфәт–ел–гьөрабаә вә ләтаиф–ел–гьәзае» (Горбәтлектә йөрүчеләргә бүләк һәм аларның хурлыкка калу вакыйгалары). «Горбәтнамә» (Читтә йөрүче хикәясе). «Гавариф–эз–заман» (Замана бүләкләре), «Тәнәиһ–ел–әфкяр фи Нәсаих–ел–әхйар» (Фикерләрне пакъләндерүче файдалы киңәшләр», «Мөһиммәт–эз–заман» (Заманның мөһим билгеләре) әсәрләренең идея–проблематик тирәнлеге. Аерым шигырьләренең үзәгенә авторның үз шәхесе, үз тормышы, үзе кичергән вакыйгалар килеп керүе; үзенчәлекле лирик герой гәүдәләнеше. Утыз Имәни иҗатына Габдулла Тукай мөнәсәбәте. Шагыйрь Габдрәхим Утыз Имәнигә багышланган хезмәтләр. |
| 2. | **Раздел 2. Татарская литература XIX в. (3 семестр)** | |
| 2.1. | Татарская литература первой половины XIX в. | Татар халкының аңына, иҗтимагый фикер һәм культура үсешенә уңай йогынты ясаган факторлар, тарихи вакыйгалар. 1812 елгы Ватан сугышында һәм декабристлар восстаниесендә татарларның катнашуы. Ватан сугышының җыр - бәетләрдә һәм язма әдәбиятта чагылышы.<br><br>Казанда университет ачылу (1804), аның Идел һәм Урал буе халыклары, шул исәптән татарларның иҗтимагый-мәдәни үсешенә йогынтысы. Халкыбызның тарихын, этнографиясен, халык иҗаты әсәрләрен җыю, туплау һәм фәнни эшкәртүдә шәркыять галимнәренең роле (К.А.Фукс, А.К.Казембек, Х.Д.Френ, И.Н.Березин һ.б.). Татар телендә китаплар басыла башлау. Университет галимнәре Ибраһим Хәлфин (1778-1829) һәм Гали Мәхмүдов (2824-1891) эшчәнлеге. Татар халкы арасында мәгърифәт тарату планнары. Әдәби телне гади халык теленә якынайту мәсьәләсе куелу. Әдәбият сөючеләр җитәкчесе Нигъмәт Ибраһимов. Габденнасыйр Курсавиның (1776-1812) Мәгърифәтне яклавы. XIX йөз башында культура һәм фикер өлкәсендә бер-берсенә капма-каршы ике юнәлеш. Акылга ирек таләп итү һәм мәгърифәтчелек омтылышлары. Әдәбиятның, нигездә, шигъри характерда үсеше һәм аның төп юнәлешләре: а) дини-әхлакый; б) суфыйчыл; в) дөньяви. Аларың еш кына үзара керешен китүе. Поэзиядә публицистик яңгырашның көчәюе (Г.Утыз Имәни «Гавариф-әз-заман»). Чорга хас социаль вакыйгаларның киңрәк урын алуы («Иляһи бәетләр»). Әхлаксыз, надан дин әһелләрен, залим түрәләрне сатирик фаш иткән әсәрләр язылу («Мүкән кантун», Г.Кандалый «Тотынышып кулың кулга»). Крестьянның авыр тормышына, социаль тигезсезлеккә, хатын-кыз язмышына игътибар арту («Илаһи бәет. Уделный», Г.Кандалый «Сәхибҗәмал»). Фольклорга тартым мавыктыргыч дастан-кыйссаларның активлашуы («Бүз егет», «Тутыйнамә»).<br><br>Либераль аристократия карашларын чагылдыручы әсәрләр (Гомәр Мөхәммәд улының «Тәзкирәи мөфти Габдессәлам» (1832), «Сәфәрнамәи шаһзадә Александр» (1837) поэмалары).<br><br>Бу чор әдәбиятында жанр төрлелеге (мәдхия, мәрсия, мөнәҗәт, шигъри хат, шигъри хикәят, шигъри сатира, мәсәл, күңел лирикасы һ.б.). |

| | | |
|---|---|---|
| | | Сурәтләү алымнары. Җанлы сөйләмгә нигезләнгән әсәрләрнең киңрәк урын ала баруы. |
| 2.2. | Татарская литература второй половины XIX в. | Гасыр уртасында җәмгыять үсешендә туган каршылыклар. Крепостное право бетерелү. Азатлык хәрәкәтенең яңа этабы. Крестьян восстаниеләре. Тарихи социаль-икъдисади үзгәрешләрнең, иҗтимагый фикернең халыкларга тәэсире. Төрки халыкларда уяну хәрәкәтенә юл салучы эшлеклеләрнең мәйданга чыгуы: Азәрбайҗанда - Ахундов М.Ф., Казахстанда - Ч.Вәлиханов, А.Кунанбаев, татарларда - Х.Фәезханов, К.Насыйри һ.б. Рус җәмгыятендә демократик көчләрнең татарлар тормышы белән кызыксынуы. «Современник» журналында П.И.Пашино мәкаләләре басылып чыгу.<br><br>Казанда Татар укытучылар мәктәбе ачылу (1876).<br><br>Казан университеты каршында оештырылган «Археология, тарих һәм этнография» җәмгыяте (1878) эшчәнлегендә рус һәм татар галимнәренең катнашуы (Н.Катанов, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри Һ.б.).<br><br>Татар телендә вакытлы матбугат чыгаруга омтылышлар һәм аларның тормышка ашмау сәбәпләре (И.Запольский, М.Никольский, П.Пашино, Х.Фәезханов, К.Насыйри, З.Бигиев, Ш.Әхмәров Һ.б.).<br><br>Мәгърифәтчелекнең бер күренеше буларак җәдитчелек хәрәкәте. Мәгърифәтчелек әдәби-эстетик фикеренең формалашуы. Әдәбият һәм сәнгатьнең иҗтимагый роле турында К.Насыйри, З.Бигиев, З.Һади һ.б.<br><br>Шиһабеддин Мәрҗани (1818-1889) - күренекле галим, тарихчы, рухани фәлсәфәче, педагог. Хөсәен Фәезхановның (1828-1866) педагогик һәм гыйльми эшчәнлеге Исмәгыйль Гаспралының (1851-1914) тормышы, күпкырлы эшчәнлеге. Күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның (1825-1902) тормыш юлы. Татар телен фәнни нигезләп, гыйльми яктан үстерү өлкәсендәге эшчәнлеге. Халык иҗаты үрнәкләрен җыеп, халыкка җиткерүдәге хезмәтләре. «Таң йолдызы» газетасы проекты. Ярым журнал характерындагы еллык календарьлары. «Әхлак рисаләсе», «Тәрбия китабы»н да укыту-тәрбия мәсьәләләре.<br><br>Мәгърифәтчелек чоры әдәбиятының ике баскычы: берсе - XIX йөзнең соңгы чиреге, икенчесе - XX йөз башы. Беренче чорда әдәбиятның яңа жанрлар белән баюы (аеруча проза һәм драматургиядә). Иҗтимагый шартларга бәйле реализмның әйдәп баручы юнәлешкә әверелүе.<br><br>«Мәкәрҗә бәете»нең (1860) язылу, басылу тарихы. Гали Чокрыйның (1826-1889) тормышы, әдәби мирасы. Татар, казакъ, башкорт халыкларының уртак әдибе, танылган мәгърифәтче, олы фикер иясе Мифтахеддин Акмулланың (1831-1895) тормыш һәм иҗат юлы, шәхесе. Яков Емельяновның (1843-1898) тормыш юлы, әдәби мирасы. Әхмәт Уразаев-Кормаши (якынча 1855-1883) иҗатында романтик мәхәббәт сюжетына нигезләнгән дастан-кыйсса жанры үсеше. Муса Акъегетзадәнең (1864-1923) тормыш һәм иҗат юлы. Шәхесе формалашуга тәэсир иткән шартлар. «Хисамеддин менла» (1886) әсәре. Заһир Бигиевнең (1870-1902) тормышы һәм иҗат эшчәнлеге.<br><br>«Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887), «Зур гөнаһлар» («Гөнаһе кәбаир», 1890) романнары. XIX йөзнең соңгы чирегендә әдәбиятта драма төре барлыкка килү. |
| 3. | **Раздел 3. Татарская литература начала XX века (4-5 семестры)** | |

| | | |
|---|---|---|
| 3.1. | Татарская поэзия начала XX века | XX йөз башы татар әдәбияты курсының предметы, максат-бурычлары, хронологик чикләре. Чор әдәбиятының өйрәнелү тарихы, этаплары. Татар шигъриятенең күпгасырлык тарихы, традицияләре. Шигърияткә Г.Тукай, Н.Думави, М.Укмаси, З.Бәшири, М.Гафури кебек шагыйрьләрьнең килеп керүе. 10 елларда татар поэзиясенә шагыйрьләрнең икенче буыны килү: С.Сүнчәләй, З.Ярмәки, М.Фәйзи, Н.Исәнбәт, Ф.Бурнаш, Г.Сәмитова. Ш.Бабич, С.Сүнчәләй, М.Фәйзи, һ.б. |
| 3.1.1 | Творчество Габдуллы Тукая | Шагыйрь, прозаик, балалар язучысы, әдәби тәнкыйтьче, публицист, журналист, методист, җәмәгать эшлеклесе. Шагыйрь иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе. Җ.Вәлиди, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Г.Сәгъди, Я.Агишев, М.Гайнуллин, И.Нуруллин, Г.Халит, Р.Ганиева һ.б. карашлары. 1905-1907 елгы инкыйлаб елларында Тукайның шагыйрь буларак формалашуы. Журналистлык эшчәнлеге. Тукайның башлангыч чор иҗатында мәгърифәтчелек идеяләренең, үгет-нәсихәтчелекнең чагылышы, мәгърифәтчелек романтикасы өстенлек итү. Тукайга Казан әдәби мохитенең йогынтысы. «Әль-ислах», «Яшен», «Ялт-йолт», газета, сатирик журналларында эшчәнлеге. Тукай шигырьләрендәге лирик геройның рухи дөньясы катлаулану, кайгы-хәсрәт, төшенкелек, өметсезлек мотивлары килеп Шагыйрь иҗатында күзәтелгән романтизмның чыганаклары, эстетик табигате, Урта гасыр татар, рус һәм Аурупа поэзиясенең традицияләре. Тукай сатирасының иң югары ноктага күтәрелүе, идея-тематик һәм сәнгатьчелек ягыннан төрләләнүе. Г.Тукайның дини-шәригать кануннарына, Аллага, Коръәнгә мөнәсәбәте. Тукайның һәр дәвер иҗатында Коръән, Ислам мәдәниятеннән килгән мотивларның күзәтелүе. Тукайның татар шигъриятен реалистик юнәлештә үстерүе. Шагыйрь лирикасында төрки-татар поэзиясе, халык авыз иҗаты, рус һәм Көнбатыш Аурупа әдәбиятлары традицияләренең синтезлашуы һәм аларның милли җирлектә үстерелеше. |
| 3.1.2 | Творчество Мажита Гафури | Әдипнең тормыш юлы. Талантлы шагыйрь, прозаик һәм публицист. Башлангыч иҗатының тематикасы. Шигъриятендә тарихи барышка мөнәсәбәтнең, социаль мотивларның тирәнлеге, реалистик «аклылык, публицистик аһәң көчәю. М.Гафуриның оста аллегорик-мәсәлче булып танылуы. М.Гафуриның 1908-1913 нче еллар лирикасында идея-эстетик үзгәрешләр: тематик киңлек, хис-кичерешләр тирәнлеге, күңел һәм фәлсәфи лириканың өстенлек итүе, лирик геройның күңел дөньясы романтик сурәтлелеккә төрелеп бирелү, шагыйрь поэзиясенең дидактизм, үгет-нәсихәттән арынуы. Авторның шигърияткә параллель рәвештә прозада уңышлы эшләп килүе. Милли әдәбиятка гади халык, авыл, шәһәр ярлыларының, көнлекчеләрнең авыр тормышын, ачлык темасын сурәтләүне алып килүе. М.Гафури иҗатында жанр байлыгы, тел үзенчәлеге. |
| 3.1.3 | Творчество Сагита Рамеева | С.Рәмиев - романтик шагыйрь, прозаик һәм драматург, публицист һәм тәнкыйтьче, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. Журналистлык эшчәнлеге. С.Рәмиевиең башлангыч чор иҗаты. «Таң вакыты» шигыре. Лирик геройның кайгыру, борчылу сәбәпләре, бу хәлдән чыгу юллары турындагы уйланулары. Әсәр исеменең символик мәгънәсе. С.Рәмиевнең реакция еллары шигъриятендә ярсу йөрәкле, шашкын, бунтарь, гыйсъянчы, лирик геройның бирелеше. С.Рәмиевнең үз каләм көчен драматургия төрендә сынап каравы. «Яшә Зәбәйдә, яшим мин» пьесасы. С.Рәмиевнең унынчы елларда прозага мөрәҗәгать итүе. «Нәҗметдин агай бәйрәме», «Галәветдин хаҗи корбаны – Җаек Хәдичә» хикәяләре. Әдипнең автобиографик характердагы төгәлләнми калган «Ул исерек түгел иде» повесте. |

| | | |
|---|---|---|
| 3.1.4 | Творчество Дэрдменда | Талантлы шагыйрь, тыйнак һәм укымышлы зыялы, милләт хадиме. Иҗатының әдәби-эстетик юнәлеше һәм әдипнең үзенчәлекле иҗтимагый хәле. Дәрдемәнднең татар поэзиясендә классик романтик шагыйрь буларак танылуы. 1902-1903 елларда шигырь һәм хикәя жанрында беренче тәҗрибәләр ясавы. Дәрдемәнд лирикасының төп хасиятләре: шигъри таланты, кинаяле сөйләмгә, фикри тирәнлеккә, символик сурәтлелеккә осталыгы сиземләнү. Әсәрләрендә кеше һәм вакыт, урын (пространство), дөньяның бакыйлыгы, гомернең фанилыгы (чикләнгәнлеге), гомер агышы, тәкъдир, яшәү һәм үлем турында фәлсәфи уйлануларның әдип иҗатында кызыл җеп булып сузылуы «Кораб» шигырендә гәүдәләнеше. Шагыйрь иҗатының экзистенциализм фәлсәфәсе һәм импрессионистик стиль билгеләре белән бәйләнеше. Дәрдемәнднең робагый; фәрд, газәл, мәдхия, мәсәл кебек жанрларда эш итүе. Шагыйрь поэзиясендә мәгънәви тирәнлек, шигъри нәфислек, сүзләрне файдалануда үзгә осталык, кыскалык, сурәтләү чараларының муллыгы. |
| 3.1.5 | Творчество Нажиба Думави | Н.Думавиның катлаулы тормыш юлы. Аның лирик һәм эпик төрдәге уңышлы иҗаты. Әдәби тәнкыйть, публицистика өлкәсендәге эшчәнлеге. Н.Думави шигырьләрендә социаль контрастлар, тәнкыйди башлангычның көчәюе, чынбарлыкка мөнәсәбәтнең субъектив гәүдәләнеше күзәтелү. Шагыйрь иҗатының экспрессионистик агымга мөнәсәбәте. Н.Думавиның 10-елларда төрле фәлсәфи, мәдәни-тарихи мәктәпләргә мөрәҗәгать итүе: Көнбатыш һәм Көнчыгыш фәлсәфәсен, позитивизм философиясен өйрәнүе, аңа романтизм һәм экспрессионизм кебек әдәби юнәлешләрнең тәэсире, яшәешкә, акыл көченә шик белдерүе, рухи чистарыну кебек толстойчылык һәм руссоистик карашларны яклавы һ.б. Сугыш темасының әдип иҗатында чагылышы. «Ватан каһарманы яки агач аяк» (1916) хикәясе. «Сугыш» (1908), «Сугыш тәэссораты» (1916), «Головка» (1917) әсәрләре. Әдипнең тарихи риваять, хикәя-легендаларга нигезләнеп иҗат ителгән «Су кызы» (1915), «Болгар кызы Тойгы туташ» (1915) хикәяләре. Соңгы хикәясендә Идел буе болгарларының тормышы, гореф-гадәтләре, йолалары, уен-бәйрәмнәре җанландырылу. Н.Думавиның әдәби, фәлсәфи, гыйльми карашларын чагылдырган мәкаләләре. Аның иҗатын өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләре. |
| 3.1.6 | Творчество Шайехзады Бабича | Шәехзадә Бабич - талантлы шагыйрь, үткен телне публицист, оста педагог, фольклорчы. Ш.Бабичның шигъри иҗаты. Иҗатында жанрлар төрлелеге, идея-тематик киңлек Бабичның шигъриятендә сәнгатьчә фикерләүнең романтик төре өстенлек итү. Шагыйрь поэзиясендә Тукай темасының зур урын тотуы. Ш.Бабич иҗатында юмор һәм сатира, аның иҗтимагый-социаль эчтәлеге тирәнәю, максат-бурычларының киңәюе. «Кандала» (1916) поэмасының сюжеты, идея-эчтәлеге. «Газазил» (1916) әсәре. Поэманың эпик киңлеге, образларның конкретлылыгы, ирония һәм сарказмның үткенлеге, фантазиягә байлыгы. Ш.Бабичның публицистик мәкаләләре, аларда күтәрелгән проблемалар. |
| 3.2. | Татарская проза начала XX века | Ике үсеш баскычы:1) 1885-1908 еллар; 2) унынчы еллар прозасы. Унынчы еллар прозасында яшәүнең һәм идеалның фәлсәфи һәм әхлакый мәгънәсен эзләү юлында милли зыялыларның төрле типлары тудырылу. Әсәрләргә импрессионистик, экспрессионистик һ.б. яңа агым билгеләренең үтеп керүе. тарихның баш калкытуы, тарихи темаларга игътибар арту, тарих сәхнәсеннән төшеп калган дәүләтебезне сагыну, болгарчылык мотивларының гәүдәләнеше: Хатын-кыз темасының татар прозасында чагылышы. Прозаның психоло-гизмга кискен борылышы. Психологизмның төрләре: аналитик психологизм, җан диалектикасы, хирыс психологизмы, психонализ һ.б. Мәхәббәт темасының прозаиклар |

| | | |
|---|---|---|
| | | иҗатында әдәби-эстетик гәүдәләнеше. |
| 3.2.1 | Творчество Гаяза Исхаки: проза, драматургия, публицистика | Яңа реалистик татар әдәбиятына нигез салучы күренекле прозаик, драматург, ялкынлы публицист, журналист, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче. Әдип иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе. «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер», «Кәләпүшче кыз», «Бай углы» әсәрләре. «Өч хатын белән тормыш» драмасы, «Ике гыйшык» пьесасы һәм «Очрашу яки Гөлгыйзар» повесте. Әсәрләренең жанр төрлелеге һәм сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте, жанры, сюжет-композициясе, проблематикасы, стиль үзенчәлеге. Татар халкының милләт буларак бетү, юкка чыгу куркынычы, аның сәбәпләре, милләтнең бүгенге хәле һәм киләчәге турында уйланулар. Г.Исхакыйның иҗтимагый-сәяси карашларында һәм әдәби-эстетик фикерендә чагылган борылыш. «Зиндан» повесте. «Алдым-бирдем» драмасы. «Тартышу», «Мөгаллим» драмалары. «Теләнче кыз» романы «Калош», «Фамилия сәгадәте», «Сөннәтче бабай» хикәяләрендә гаилә, кеше бәхете мәсьәләләре. «Мәдрәсә җимеше», «Шәкерт абый» кебек хикәяләрдә психологизм. «Тормышмы бу?» романы. Әсәрдә күтәрелгән проблемалар. «Мулла бабай» романы «Зөләйха» фаҗигасе «Ул икеләнә иде», «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрләрендә милләтара никахлар, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләре. «Локман Хәким», «Көз», «Өйгә» таба» һ.б. әсәрләре, аларның жанр үзенчәлекләре, идея эчтәлеге. «Дулкын эчендә» пьесасында дөнья сугышы, сыйнфый, инкыйлаби вакыйгаларның кеше язмышы, бәхете, гаилә тормышы мәсьәләләре. «Җан Баевич» комедиясендә милли мәсьәләсе. «Олуг Мөхәммәд» драмасы, аның жанр үзенчәлеге. Г.Исхакыйның татар әдәбияты тарихы һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге. Г.Исхакый һәм XX йөз татар әдәбияты. |
| 3.2.2 | Творчество Фатиха Амирхана: проза, драматургия, публицистика | Талантлы әдип, тәнкыйтьче һәм публицист, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. Ф.Әмирханның тормыш юлы. Аның журналистлык эшчәнлеге. «Гарәфә кич төшемдә» хикәясе. «Бәйрәмнәр» әсәре. «Фәтхулла хәзрәт» повестенда көлү һәм фаш итү объектлары. «Хәзрәт үгетләргә килде», «Габделбасыйр гыйшкы», «Сәмигулла абзый» һ.б. хикәяләре. «Картайдым» хикәясе. Әдипнең «Урталыкта» романы. Ф.Әмирхан иҗатында хатын-кыз темасының гәүдәләнеше: «Татар кызы» нәсере; «Хәят» повесте. «Ай өстендәге Зөһрә» кыз» романтик рухлы хикәясе. «Хәкарәт саналган мәхәббәт», «Бер харабадә», «Сүнгәч» хикәяләре. Аларның идея эчтәлеге. «Яшьләр», «Тигезсезләр» драмалары. Аларның жанр, сюжет, төзелеш үзенчәлеге. |
| 3.2.3 | Творчество Галимджана Ибрагимова: проза, драматургия, публицистика | Г.Ибраһимовның тормыш юлы, гаҗәеп күпкырлы эшчәнлеге турында белешмә: әдип, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, публицист һәм журналист, тарихчы һәм тел белгече, методист һәм педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче. Әдипнең иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе. Язучының 1907-1912 еллардагы әдәби эшчәнлеге. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе. «Татар хатыны ниләр күрми» (вариантлары) повесте. Язучының иҗатында психологизмга, әдәби геройларның эчке дөньясын, хис-кичерешләрен, табигать, пейзаж, хатын-кыз матурлыгын, рухи мәхәббәт темаларын сурәтләүгә игътибарның көчәюе, Гареб романтизмының әдип иҗатында Шәрык традицияләре белән үрелеп үсүе. «Яз башы», «Дингездә», «Сәю-сәгадәт» һ.б. хикәяләре. «Карак мулла» әсәре. «Яшь йөрәкләр» романы. Әдәби метод, әдәби юнәлеш ягыннан катлаулануы: реалистик юнәлештә үсеп китүе, реализм белән романтизмның синтезы күзәтелү, реализмның |

| | | |
|---|---|---|
| | | романтик алымнар, чаралар белән баетылуы. «Карт ялчы», «Көтүчеләр» хикәяләре. «Безнең көннәр» романы. Аның катлаулы сюжеты, төзелеше һәм образлар системасы. Г.Ибраһимовның тәнкыйди, гыйльми, педагогик-методик эшчәнлеге. «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә күтәрелгән мәсьәләләр. Авторның бәхәсле карашлары. |
| 3.2.4 | Творчество Шарифа Камала | Әдипнең тормыш юлы. «Вакыт», «Шура» газета-журналларында эшчәнлеге. «Сулган гөл», «Уяну», «Буранда», «Сукбай», «Бәхет эзләгәндә» һ.б. әсәрләре. «Бер картның тойгылары», «Нәфисә», «Эч пошулы» һ.б. инсаният идеясенең сурәтләнүе. Ш.Камал иҗатында психологизм. «Уяну», «Буранда», «Сулган гөл», «Курай тавышы», «Буранда», «Бер картның тойгылары», «Козгыннар оясында» хикәяләре. «Акчарлаклар» повесте. Аның вакытлы эшчеләр (балыкчылар) тормышын сурәтләве. Ш.Камал иҗатында сатира һәм юмор үрнәкләре. «Сәмруг кош», «Депутат» фельетон-хикәяләре. Ш.Камалның татар драматургиясен үстерүгә керткән өлеше. «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясе |
| 3.3. | Татарская драматургия начала XX века. | Татар драматургиясе тарихын чорларга бүлү мәсьәләсе: 1887-1905 еллар; 1906-1911 еллар; 1912-1917 еллар. Яшь көчләр килүе. Драматургиянең тарихи темаларга мөрәҗәгать итүе, идея эчтәлеге баеуы, жанрлар системасы төрлеләнүе. |
| 3.3.1 | Зарождение татарского театра и его влияние на развитие татарской драматургии | Милли профессиональ театр барлыкка килү һәм татар драматургиясенең, тагын да ныгып, яңа баскычка күтәрелеше, бу уңайдан рус һәм Гареб драматурглары иҗатына мөрәҗәгать итү.<br><br>“Сәйяр”, “Нур” театрларының барлыкка килүе. |
| 3.3.2 | Творчество Галиасгара Камала | Г.Камал - реалистик татар драматургиясенә нигез салучы, хикәяче һәм шигырьләр авторы, тәнкыйтьче, публицист, журналист, тәрҗемәче, рәссам, театр эшлеклесе. Камалны драматургиягә алып килгән алшартлар. Драматургның әдәби иҗаттагы беренче тәҗрибәләре «Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет» пьесалары һәм «Сабир хәзрәт» хикәясе. Г.Камалның әдәби һәм журналистлык эшчәнлеге «Уйнаш» драмасы. «Беренче театр» комедиясе. Әсәрнең төп һәм ярдәмче конфликтлары. «Бүләк өчен», «Банкрот» комедияләре. «Өйләнәм... ник өйләндем» трагикомедиясе. Г.Камал драма һәм комедияләренең бай сәхнә тарихы. Аның әдәби тәнкыйди эшчәнлеге |
| 3.3.3 | Творчество Гафура Кулахметова | Тормыш юлы. Аның инкыйлаби эшчәнлеге, марксистик тәгълиматны өйрәнүе. Милли телдә марксистик әдәбият, инкыйлаби матбугат тудыруда аның роле, Аның милли театрны оештыруга, үстерүгә керткән өлеше, педагогик эшчәнлеге. Г.Коләхмәтовның әдәби мирасы. Аның проза һәм драма төрләрендә эшләве, әсәрләрендә пролетариат әдәбиятының нигезе салыну. «Ике фикер» фәлсәфи драмасы. Пьесада күтәрелгән мәсьәләләр. «Яшь гомер» драмасы. Аның конфликты. Әдипнең эпик әсәрләре. «Уалган мол» нәсере. «Ник уйгандым» хикәясе. Хикәянең дини-мифологик сюжетка корылуы. |
| 3.3.4 | Творчество Мирхайдара Файзи | Татар әдәбияты тарихында драматург буларак танылуы, шигырь һәм хикәя жанрларында да мирас калдыруы. Аның тормыш сукмаклары. Татар драматургиясе өлкәсендә, беренче тәҗрибәләре: «Татар туе», «Ике Хәсән» пьесалары. Беренче шигырьләре. «Минем шигырьләрем», «Яшь күңел» шигырь китаплары. Шагыйрь поэзиясендә романтик иҗат принциплары. М.Фәйзинең драматургия төрендәге эшчәнлеге. |

| | | |
|---|---|---|
| | | «Яшьләр алдатмыйлар» водевиле. «Кызганыч» романтик драмасы. «Тәкъдирнең шаяруы», «Авыл бәйрәме» пьесасы. «Галиябану» музыкаль драмасы. Пьесаның жанр үзенчәлеге, сюжеты, композиция бөтенлеге, камиллеге. Драманың образлар системасы: Драманың сәнгатьчә эшләнеше. |
| 4. | **Раздел 4. Татарская литература XX века (6-8 семестры)** | |
| 4.1. | Татарская литература 20-х годов (1917-1929 гг.) | Илдәге тарихи вакыйгалар, иҗтимагый-сәяси хәл. Февраль революциясе, аның милли-азатлык хәрәкәте көчәюенә китерүе. 1917 елгы Октябрь инкыйлабы, сәяси үзгәрешләр. Илдәшләр сугышы, ил һәм халык тормышына китергән фаҗигасе. Марксизм-ленинизм тәгълиматының бердәнбер идеологиягә әверелүе. Әдәбият-сәнгать алдында куелган яңа бурычлар.<br><br>Инкыйлаб һәм татар әдәбияты. Иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр белән нисбәттә 1920-30 еллар татар әдәбиятын шартлы рәвештә чорларга бүлү. 1917-1921 еллар – гражданнар сугышы, төп тема – көрәш; 1922-1929 еллар – илнең аякка басу чоры, яңа шартларда үзгә тема, проблема, стиль эзләү; 1930-1937 еллар – соцреализм иҗат методы игълан ителүгә бәйле үзгәрешләр чоры; 1937-1941 еллар – репрессияләр чоры, әдипләрнең кулга алынуы, сугыш куркынычы көчәю.<br><br>Татар әдәбиятында барган әдәби-эстетик, рухи эзләнүләр, тәҗрибәләр, әдәби ачышлар ясарга омтылу, социалистик реализмның әдәбиятка ясаган тәэсире. Модернистик агымнар һәм аларга татар әдәбиятының, тәнкыйтенең мөнәсәбәте.<br><br>Әдәбият өлкәсендә идеология хакимлеге һәм партия сәясәте. “Татар әдәбияты” төшенчәсенең “пролетар әдәбият”, “татар совет әдәбияты” атамаларына алмашынуы. Цензура һәм репрессияләр. Совет хакимияте алып барган сәясәт, иҗади ирекне кысу белән килешмәү сәбәпле илдән куылган яки үзләре киткән әдипләр язмышы.<br><br>1920 елларда әдәби төркемнәр барлыкка килү, РАПП һәм ТАПП оешу. “Җидегәнчелек”, “солтангалиевчелек” кебек советка каршы хәрәкәтләрнең уйлап чыгарылуы һәм нәтиҗәләре.<br><br>1920-30 елларда әдәби тәнкыйть. Бу өлкәдә Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди, Г.Нигъмәти, Г.Гали, Г.Толымбайский, Һ.Такташ, Х.Туфан, Ф.Сәйфи-Казанлы һәм башкаларның эшчәнлеге. Әдәбиятта “буржуаз тенденцияләр” белән көрәш, вульгар социологизм тәнкыйте.<br><br>Чор әдәбиятының өйрәнелү тарихы, этаплары, һәр дәвернең үз табышлары һәм кимчелекләре, теге яки бу күренешне бәяләүдә берьяклы караш, аларның заман сәясәтенә бәйле булуы. Бу юнәлештә үзгәртеп корудан соң барлыкка килгән яңа карашлар һәм хезмәтләр. Чор әдәбиятын өйрәнүнең бүгенге торышы.<br><br>Гражданнар сугышы елларында **поэзия**. Шигъриятнең яңа эчтәлек алуы. Аның гамәли әһәмияте арту сәбәпле, яшәү мәйданы киңәюе (газета-журналлар, театрлар, концерт заллары, мәйданнар митинглар һ.б.). Жанрлар системасы: публицистик-агитацион, сатирик-комик шигырьләрнең тернәкләнүе. Гражданнар сугышы чорында **драматургия.** Драма әсәрләренә ихтыяҗ үсүнең сәбәпләре. Тарихи-революцион һәм героик драмаларның алга чыгуы. 1920 елда татар халкына автономия рәвешендә бәйсезлек бирелү, 1921 елда татар теленең дәүләт теле дип игълан ителүе. Яңа икътисади сәясәт. 1921 елгы ачлык һәм аның татар |

| | | |
|---|---|---|
| | | әдәбиятына йогынтысы. Г.Ибраһимовның “Адәмнәр” повестенда, М.Гафуриның “Кеше ашаучылар”, Һ.Такташның “Күләгәләр” поэмаларында, Ф.Әмирханның “Тәгъзия” нәсерендә ачлыкның дәһшәтле чынбарлыгын тасвирлау.<br><br>Татар әдәбиятының зур югалтулар кичерүе (Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, Ф.Әсгать, М.Фәйзи), мәйданга килгән яңа көчләр (Х.Туфан, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, Г.Кутуй, К.Нәҗми һ.б.).<br><br>Илдә башланган үзгәрешләр, икътисади сәясәт нәтиҗәсендә шигърияттә хезмәт темасының үсеше. Эш һәм эшче образының эчтәлеге үзгәрү. Игенче образын тудыруда традицион сурәтләр, эшче хезмәтенә мәдхия укылу (Н.Исәнбәт, Г.Камал, К.Нәҗми, М.Гафури һ.б.). 20 еллар шигърияте һәм сәясәт мөнәсәбәте.<br><br>Х.Туфанның татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы, иҗатында завод эшчеләре темасының күтәрелүе: “Урал эскизлары”, “Ике чор арасында”, “Башлана башлады”, “Иске Рәсәй үлде”, “Бибиевлар” поэмалары.<br><br>Гыйсъянчылык күренеше, тамырлары белән классик көнчыгыш әдәбиятына барып тоташуы. Романтик сурәтлелек чарасы буларак мифологик символизм, аның яңа эчтәлек белән баетылуы. 1921 елдагы ачлыкның поэзиядә чагылышы. Ачлык күренешен сурәтләүдә шартлылык, символлар, натурализм: М.Гафури “Кеше ашаучылар”, “Ачлык”, Һ.Такташ “Күләгәләр”, “Җир уллары трагедиясе”, Ә.Сәгыйди “Ачлык көннәрендә”. |
| 4.1.1 | Творчество Мажита Гафури | Башкортостанның халык шагыйре, татар һәм башкорт әдәбияты классигы буларак М.Гафури.<br><br>М.Гафуриның шигырьләрендә көн темаларына мөрәҗәгать итүе. «Бетсен империалистлар сугышы», «Икмәк», «Хөрриятkә каршы торучыларга», «Аждаһа» кебек шигырьләрендә Вакытлы хөкүмәтне, аның халыкка каршы политикасын фаш итүе. Изүчеләрне халык хөкеменә тарту пафосы белән сугарылган «Хисап көне», «Бай абзый» шигырьләре.<br><br>М.Гафуриның идея-эстетик үсешен күрсәтү ягыннан «Эшче» поэмасының беренче һәм икенче вариантлары. Татар опера сәнгатенә нигез салудагы роле.<br><br>М.Гафури – прозаик. Нигездә реализмга өстенлек бирүе. «Кара йөзләр» повесте. Әсәрнең төп проблемасы. Галимә образының типиклыгы, халыкчан характеры. Әсәрдә дини фанатизм белән аек акылның конфликтка керүе. Сәнгатьчә эшләнештә психологизмны оста файдалану. Персонажларның һәм хикәяләүченең индивидуаль теле. Әсәрнең тәнкыйди рухы.<br><br>«Тәрҗемәи хәлем», «Шагыйрьнең алтын приискасында» повестьларында яшь кеше образлары. Капиталистик чынбарлыкта түбән катлау яшьләренең авыр хәлен күрсәтеп бирү. Эшчеләр белән прииска хуҗаларын капма-каршы итеп сурәтләү.<br><br>«Тормыш баскычлары» повесте. Вахит Җәгъфәровның революцион чынбарлыкта актив көрәшче булып житешүе. Нури Сәгыйтов, Ефимов, Нәгыйм Әминев образлары. Уңай образларны сурәтләүдәге җитешсезлекләр. Мәхмүт образы, аның типиклыгы. Хезмәт ияләренең авыр тормышын дөрес күрсәтү.<br><br>М.Гафуриның публицистикасы. М.Гафури иҗаты турындагы фәнни |

| | | |
|---|---|---|
| | | әдәбиятка күзәтү. |
| 4.1.2 | Литературная и общественная деятельность Галимджана Ибрагимова | Г.Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлы. Г.Ибраһимовның совет чоры әдәбияты үсешенә ясаган тәэсире. «Кызыл чәчәкләр» повесте. Социаль чыгыш һәм революциягә мөнәсәбәт мәсьәләсенең образларда дөрес ачылуы. Шаһбаз, Солтан, Гыйлаҗи образларына каршы куелган Фазыйл белән Гали. Кызыл чәчәк образының символик булуы. Әсәр тукымасының халык авыз иҗатына якын яклары. Дуслык, намуслы хезмәт белән тормышны матурлау идеяләре.<br><br>«Тирән тамырлар» романы. Сыйнфый көрәшнең яңа формалары. Фәхри һәм Вәли Хәсәнов образы. Кеше концепциясенең яңаруы. Шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәте. Сюжет-композиция үзенчәлекләре. Символик образларның роле.<br><br>“Алмачуар” хикәясе. Кеше һәм табигать мөнәсәбәте, әхлакый мәсьәләләрне күтәрүе. “Адәмнәр” повесте натуралистик сурәтләрдә ачлык фаҗигасын тасвирлау.<br><br>Г.Ибраһимовның язучы буларак осталыгын күрсәткән «Казакъ кызы» романы. Тормыш материалының яңалыгы. Тугандаш казакъ халкының тарихи үткәнен реаль итеп сурәтләү. Карлыгач-Сылу, Арсланбай образларының реальлеге һәм романтиклыгы.<br><br>Г.Ибраһимов – татар әдәбияты классигы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе. Февраль һәм Октябрь инкыйлабларыннан соңгы иҗтимагый эшчәнлеге. “Яңа кешеләр” пьесасы. Сыйнфый көрәш һәм яңа хакимияткә мөнәсәбәт.<br><br>Г.Ибраһимовның язучы, галим булып җитлегүендә башка халыклар әдәбияты, фәне, мәдәнияте тәэсире. |
| 4.1.3 | Творчество Хади Такташа | Иҗатының беренче чорына (1916-1922) хас үзенчәлекләр. Җәмгыятьтәге явызлыкны, рәхимсезлекне ләгънәтләү, аларга каршы чыгу протестының абстрактлыгы. Романтик сурәтләү, бунтарьлык рухы өстенлек итү. Дини-мифологик, символик образларның үзәктә торуы һәм шулар аша җир тормышын, яшәү мәгънәсен аңларга омтылу («Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр», «Янар таулар», «Җир уллары трагедиясе»). Мәхәббәттә янучы лирик герой («Урман кызы», «Таң кызы», «Зәңгәр күзләр»). Гомумкешелек кыйммәтләрен яклавы, фәлсәфи эчтәлек («Мәңгелек әкият»).<br><br>Иҗатының икенче чорына (1923-1931) хас үзенчәлекләр. Реалистик сурәтләү өстенлек итү. Гыйсъянчы лирик герой («Такташ үлде», «Син дә үл инде», «Әйдә, энем»). Чынбарлыкка, яңа җәмгыятькә бәя, мөнәсәбәт бирелү («Болай... гади җыр гына», «Ак чәчәкләр», «Мокамай»). Объектив һәм субъектив эчтәлек, форма яңалыгы, иҗтимагый тормыштагы социаль-психологик каршылыклар («Киләчәккә хатлар», «Бүгенге матурлык»). Яшьлек, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләренә мөрәҗәгать итү («Алсу», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Югалган матурлык»). Халыкчанлык, тел бизәкләре байлыгы, юмор («Нәни разбойник»). Еш кына романтизм белән реализм үрелеп килү; сөйләм шигыренең уңышлы формаларын табуы.<br><br>Һ.Такташ иҗатының новаторлыгы.<br><br>Һ.Такташ – драматург һәм прозаик. «Күмелгән кораллар», «Камил», |

| | | |
|---|---|---|
| | | «Югалган матурлык» драмалары. «Таң җиле» романының язылган кадәресе. “Караборынның дусты”, “Кияү” хикәяләре. Әсәрләренең проблематикасы.<br><br>Хәзерге татар совет шигъриятенә Һ.Такташ иҗат мәктәбенең тәэсире. |
| 4.1.4 | Творчество Карима Тинчурина | К.Тинчурин иҗатының үзенчәлеге, характерлар тудырудагы, сюжет корудагы аермалы яклары. К.Тинчуринның «Мәрҗәннәр» китабы, әсәрдә авторның прозаик буларак ачылуы. Драматургиядә К.Тинчурин тудырган традицияләр, аларның башка авторлар тарафыннан үстерелүе.<br><br>Музыкаль драма жанры үсешенә зур өлеш кертүе («Зәңгәр щәл», «Сүнгән йолдызлар», «Ил»). Иҗат үзенчәлекләре: беренче иҗат тәҗрибәләрен «Сәйяр» труппасында артист булып эшләгәндә ясый: «Хәләл кәсеп», «Беренче чәчәкләр», «Назлы кияү», «Соңгы сәлам» һ. б.; |
| 4.1.5 | Творчество Фатхи Бурнаша | Ф.Бурнашның романтик поэзиясе. Героик-патриотик поэзияне үстерүдә Ф.Бурнаш иҗаты. Аның әсәрләренең романтик характеры, халык иҗатына якынлыгы. Ф.Бурнашның революцион матбугаттагы эшчәнлеге. “Чәчәктән һәйкәл”, “Гөлчәчәк”, “Сахра каны”, “Ак каен”, “Әҗәл” поэмалары. Шигырьләре. “Таһир-Зөһрә” трагедиясе һәм “Яшь йөрәкләр” драмасының Ф.Бурнашны талантлы драматург итеп танытуы.<br><br>Ф.Бурнашның шигърияттә сатирик юнәлешне үстерүгә керткән өлеше. |
| 4.1.6 | Творчество Махмута Галяу | М.Галәүнең тормыш юлы. Вакытлы матбугатта актив катнашуы. Тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге. Дәреслекләр төзүдә, уку-укыту кулланмалары язуда, аң-белем таратуда катнашуы. М.Галәүнең хикәяләре, драма әсәрләре. «Канлы тамгалар» эпопеясы. Әсәрнең беренче һәм икенче кисәкләре – «Болганчык еллар» («Ил тыныч чакта»), «Мөһаҗирләр» (Ил өреккәндә») романнары. Аларның темалары, күтәргән проблемалары, сурәтләнгән образлар.<br><br>М.Галәү иҗаты турында фәнни хезмәтләр. |
| 4.2. | Татарская литература 30-х годов (1930-1941 гг.) | Ил күләмендә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр, масштаблы төзелешләр чоры. Бу дәвернең тискәре яклары. Үзгәрешләрнең әдәби барышта чагылышы.<br><br>Әдәбиятның идеологиягә буйсындырылуы. Татарстан һәм Бөтенсоюз язучыларының I съездлары (1934), аларда кабул ителгән карарлар. Социалистик реализм иҗат методы тантанасы, аның үзенчәлекләре, әдәби иҗатка тискәре тэсире. Совет әдәбияты үсешенә административ система алымнарын кулланып ирешергә омтылу. Иҗат ирегенең чикләнүе, массакүләм репрессияләр башлану. Шәхес культы чорында татар әдипләре, язмышы.<br><br>Поэзия. Х.Туфан, Ә.Фәйзи, С.Баттал, М.Җәлил, Ш.Маннур, Н.Баян, Ф.Кәрим, Ә.Ерикәй һ.б. актив иҗат итүе. Иҗтимагый идеалны шигъриятькә әверелдерү юлында эзләнүләр. Актив жанрлар.<br><br>Идеология кысаларыннан читләшү омтылышы. Шул юлда халык иҗаты казанышларын үзләштерү. Х.Туфанның “Луиза”, “Ак каен”, “Озату”, Ә.Фәйзинең “Умырзая”, “Яшьлек”, М.Җәлилнең “Сагыну”, С.Хәкимнең “Юксыну” кебек лирик шигырьләре.<br><br>30 елларда поэма һәм баллада жанрларының актвилашуы, яңа сыйфатлар |

| | | |
|---|---|---|
| | | белән баюы. Ә.Фәйзи "Флейталар", "Дала һәм кеше" М.Җәлил "Хат ташучы", Ф.Кәрим "Тавышлы таң", "Җиденче мич", Х.Туфан "Ант", "Тукайның туганы", "Тимер турында баллада", С.Хәким "Пар ат" әсәрләрендә тема төрлелеге, жанр үзенчәлекләре.<br>30 еллар поэзиясендә үткән тарих: М.Җәлил "Алтынчәч", "Илдар" либреттолары, Н.Исәнбәт "Түләк батыр", "Спартак" әсәрләре.<br>Проза төренең үсеше. Әсәрләрдә заман темаларын чагылдыру үзенчәлекләре, идея һәм сәнгатьлелек принципларында вульгар социологизмның өстенлек алуы. Кабатланучы сюжет һәм конфликтлар, вакыйгаларны тасвирлауда схемачалык. Яңа кеше образын эзләү, аны партиялелек, сыйнфый көрәш ноктасыннан торып тасвирлау.<br>Гражданнар сугышына багышланган вакыйгаларны "яңарту": Г.Бәширов "Сиваш", М.Әмир "Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре", А.Шамов "Госпитальдә", "Бер мәхәббәт тарихы" һ.б..<br>Диннең җәмгыятьтәге урынын бозып күрсәтү. Яңа әхлак нормалары, гаилә, мәхәббәт мәсьәләләре. Күмәк хезмәткә уңай мөнәсәбәт тәрбияләргә тырышу, хезмәт кешесен югары күтәрергә омтылу. Г.Кутуйның "Тапшырылмаган хатлар" повестеның популярлыгы, сере.<br>Прозада тарихи тема. М.Галәү "Болганчык еллар" һәм "Мөһаҗирләр" романы, К.Тинчурин "Мәрҗәннәр" циклы.<br>Драматургиядә конфликт ясалмалылыгы: Ш.Камал "Таулар", Г.Кутуй "Җавап", Т.Гыйззәт "Мактаулы заман" һ.б.<br>Ватанны саклау темасы: Т.Гыйззәт "Таймасовлар", Р.Ишморат "Идегәй". Фольклорга корылган әсәрләр: Н.Исәнбәт "Хуҗа Насретдин", Т.Гыйззәт "Кыю кызлар". Драматургиядә тарихи шәхесләр: Ә Фәйзи "Тукай", Н.Исәнбәт "Спартак", "Идегәй" һ.б. Әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеше, идеология таләпләренә буйсынып язылулары. |
| 4.2.1 | Творчество Шарифа Камала | Шәриф Камалның тормыш һәм иҗат юлы. Ш.Камал – прозаик. «Матур туганда» романы. Ш.Камалның публицистикасы, аның актуальлеге<br>Ш.Камал – татар әдәбияты классигы, татар совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе булуы. Язучының башлангыч чор иҗатында идея-эстетик эволюциясе. Ш.Камал – прозаик. «Матур туганда» романы. |
| 4.2.2 | Творчество Тази Гиззат | Драматургның тормыш юлы. «Тәрҗемәи хәлем», «Мин ничек артист һәм драматург булдым» исемле язмалары. Т.Гыйззәтнең драматург буларак үсеш этаплары, аның иҗатындагы төп темалар.<br>1917 елга кадәрге татар авылы, андагы стихияле ңәм оешкан сыйнфый көрәшне тасвирлау. Тарихи-революцион драмалары: «Наемщик», «Чаткылар», «Ялкын», «Ташкыннар», «Бишбүләк» һ.б. Тулаем алганда бу әсәрләрдә татар крестьяны үткән юлның тарихи эзлеклелектә бирелүе. |
| 4.2.3 | Творчество Кави Назми | Язучының тормышы һәм иҗаты. К.Нәҗминең иҗтимагый эшчәнлеге. Яңа әдәби юнәлешләр белән кызыксынуы. «Чыныгу» (1923), «Иң соңгысы» (1924), «Шобага» (1925), «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» (1926), «Таштугайга кайтмыйбыз!» (1928) кебек хикәяләре һәм аеруча хезмәт ияләренең революция, гражданнар сугышы аша социализмга килүен, яңа тормыш төзи башлавын реалистик картиналар һәм образлар аша сурәтләгән «Яр буенда учаклар» (1928), «Якты сукмак» (1929), «Кояшлы яңгыр» (1930) повестьлары. Бөек Ватан сугышы елларында К. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Нәҗми. Әдип совет кешеләренең тылдагы һәм фронттагы батырлыгын, ватандарлык хисләрен әдәби образларда чагылдырган «Хәят апа» (1941), «Сагыну хаты» (1942), «Снайпер Мәрдән» (1943), «Фәридә» (1943-1944) кебек поэмаларын һәм күп санлы патриотик шигырьләре. «Язгы җилләр» исемле тарихи-революцион романы. |
| 4.2.4 | Творчество Гаделя Кутуя | Утызынчы еллардагы идея-эстетик үсеше, шуның күрсәткече буларак, «Җавап», «Шатлык җыры» пьесалары. Әдипнең барлык жанрлар өлкәсендә дә актив эшләве. Шигырь (“Иртәнге уйлар” һ.б.), поэма (“Талантлар ватаны” һ.б.), повесть (“Тапшырылмаган хатлар”, нәсер (“Без – сталинградчылар” һ.б.) очерк (“Берлин юлында очрашу”), тәрҗемә (Лермонтовның “Маскарад”ы, Маяковскийның “Сул марш”ы һ.б.), «Солтанның бер көне», «Нишләргә?», «Вөҗдан газабы» хикәяләре, аларда сурәтләнгән интеллигенция вәкилләре образлары.<br><br>«Тапшырылмаган хатлар» повесте. |
| 4.3. | Татарская литература периода Великой отечественной войны (1941-1945 гг.) | Бөек Ватан сугышы елларында татар әдәбияты. Чор һәм әдәбият. Аңа хас үзенчәлекләр. Әдәбиятның агитатор һәм пропагандист вазифаларын үти башлавы: төп максат-бурычы: халыкны изге көрәшкә чакыру, бердәмлеккә өндәү, җиңүгә ышаныч тәрбиләү, фашизмга нәфрәт хисе уяту һ.б. Татар язучылырының күпчелеге фронтка китүе; 30 дан артыгы сугыш кырында яисә дошман әсирлегендә һәлак булуы (М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, К.Басыйров, М.Гаяз, Р. Ильяс, Х.Мөҗәй, Д.Фәтхи һ.б.). 1942 елдан башлап төрле фронтларда 16 исемдә татарча газета чыгуы. Аларда Г.Кутуй, А.Шамов, Ә.Ерикәй, Р.Ишморат, Г.Әпсәләмов, И.Гази, Ш.Маннур, Ә.Фәйзи, Ш.Мөдәррис, М.Хөсәен һ.б. әдипләрнең журналист булып хезмәт итүе. ВКП(б) ҮКның 1944 ел 9 август карары нигезендә татар әдәбиятында һәм сәнгатендә тарихи темаларны яктыртуга зур киртә куелуы. Сугыш чоры таләпләренә иң тиз яраклашучы төрнең лирика булуы, төп мотивлар. Әдәбиятның агитатор һәм пропагандист вазифаларын үти башлавы: төп максат-бурычы: халыкны изге көрәшкә чакыру, бердәмлеккә өндәү, җиңүгә ышаныч тәрбиләү, фашизмга нәфрәт хисе уяту һ.б.<br><br>Татар язучылырының күпчелеге фронтка китүе; 30 дан артыгы сугыш кырында яисә дошман әсирлегендә һәлак булуы (М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, К.Басыйров, М.Гаяз, Р. Ильяс, Х.Мөҗәй, Д.Фәтхи һ.б.).1942 елдан башлап төрле фронтларда 16 исемдә татарча газета чыгуы. Аларда Г.Кутуй, А.Шамов, Ә.Ерикәй, Р.Ишморат, Г.Әпсәләмов, И.Гази, Ш.Маннур, Ә.Фәйзи, Ш.Мөдәррис, М.Хөсәен һ.б. әдипләрнең журналист булып хезмәт итүе. ВКП(б) ҮКның 1944 ел 9 август карары нигезендә татар әдәбиятында һәм сәнгатендә тарихи темаларны яктыртуга зур киртә куелуы.<br><br>Сугыш чоры таләпләренә иң тиз яраклашучы төрнең лирика булуы, төп мотивлар Поэзиядә жанрлар торышы. Традицияләрне баетырга омтылу. Бу өлкәдәге бәхәсләр. Прозада хикәя, очерк, повесть кебек жанрлар алгы планга чыгуы. Прозада жанр төрлелеге. Хикәя (Г.Әпсәләмов. Ватан улы. Үлемнән көчлерәк; Ә.Еники. Бала. Ана һәм кыз; И.Гази. Алар өчәү иде). Повесть (Ф.Кәрим. Язгы төндә. Разведчик язмалары). Маҗаралы повесть (Г.Кутуй. Рөстәм маҗаралары). Нәсер (Г.Кутуй. Сагыну. Без – сталинградчылар). Фронт көндәлеге (Х.Мөҗәй. Сугышчы язмалары). Драматургиядә халык героизмын, патриотизмын, партизаннар хәрәкәтен чагылдырган драмалар дөнья күрү (М. Әмир. Партизан Иван; Т.Гыйззәт. Төнге сигнал; Н.Исәнбәт. Мәрьям). |

| | | |
|---|---|---|
| | | Халыкның тылдагы фидакарь хезмәтен сүрәтләү (Р.Ишморат. Кайту; М.Әмир. Гөлҗамал. Миңлекамал). Тарих һәм заман темасына бәйле олы шәхесләрнең мәһабәт образлары тудырылу (Н.Исәнбәт. М.Вахитов; М.Гали, Х.Уразиков. К.Насыйри). |
| 4.3.1 | Творчество Мусы Джалиля | Иҗатының башлангыч чорында әсәрләрендә күтәрелгән проблемалар. Азат тормышка, хезмәткә дан җырлау, яңа әхлакны яклау, яшьләрне социалистик төзелешкә рухландыру. Кызыл Армияне данлау, иске тормышны фаш итү. “Барабыз” (1925), “Иптәшкә” (1929) җыентыклары.<br><br>“Бәхет”, “Үткән юллар”, “Кызыл каһарман”, “Сугышта” һ.б. әсәрләрендә яшәү һәм көрәш мәгънәсе турында уйланулар. Егерменче елларда шагыйрьнең эзләнүләре, иҗат кыенлыклары. Аның поэзиягә алып килгән яңалыгы, шигъри осталыгы камилләшүе. “Орденлы миллионнар”, “Шигырьләр һәм поэмалар”, “Шигырьләр” җыентыклары. Егерменче-утызынчы еллар яшьләренең героик-романтик рухын чагылдырган әсәрләре: “Походка”, “Батыр егет турында җыр”, “Унсигез”, “Сәрби әби”, “Күк юрга”, “Комсомолларга”, “Яшьләр”, “Урожай”, “Походка”, “Арыш кырында”, “Яшьлек”, “Колхоз кызына”, “Зәйнәп”.<br><br>“Хат ташучы” поэмасының темасы һәм идеясе. Сәнгатьчә эшләнеше. Тимербулат һәм Фәйрүзә образлары, әсәрнең идеясен ачуда аларның әһәмияте. Поэмада халыкчан традицияләренең оста файдаланылуы.<br><br>Халык-ара тормышка, дөнья эшче сыйныфы бердәмлегенә багышлап язылган “Парчалар”, “Еларгамы-көләргәме”, “Джем” әсәрләре.<br><br>М.Җәлилнең татар опера театрын оештыруда күрсәткән хезмәтләре. “Алтынчәч”, “Илдар” либреттолары. “Алтынчәч” героик-романтик драмасының идея-эстетик кыйммәте. Әсәрнең сәхнә тарихы.<br><br>М.Җәлилнең әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышлап язган мәкаләләре.<br><br>Бөек Ватан сугышы елларында М.Җәлилнең көрәше һәм иҗаты. “Тупчы анты” (1942) җыентыгына кергән әсәрләренең төп пафосы, сәнгатьлелек дәрәҗәсе, актуальлеге. М.Җәлил – хәрби корреспондент, сугышчы, шагыйрь.<br><br>М.Җәлилнең әсирлек шартларындагы шигъри һәм гражданлык батырлыгы. “Моабит дәфтәре” җыентыгы. Шигырьләрендә патриот шагыйрьнең лирик образы. Әсәрләрдәге конфликт, аларның кискенлеге. Биредә тупланган әсәрләрнең темасы – коммунист шагыйрьнең туган илгә, халыкка биргән антына тугрылыгын, рухи көчен күрсәтү. “Җырларым”, “Ышанма”, “Кичер, илем”, “Кошчык”, “Ирек” әсәрләрендә кичерешләр, коммунистик идеялелеген күрсәтүдә “Егет көче”, “Үлемгә”, “Катыйльгә” һ.б. әсәрләре. “Ана бәйрәме”, “Сандугач һәм чишмә” балладаларының идея-эстетик көче. Аллегорик образлар тудыруда М.Җәлилнең новаторлыгы. Лирик герой уйларындагы фәлсәфи тирәнлек.<br><br>Фашизмның ерткыч асылын, кешелек дошманы булуын аяусыз фаш итүдә “Бүреләр”, “Вәхшәт”, “Сакчы” һ.б. әсәрләре. Совет солдатының гуманизм һәм фашистларның кабахәтлеген ачуда шагыйрь кулланган контрастлык чаралары. “Моабит дәфтәре”ндә интернационализм идеясе. Шагыйрьнең киләчәккә ышаныч белән каравын белдергән “Сугыштан соң”, “Төзүче”, “Яңа ел теләкләре”, “Шатлыкны каршылап” шигырьләре. Юмористик шигырьләре: “Хәдичә”, “Томаулы гыйшык”, “Гашыйк һәм сыер”, “Табут”, “тозлы балык”, “Борча” һ.б. |

| | | |
|---|---|---|
| | | "Моабит дәфтәре"нең совет һәм дөнья әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше. Муса Җәлил иҗаты турында илебез һәм чит ил язучылары, галимнәре. |
| 4.3.2 | Творчество Фатиха Карима | 20 нче еллар уртасында шигърияткә килеп, яңа тормышка, яшьләргә, хезмәткә дан җырлавы; комсомол рухы алып килүе. Төрле вакыйгаларга мөнәсәбәтен шигырь аша белдерүе, укучыга ниндидер хәбәр җиткерү формасында язуы. Көрәш дәрте белән мавыгу, декоратив сөйләүгә, коры риторикага, яңа формалар белән мавыгуга китерүе; образлылык кимүе, сүрәт чаралары ярлылануы («Безнең һәйкәл», «Закон). 30 нчы елларда шигъри осталыгы, әдәби зәвыгы үсүе, киңәю; шигырьләрендә лирик җылылык, мөләемлык, табигыйлек артуы («Зәйтүнә», «Беренче бала», «Кемгә сөйлим серләремне»). Бу чор иҗатының төп тема-мотивлары: социалистик хезмәт, бәхетле киләчәк, совет кешесенең гуманистик сыйфатлары («Җиденче мич», «Тавышлы таң»); илне саклау («Чайка башыңны», «Пулеметчы», «Аникин»). Тоткынлык чоры иҗаты (1938-1941). Әсәрләрендә тоткынлыкның ачы газабы, рәнҗетелү хисләре өстенлек итү («Я көн генә була, я төн генә...»). Шигырьләренең төп мотивлары: лирик геройның борчылуы, сыкрануы һәм якыннарын, туган җирен сагыну хисләре («Ант», «Көзге яңгырлы төн»). Лирик геройның, ялгыз калып, хатыны,балалары турында уйлануы («Кадрия», «Сагынып кайтам сине»). Символик образларга, чагыштыру, арттыру, антитеза һ.б. алымнарга иркен мөрәҗәгать итүе («Кыр казы»).<br><br>Сугыш чоры иҗаты (1941-1945). Җиңүгә тирән ышаныч белән илен сакларга ант итү («Ант»). Лирик геройның рухи дөньясы баю, ул кешелекле, нык ихтыярлы («Теләк», «Иптәш»). Яшәү һәм үлем турында фәлсәфи уйлануы («Сөйләр сүзләр бик күп алар...»). Фашизмга нәфрәт, ләгънәт яңгырау («Бездә яздыр»). Тыл тормышы, фронт һәм тыл бердәмлеге («Сагынып көтәм», «Газиз әнкәй»). Поэма һәм баллада жанрларында иҗаты иң югары ноктага җитү («Гөлсем», «Идел егете», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Үлем уены», «Партизан хатыны», «Өмет йолдызы», «Тимер һәм тимерче». Прозада һәм драматургиядә сугыш афәтен, совет солдатының батырлыгын күрсәтү («Язгы төндә», «Разведчик язмалары» повестьлары, «Шакир Шигаев» пьесасы). |
| 4.4. | Татарская литература 40-65-х годов | Сугыштан соңгы әдәбият (1945-1965).<br><br>Тыныч хезмәткә күчүнең беренче елларында әдәбият алдында торган яңа бурычлар. Татарстан язучыларының икенче (1950) һәм өченче (1954) съездларының әдәби хәрәкәттәге әһәмияте.<br><br>Тоталитар җәмгыятьнең катгый сәяси катып калган таләпләре өстенлек иткән шартларда әдәбият үсешендәге кыенлыклар. Әдәбият, сәнгатьтә «космополитик» күренешләрен гаепләү. «Конфликтсызлык» теориясе. Уңай герой, заман темасы.<br><br>Шәхескә табыну күренешләренең әдәбият үсешенә тискәре йогынтысы. Әсәрләрдә тема ярлылыгы. Күп яктан чикләнгән, кыен шартларда татар әдәбияты ирешкән кайбер уңышлар. Прозада «Тукай» (Ә.Фәйзи), «Намус» (Г.Бәширов), «Рәхмәт, иптәшләр» (Ә.Еники) кебек уңышлы әсәрләрнең дөнья күрүе.<br><br>Илленче еллар уртасында шәхескә табыну күренешләрен фаш итү. Моның әдәбият үсешенә уңай йогынтысы. Әдәбиятның катгый, катып калган таләпләр чикләреннән котыла башлавы. 50 нче еллар уртасында М.Җәлил һәм репрессияләнгән әдипләрнең (Г.Ибраһимов, К.Тинчурин, |

| | | |
|---|---|---|
| | | Ф.Бурнаш, Ш.Усманов, Ф.Сәйфи-Казанлы, Х.Туфан, С.Рәфыйков һ.б.) иҗаты халыкка кайту.<br><br>Әдәби тормышта дискуссия һәм бәхәсләрнең, ачыктан-ачык сөйләшү рухының көчәюе.<br><br>Әдәби тәнкытьтә кимчелекләрне кыю ачкан мәкаләләр күренә башлау. |
| 4.4.1 | Поэзия 40-65-х годов | Поэзиянең әдәби төрләре. Күңел лирикасы (Ә.Фәйзи. Ач тәрәзәң; С.Хәким. Көткән идем; Ш.Галиев. Әткәйгә хат). Пейзаж лирикасы (Х.Туфан. Гүзәл). Публицистик лирика (Х.Туфан. Тугызынчы дулкын. Ә җир барыбер әйләнә. Туган тел). Фәлсәфи лирика (Ә.Давыдов. Фәлсәфә. Чорлар чатында; Х.Туфан. Һиндстанны эзлим. Сөйли торган материя). Сатирик лирика (Г.Афзал. Тәвәккәл әби. Сәләхетдин абзый сөйли; Ә.Фәйзи. Улым үземә охшаган. Тәнкыйтьче мәхәббәте). Баллада (С.Хәким. Сары капкалы йорт). Поэма (С.Хәким. Дала җыры. Курск дугасы. бакчачылар; Ш.Маннур. Казан кызы; Г. Хуҗи. Гражданин, солдат, шагыйрь; Ә.Давыдов. Ташу; З.Нури. Дан юлы). Шигъри повесть (С.Баттал. Олы юл буйлап; Ш.Маннур. Җир-әнкәнең сылу кызы). Сатирик мәсәл (Ә.Исхак. Аю Яңа урында. Мәче һәм рәсем. Попугай-лектор). Поэзиядә сатира һәм юмор. Декларативлыкка, схематизмга, шаблонлыкка каршы көрәш. Поэтик жанрлар һәм аларның үсешендәге яңалыклар. Традицияләр һәм новаторлык мәсьәләре. |
| 4.4.2 | Проза 40-65-х годов | Татар прозасында үзгәртеп кору процессын чагылдырган әсәрләрнең дөнья күрә башлавы. А.Гыйләҗев, М.Хәсәнов, М.Мәһдиев, һ.б. язучыларның яңа роман һәм повестьлары, драмалары һәм поэмалары. М.Хәсәновның «Язгы аҗаган» романында сурәтләнгән образлар.<br><br>Темалар һәм жанр ягыннан төрлелеге.Фронттагы һәм тылдагы батырлык (Г.Әпсәләмов. Газинур; Г.Бәширов. Намус; М.Әмир. Саф күңел). Дошман әсирлегендәге хәлләрне, фаҗигале язмышларны сурәтләү (Н.Дәүли. Яшәү белән үлем арасында; Г.Әпсәләмов. Мәңгелек кеше). Тыныч тормышны сурәтләүдә заман рухының тирәнәюе (Ә.Еники. Саз чәчәге. Рәшә; Ф.Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы; И.Гази. Гади кешеләр). Тарихка мөрәҗәгать итү (К.Нәҗми. Язгы җилләр; И.Гази. Онытылмас еллар; Ә.Фәйзи. Тукай). Хикәя (Ә.Еники. Кем җырлады?; А.Шамов. Миңнур карт). Повесть (Г.Әпсәләмов. Ак төннәр; Н.Дәүли. Яшәү белән үлем арасында; Ә.Еники. Саз чәчәге). Роман (Г.Әпсәләмов. Газинур. Алтын йолдыз; Г.Бәширов. Намус). Тарихи роман (К.Нәҗми. Язгы җилләр; И.Гази.Онытылмас еллар). Тарихи-биографик роман (Ә.Фәйзи. Тукай). Роман һәм повесть өлкәсендә эзләнүләрнең көчәюе. Прозада сюжет-композиция, тел-сурәт өлкәләрендә эзләнүләр. Иҗат көчләре мәсьәләләре. Үсеш проблемалары.<br><br>Үзгәртеп коруның драматургиядә зур җанлану тудыруы. Тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть, ачыктан-ачык сөйләшү рухының әдәби хәрәкәткә үтеп керүе. Язучыларның иҗтимагый-политик тормышта актив катнашулары. Язучылар күтәргән актуаль мәсьәләләр буенча дәүләт күләмендә әһәмиятле карарлар кабул ителү. Героик һәм тарихи-революцион тема. |
| 4.4.3 | Драматургия 40-65-х годов | Драматургиядә замандаш герой проблемасы.<br><br>Драматургларның индивидуаль стильләре камилләшү. “Муса” (Н.Исәнбәт); “Давылга табан”, “Үлмәс җыр” (Р.Ишморат); Шамил |

| | | |
|---|---|---|
| | | Усманов, А.Яхин, А.Гыйләҗев пьесалары. |
| 4.5. | Татарская литература 65-85-х годов | 65-85 еллар әдәбияты. Идеологик басымның кимүе. Чынбарлыкны күпъяклы һәм дөреслек белән сурәтләү тенденциясенең көчәя баруы. Эпик колач киңәю. Прозаның төп темалары. Тарихи темаларны яктырту. Традицион авыл темасын сурәтләү үзенчәлекләре. Ватан сугышы темасын яктыртудагы яңалыклар. Заман темасын яктыртуда яңалыклар. (Г.Ахунов, Н.Фәттах, Ф.Хөсни, Ә.Еники, М.Мәһдиев, Р.Төхвәтуллин һ.б.). «Хрущев җепшеклеге» исеме белән тарихка кергән хәбәрдарлык, демократия күренешләренең 60 нчы еллар әдәбият-сәнгатенә уңай йогынты ясавы; идеологик басымның бераз кимүе, әмма тиздән партия йогынтысы яшәешнең бөтен өлкәләренә үтеп керүе; ил тормышында торгынлык чоры башланауы.<br><br>Милләтләр дуслыгы, интернационализм идеяләре җирлегендә совет халкы формалашуы; рус теленең зур тизлек белән башка телләрне аралашудан кысрыклап чыгаруы.<br><br>Талантлы каләм ияләренең, хакимият идеологиясен читләтеп үтеп, әдәбиятының эстетик асылына мөрәҗәгать итүе, халыкның гасырлар дәвамында тупланып килгән әхлакый кыйммәтләрен яклап чыгуы һәм сәнгати югары әсәрләр иҗат итүе (Ә.Еники.Әйтелмәгән васыять. Туган туфрак; А.Гыйләҗев. Өч аршын җир. Җомга көн кич белән; Т.Миңнуллин. Әлдермештән Әлмәндәр һ.б.<br><br>Әсәрләрендә социалистик җәмгыятенең чын асылы ачылуы, эзоп теле белән тәнкыйть ителүе; кеше һәм система каршылыгы әдәби чаралар ярдәмендә тасвирлануы (А.Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә; Ә.Баянов. Тау ягы повесте һ.б.). С.Хәким, Т.Миңнуллин Россия Дәүләт бүләгенә лаек булулары; иң уңышлы әсәрләре рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителүе. |
| 4.5.1 | Поэзия 65-85-х годов | Поэзиядә уйланучан башлангычның көчәюе, лирик каһарманның рухи дөньясы катлаулануы, зиһен һәм фикер эшчәнлеген тулырак ачарга омтылыш. Замандашыбызның рухи тәҗрибәсен тулырак ачкан олы образын тудыруда төп юнәлешләр, идея-тематик үзгәрешләр. Кеше шәхесенә игътибар арту. Лирик агымның көчәюе. Өлкән буын шагыйрьләренең иҗат активлыгы үсүе (Х.Туфан, С.Хәким, Ш.Маннур, М.Садрый, З.Нури, Н.Арсланов һ.б).<br><br>Ә.Давыдов һәм З.Маннур иҗаты. Тарихи-революцион тематика һәм поэтик М.Ногман поэмалары. И.Юзиев, Ш.Галиев, Х.Камал, Г.Афзал поэзияләренең үзенчәлекләре. Поэзия өлкәсендә эзләнүләр. Яңа буын шагыйрьләрнең әдәбиятка килүе (Ә.Баянов, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалимов, Р.Гатауллин). Җыр һәм романслар (С.Хәким, Н.Арсланов, М.Ногман, Г.Зәйнәшева, Л.Айтуганов, Р.Әхмәтҗанов, М.Әгъләмов). Поэзиядә сатира һәм юмор. Декларативлыкка, схематизмга, шаблонлыкка каршы көрәш. Поэтик жанрлар ңәм аларның үсешендәге яңалыклар. Традицияләр һәм новаторлык мәсьәләре.<br><br>Лиро-эпик жанрның үсеш-үзгәреш кичерүе.<br><br>Баллада (Зөлфәт. Ике ат турында баллада. Фатыйма. Кара күбәләк; М.Галиев. Чишмә караучы карт; И.Юзеев. Унөченче; Р.Әхмәтҗанов. Таш елады). Эпик поэма (С.Хәким. Кырыгынчы бүлмә; И.Юзеев. Әнкәй. Өчәү чыктык ерак юлга; Ә.Баян. Сәяхәтнамә; М.Әгъләмов. Тукайдан хатлар). Шигъри роман (С.Баттал.Чирмешән якларында; Ә. Давыдов. Йокысыз |

| | | |
|---|---|---|
| | | төннән соң). Оратория (Р.Харис. Кеше). Либретто (Г.Рәхим. Каһәрләнгән мәхәббәт).<br><br>Табигый хис-тойгылар чагылыш тапкан лирик шигырьләр, көйгә салынып, киң яңгыраш алган җырлар булып китүе (С.Хәким. Башка берни дә кирәкми; Ш.Галиев. Раушаниям, бәгърем; И.Юзеев. Яшь наратлар. Мәтрүшкәләр; Г.Зәйнашева. Китмә, сандугач; Р.Фәйзуллин. Аккошлар; Р.Вәлиев. Зинһар өчен кермә төшләремә һ.б.).<br><br>Г.Афзалның тормыш һәм иҗат юлы.<br><br>Г.Афзалның шигъри таланты. Шагыйрь поэзиясендә табигать культы (“Бу кырларда”, “Апрель җиле!, “Кышкы урман” һ.б.).<br><br>Сюжетлы шигырьләрендә комик типлар тудыру осталыгы (“Сәләхетдин бабай сүзләре”, “Сабирҗан хаты”, “Шәрифулла күршем белән”).<br><br>Сатирик поэзиянең төрле формаларына, жанрларына мөрәҗәгать итүе: фельетон, памфлет, мәсәл, җыр, эпиграмма, диалог, монолог һ.б.<br><br>Г.Афзал сатирасының төп үзенчәлеге булып халык иҗаты традицияләренең, чичәнлек рухының көчле булуы.<br><br>И.Юзеев иҗаты. Шагыйрьнең рус (“Последнее испытание”, “Маленький рыжий кони”) һәм башкорт (“Язылмаган поэма”) телләренә тәрҗемә ителгән китаплары. Башлангыч чор иҗатында (шигырьләренең ритмикасында, сөйләм интонациясендә, лирик чигенешләрдә, композиция төзелешендә) Такташ йогынтысы. Шул җирлектә поэзиянең иң күркәм романтик һәм реалистик традицияләрен дәвам итүе. Поэмаларда уңышлы эшләве. И.Юзеев иҗатында лиро-эпик жанр, үсеш-үзгәреш кичереп, эпик вакыйгаларны кичерешләр байлыгы аша сурәтләү мөмкинлеге артуы сизелә. Тематик киңлек күзәтелү.<br><br>Поэмаларда стилистик төрлелек. Сюжетка корылган (“Фәрит-Фәридә”); лирик монолог (“Тормыш җиңә”); драматик легенда (“Соңгы сынау”); шигырь, дастан, парча, лирик чигенү, балладалар циклы (“Мәхәббәт китабы”); документальлек (“Таш диварлар авазы”).<br><br>И.Юзеев драматургиясендә лирик агымның, романтик пафосның көчле булуы, җыр, музыка белән үрелеп килүе. Жанрлар төрлелеге: “Резидәкәй” (музыкальпьеса), “Сандугачлар килгән безгә” (драма), “Командировка” (моңсу комедия), “Очты дөнья читлегеннән”, “Соңгы төн” (тарихи-революцион трагедия) һ.б.<br><br>И.Юзеев – комедияләр остасы (“Мәкәрҗәгә барган идек”, “Кайтмый калсам – көтәрсеңме?” һ.б.).<br><br>Р.Фәйзуллин иҗаты. Кыска шигырьләр язу, “сүз белән рәсем ясау” осталыгы. Аларга тирән мәгънә, фәлсәфи эчтәлек салып халыкны тапкырлык, зирәклек юнәлешендә тәрбияләү һәм кыска үткен форманы үстерүдә уңышлары. Дөнья поэзиясендәге барлык төшенчәләрнең – намус, тугрылык, дуслык-туганлык, рух азатлыгы, бәйсезлек, коммунарлар, Буратино, ырымнар, Аллага табыну, иман ныклыгы, палач балталары, лазерлар, тәхетләр, хөкемдарлар, яшәү-сәгадәт, өмет-ышанычлар – барысының да поэмаларда урын алуы.<br><br>Р.Фәйзуллинның җыр жанрында, публицистикада, балалар әдәбиятында нәтиҗәле эшләве. Кол Гали, Тукай, Кутуй, Туфан иҗатына багышланып |

| | | |
|---|---|---|
| | | язылган монографик характерда хезмәтләре.<br><br>Поэмаларның жанр төрлелеге: “Көрәшчеләр” (фәлсәфи), “Сәйдәш” (шигъри повесть). Әдәби – публицистик мәкаләләре, иҗат портретлары. |
| 4.5.2 | Проза 65-85-х годов | Чынбарлыкны күпъяклы һәм дөреслек белән сурәтләү тенденциясенең көчәя баруы. Эпик колач киңәю. Прозаның төп темалары. Тарихи темаларны яктырту. И.Газиның «Онытылмас еллар», Ф.Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романнарында халык тормышын яктыртудагы яңалыклар. Татар халкының үткәнендәге иҗтимагый-рухи тормышын һәм үсешен яктыртуда Н.Фәттахның «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар»; Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәрләре. Үткәндәге бөек тарихи шәхесләрне гәүдәләндерүдә А.Расихның «Ямашев»; Г.Шәрипованың «Гафур гаиләсе»; Җ.Тәрҗемәновның «Көмеш дага» романнары. Традицион авыл темасын сурәтләү үзенчәлекләре. Ф.Хөснинең «Утызынчы ел», Р.Рафиковның «Беренче яз», М.Хәсәновның «Язгы аҗаган» романнарында авылны коллективлаштыру проблемасы гәүдәләнеше. Кеше язмышына игътибар арту. «Язгы авазлар» (А.Расих), «Йолдызым» (Р.Төхватуллин), «Яшьлегемне эзлим» (Ә.Баянов), «Берәү», «Күпер чыкканда» (В. Нуруллин), әсәрләрендә сугыштан соңгы авылның үсеш кыенлыклары. Шул елларда яшь кеше үсеше, формалашуы «Без 1941 ел балалары», «Фронтовиклар» (М.Мәһдиев), «Шинельсез солдатлар» (В.Нуруллин), «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турындагы хикәят» (А.Гыйләҗев) әсәрләрендә чагылу. Фәнни-техник революция һәм хәзерге авыл проблемаларының әдәбиятта гәүдәләнеше (Г.Бәширов «Җидегән чишмә»; Ә.Еники «Әйтелмәгән васыять»; М.Хәбибуллин «Чоңгыллар»; Х.Хәйруллин «Канатлар талмасын»).<br><br>Ватан сугышы темасын яктыртудагы яңалыклар. Г.Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше»; Ш.Маннурның «Муса»; Н.Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында»; Х.Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр»; М.Юнысның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна»; Ш.Рәкыйповның «Кайдан син Җан?», «Кызлар-йолдызлар» әсәрләре.<br><br>Заман темасын яктыртуда яңалыклар.<br><br>Эшчеләр темасын яктырту. «Сүнмәс утлар» (Г.Әпсәләмов), «Хәзинә», «Хуҗалар», (Г.Ахунов), «Тын елга буенда» (С.Рафиков), «Зәй энҗелре» (А. Гыйләҗев), «Ут һәм су» (Ә.Баянов, «Каты токым» ( Ш. Бикчурин) әсәрләре. Мораль – әхлак проблемаларына игътибар арту. Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» повесте, А.Расихның «Сынау» романы. Интеллигенция тормышын яктыртуда үзенчәлекләр (А.Расих «Ике буйдак»; Г.Әпсәләмов «Ак чәчәкләр», «Яшел яр»; А.Гыйләҗев «Урамнар артында яшел болын»). Роман һәм повесть өлкәсендә көчәюе. Прозада сюжет-композиция, тел-сурәт өлкәләрендә эзләнүләр. Иҗат көчләре мәсьәләре. Үсеш проблемалары. Тематик киңлек күзәтелүе. Татар халкының үткән тарихын, иҗтимагый-рухи тормышын аңларга омтылу (Н.Фәттах. Әтил суы ака торур. Сызгыра торган уклар; М.Хәбибуллин. Кубрат хан һ.б.).<br><br>Совет хакимиятенең төрле чорларында татар авылы кешеләрен сурәтләү, аларның яшәү рәвеше (Ф.Хөсни. Утызынчы ел; А.Гыйләҗев. Язгы кәрваннар; Г.Ахунов. Чикләвек төше; М.Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары. Кеше китә – җыры кала).<br><br>Бөек Ватан сугышы елларының каршылыкларын, фаҗигале вакыйга- |

| | | |
|---|---|---|
| | | хәлләрен яңа чор биеклегеннән бәяләү (Х.Камалов. Һәркемнең гомере бер генә; Ш.Рәкыйпов. Кайдан син, Жан? Кызлар-йолдызлар; М.Юныс. Шәмдәлләрдә генә утлар яна һ.б.)<br><br>Эшчеләр тормышы, производство мәсьәләләре (Г.Ахунов. Хәинә. Хуҗалар; А.Гыйләҗев. Зәй энҗеләре; Ә.Баянов. Ут һәм су).<br><br>Халкыбызга хас гадәт-йолаларның кимүе, әдип-әхлакның бозылуы өчен борчылу (Ә.Еники. Әйтелмәгән васыять; Х.Сарьян. Бер ананың биш улы; А.Расих. Сагыну; А.Гыйләҗев.Җомга көн кич белән һ.б.).<br><br>Фән кешеләре, зыялылар тормышын рухи-психологик планда ачу (А.Расих. Ике буйдак; Г.Әпсәләмов. Ак чәчәкләр. Яшел яр; А.Гыйләҗев. Урамнар артында яшел болын. Урталыкта һ.б.). |
| 4.5.3 | Драматургия 65-85-х годов | Драматургиядә замандаш герой проблемасы.<br><br>Хәзерге драма иҗаты үсешендәге мөһим тенденцияләр, сыйфатлар. Мораль башлангычның көчәюе, сюжетта гаделлеккә омтылу, конфликтларның әхлакый планга корылу, фикер тыгызлыгы һәм үткенлеге, интеллектуальлек өстенлек алу.<br><br>Р.Ишморат («Яңа бистәдә»), Г.Насрый («Кадерле минутлар»), Н.Исәнбәт («Гүзәл») һ.б. драматурглар иҗатында кешеләр арасындагы яңа мөнәсәбәтләр проблемасы. Кеше психологиясен ачуның яңа чараларын эзләү. Ф.Хөсни һәм М.Әмир драмалары. Героик һәм тарихи-революцион тема. «Муса» (Н. Исәнбәт), «Давылга таба», «Үлмәс җыр» (Р.Ишморат), «Шамил Усманов» (А.Яхин, А.Гыйләҗев) пьесалары.<br><br>Драматургларның индивидуаль стильләре камилләшү. Х.Вахит драматургиясенең төп сыйфатлары. «Беренче мәхәббәт», «Соңгы хат», «Туй алдыннан» әсәрләрендә яшьләр һәм әхлах проблемалары.<br><br>Ш.Хөсәеновның драма иҗатында чынбарлыкны сурәтләү үзенчәлекләре. «Зөбәйдә–адәм баласы», «Әни килде» әсәләренең художество эшләнеше.<br><br>Әдәби төрләр, жанрлар, жанр формалары үсеше.<br><br>Бу чор сәхнә әдәбиятында чын мәгънәсендә халыкчан образ-характерлар, замандаш сыйфатларын үзләрен туплаган типлар мәйданга чыгуы (Ш.Хөсәеновның «Әни килде» әсәрендә Ана, Т.Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәрендә Мәдинә, «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә Әлмәндәр, И.Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» әсәрендә Хәмзин һ.б.).<br><br>Х.Вахит – шагыйрь: «Безнең авыл», «Якты юллар», «Яз килә» җыентыклары. Либреттолар авторы: «Самат», «Дим буенда», «Җиһангир». Х.Вахит – үзенчәлекле драматург: «Беренче мәхәббәт», «Рәхим итегез», «Илһамия», «Карлыгач канат җәя», «Соңгы хат», «Туй алдыннан»,» «Мәхәббәтең чын булса», «Оныта алмасаң нишләрсең» һ.б. Драматургның сюжет төзү остасы булып танылуы, аның нигезен тәшкил иткән конфликт тормышчанлыгы, әхлакый һәм фәлсәфи киңлеге белән аерылып торуы. Җыр-музыка пьесаларының лейтмотивына әйләнүе. Тәрбия, әхлак мәсьәләләре, матур рухи башлангычларны яклавы, тормыштагы ямьсез күренешләрне, кешеләрдәге һәртөрле кимчелекләрне тәнкыйтьләве. Яшьлек темасы, яшь геройларның зур тормышка килү юлы, характеры формалашу шартлары, хезмәткә, мәхәббәткә, дуслыкка мөнәсәбәтләре кызыксындыруы. Художестволы форма һәм стиль өлкәсендәге эзләнүләр. Романтик сурәтлелек, музыкальлек, |

| | | |
|---|---|---|
| | | тамашалыкны яңа баскычка күтәреп, күпсанлы әдәбият-сәнгать сөючеләрне театр белән кызыксынуга этәрүе. |
| 4.6. | Пути и основные тенденции<br><br>развития татарской литературы конца XX века | Сәнгатьнең бер тере буларак гасыр кичеше әдәбияты. Яшәешнең, дөньяның һәрвакыт үзгәрештә булуы, чорның әдәбият үсешенә, иҗат кешеләренең рухи-фикри эзләнүләренә тәэсир иткән соңгы ике дистә ел эчендәге әһәмиятле вакыйгалары. XX-XX1 гасыр цивилизациясе һәм мәдәнияте контекстында хәзерге татар әдәбияты. |
| 4.6.1 | Татарская поэзия в контексте общественно-исторических реалий | Җәмгыятьтә яңа иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләр. Әдәбиятыбыздагы “ак тап”лар. Татар әдбәбият беле галимнәренең эшчәнлеге (И. Нуруллин, Ф.Хатипов, Ф Мусин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Сверигин, Ф.Галимуллин, Г. Гыйльман, М Вәлиев). |
| 4.6.2 | Новые направления в татарской прозе конца XX века | XX гасыр ахыры татар прозасы: стиль тенденцияләре, жанрлар төрлелеге: реалистик, романтик юнәлешләр, интеллектуаль тенденция, экзистенциаль фикерләү төре, неомифологизм. |
| 4.6.3 | Драматургия и театр конца XX века | Гасыр ахыры татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре. Т.Миңнуллин, З.Хәким, Аманулла, И.Зәйниев, Д.Салихов, Р.Зәйдулла иҗаты. |
| 5. | **Раздел 5. Современная татарская литература (9 семестр)** | |
| 5.1. | Современные тенденции развития татарской<br><br>поэзии | Хәзерге татар поэзиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре, алшартлары. Хәзерге татар поэзиясендә реалистик юнәлеш.<br><br>Хәзерге татар поэзиясендә романтик юнәлеш. Соңгы еллар татар поэзиясендә интеллектуаль тенденция, модерн алымнар. Р.Харис иҗаты (1943). З.Мансуров иҗаты (1949). Р.Зәйдулла иҗаты. Яңа буын шагыйрьләр иҗаты. |
| 5.2. | Разнообразие литературных направлений и течений в татарской прозе | М.Кәбиров әсәрләрендә постмодернистик алымнар.<br><br>Хәзерге татар прозасында интеллектуаль тенденция. (М.Кәбировның “Сары йортлар сере” повесте).<br><br>Хәзерге татар прозасында концептуализм күренеше (Г.Гыйльманның “Оча торган кешеләр” әсәре мисалында).<br><br>Хәзерге татар прозасында мифологик катламның вазифасы. (Н.Гыймадинова повестьлары). XXI йөз башы татар прозасында реалистик роман жанры. (З.Хәкимнең Бөек Ватан сугышы елларында совет коллаборационизмы темасына караган “Легионер” романында экзистенциаль мотив). |
| 5.3. | Основные тенденции и закономерности развития<br><br>татарской драматургии | Хәзерге татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре. Т.Миңнуллин, З.Хәким, Аманулла, И.Зәйниев, Д.Салихов, Р.Зәйдулла иҗаты. “Яңа татар пьесасы” конкурсының татар драматургия үсешенә йогынтысы. Татар театрлары, аларның репертуары. Театраль фестивальләр. |

## Критерии оценивания практического (семинарского) занятия:

**1 балл** - выставляется студенту, сформулировавшему полный и правильный ответ на вопросы семинара, логично структурировавшему и изложившему материал. При этом студент должен показать знание специальной литературы. Необходимо продемонстрировать умение обозначить проблемные вопросы, дать исчерпывающие ответы на уточняющие и дополнительные вопросы.

**0 баллов** - выставляется студенту, если он не дал ответа по вопросам семинара; дал неверные, содержащие фактические ошибки ответы на все вопросы; не смог ответить на дополнительные и уточняющие вопросы. Или студенту отказавшемуся отвечать на вопросы семинара.

## Контрольные вопросы и задания

## Задания для самостоятельного изучения

### 1 курс 2 семестр

### 1. Изучить следующие понятия:

Тәңре, Төрки каганлык, туран (рун), рун һәм уйгур графикалары, рун язуы, гомумтөрки әдәбият, Орхон ядкярләре, ташъязма, ярлык һәм битекләр, команн табышмагы, татар, шәхес, концепция, Яңарыш (Ренессанс) әдәбият, дини дидактика, суфичылык (тасаувыф), тарикат, Илаһият, Аллаһы Тәгалә, Коръәни эстетика, нәзыйрә, конталинация, символика, ярлыклар, хөтбә, пирнамә, Болгар–хәзәр чоры әдәбияты, Алтын Урда чоры әдәбияты, Казан ханлыгы чоры әдәбияты, хикәят, хикмәт, кыйсса, дастан, тартмалы композиция, мәдхия, мәрсия, робагый, касыйдә, газәл, поэма, эпос, пародия, сатира, утопия, Көнчыгыш романтизмы, психологизм, реализм.

### Вопросы для самостоятельного изучения

1. Йосыф Баласагунлы иҗатында Ренессанс тендицияләре
2. Төрки-татар Яңарыш әдәбиятында шәхес концепциясе
3. Кол Галинең “Кыйсса-и Йосыф” әсәрендә дөнья сурәте.
4. Кол Гали поэмасының синкретик сыйфатлары.
5. Котб иҗатында новаторлык.
6. Котбның “Хөсрәү вә Ширин” поэмасында геройларның рухи эволюциясе.
7. Хисам Кятибнең “Җөмҗөмә солтан” поэмасында вакыт һәм пространство.
8. XIV йөз төрки–татар шигъриятендә фольклор мотивлары.
9. Мөхәммәдьяр иҗатында фәлсәфи карашлар
10. Котбның “Хөсрәү вә Ширин” поэмасында тәнкыйди пафос.
11. Котбның “Хөрәү вә Ширин” поэмасында ир-егетлек идеалы.
12. Мәүлә Колый хикмәтләрендә фәлсәфи карашлар.
13. Сайадинең “Дастан Бабахан” поэмасында кеше проблемасы.
14. Сайяди бине Кылычның «Дастан Бабахан» әсәренең тарихи җирлеге, сюжет-композициясе, идея-проблематикасы.
15. Борынгы татар әдәбиятында дини-мифологик образлар.
16. XIV йөз поэзиясендә кеше концепциясе.
17. Сәйф Сараи иҗатында фольклор мотивлары.
18. Сәйф Сараиның “Сөһәйл вә Гөлдерсен” поэмасында мәхәббәт культы.
19. С.Сараиның «Сөһәйел вә Гөлдерсен» поэмасында мәхәббәт проблемасы.
20. Сәиф Сараи иҗатында сатира һәм юмор.
21. Сәиф Сараиның “Гөлестан бит-төрки” әсәренең жанр үзенчәлекләре.

22. Сәйф Сараи иҗатында халык образы.
23. Мөхәммәдьяр иҗатында дини һәм дөньяви идеяләр.
24. Суфичылык поэзиясендә язмыш концепциясе.
25. Борынгы татар поэзиясендә тәнкыйди пафос.
26. Өмми Кәмал иҗатында дөнья сурәте.
27. XIV йөз төрки-татар поэзиясендә психологизм.
28. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында мәхәббәт культы.
29. Таҗетдин Ялчыгол иҗаты һәм тормышы.
30. Төрки-татар Яңарыш (Ренессанс) әдәбиятының төп сыйфатлары.

**2 курс 3 семестр**

**Список художественной литературы для изучения**

Әбелмәних Каргалый “Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди», «Җиһангир ханга», «Кибай байга», «Мәдхе рәсүл», «Сахрада», «Галәм әйванидә...» һ.б.

Һибәтулла Салихов: Беренче мәрсияләре. «Тәндә җаным...» шигыре. ”Тәхфәтел-әуляд» (“Баларга бүләк”), «Мәҗмәгыль-адаб» (”Әдәпләр җыентыгы» һ.б..

Шәмсетдин Зәки: «Нә оерсан, уян!», «Күз кирәктер», «Дөнья һәм мин» Һ.б. газәл, мәдхия, робагый, мәснәви, кыйтга һ.б. жанрлардагы

Баһави: «Бүз егет» дастаны.

Габделҗәббар Кандалый: «Рисалаи-р-иршад», «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмалары. «Бу илләрдә торып калсам», «үз вазифасын үтәмәүче муллаларны («Тотынышып кулың кулга») , «Кызыклы шигырьләр» циклы. «Шәфгый», «Фәрхи», «Мәхәббәтне сәңа салды ходаем...», «Сурәтең төшемә керер» , «Сәхибҗәмал» Һ.б.

Шиһабеддин Мәрҗани: «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр»

Каюм Насыйри: «Әхлак рисаләсе», «Тәрбия китабы», «Кырык вәзир кыйссасы», «Әбүгалисина кыйссасы», «Кырык бакча»-«Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият», «Әфсанәи Гөлрөх вә Камәрҗан» романы.

«Мәкәрҗә бәете»

Гали Чокрый: «Шәмгыз-зыя», «Мәдхе Казан», «Хаҗнамә», «Фосуле әрбага» циклы.

Мифтахеддин Акмулла: «Бәгъдәссәлам, Нургали мулла...», «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе », «Урыным - зиндан...», «Гаҗәб: һәр кем гани булса...», «Минем кебек булыр микән бәхетсез», «Иң әүвәл пакьләү кирәк эчнең керен...», «Бәланың күбе чыга эчемездән...», «Башка илне без күрәбез...».

Баһаведдин Вәисев: «Әзәлдән та әбәд, дуслар...», « һай, дөнйадыр - бакча, чәчәге - залимнәр...», «Әхүале рөгъйәт».

Яков Емельянов: «Ярлы тормыш», «Кайгы», «Улыма», «Санлау», «Саран бай», «Әләк».

Әхмәт Уразаев-Кормаши: «Кыйссаи Бүз егет», «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә».

Галимәтелбәнат Биктимирова: «Тәргыйбел-бәнат» («Кыз балаларда укуга дәрт уяту»), «Мәгашәрәт адәбе» («Аралашу кагыйдәләре»).

Хәнифә Гыйсмәтуллина: «Тәгъзия» («Юаныч»), «Тәргыйб» («Кызыксындыру»).

Галимә Рәхмәтуллина: «Аналарга яднамә», «Иҗмагъ ишеге».

Бибигөлҗамал: «Бидгать-намә» әсәре.

Газизә Сәмитова: «Сәнең өчен», «Җан дустыма», «Күп сайрама, сандугач!», «Кыз тәкъдире», «Сагыш», «Ничек түзим?», «Зая гомер», «Каләм», «Гыйлемлек җанга юлдаш», «Төркем барга күркем бар» , «Анда киткәч», «Хәсрәт күп күргәнгә язык юк», «Ютәл йөрәкне өзәдер», «Ялгыз торгынлыктан үлгән юк, Әмма ялгызлыкта иләм юк».

«Тутыйнамә», «Кәлилә вә Димнә», «Мең дә бер кичә»

Муса Акъегетзадә: «Хисамеддин менла» әсәре.

Заһир Бигиев: «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә», «Зур гөнаһлар» («Гөнаһе кәбаир»), «Мавәраэннәһердә сәяхәт» әсәре.

Габдрахман Ильяси: «Бичара кыз» пьесасы.

Фатих Халиди «Мең дә бер кичә», «Мең дә бер сәхәр», «Рәдде «Бичара кыз» әсәре, «Морад Сәлимов» драмасы, «Саран, надан Теллә бай» пьесасы.

«Комедия Чистайда»

Ризаэддин Фәхреддин: «Тәрбияле ава», «Тәрбияле бала», «Шәкертлек әдәбе», «Болгар вә Казан төрекләре», «Алтын Урда ханнары», Асар» («Эзләр») хезмәтләре. «Сәлимә, яки Гыйффәт», «Әсма, яки Гамәл вә җәза» повестьлары.

Фатих Кәрими: «Салих бабайның өйләнүе», «Шәкерт илә студент», «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы», «Нуреддин хәлфә» повесть-хикәяләре, «Морза кызы Фатыйма» повесте, «Хыялмы? Хакыйкатьме?» әсәре, «Аурупа сәяхәтнамәсе», «Кырымга сәяхәт» әсәрләре.

Закир Һади: «Бәхетле кыз», «Бәхетсез кыз», «Мәгъсүм» хикәяләре. «Яңа әсхабе кәһәф», «Җиһанша хәзрәт» повестьлары.

Шакир Мөхәммәдев: «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай», «Яфрак асты, яки Мәкәрҗә ярминкәсе», «Япон сугышы, яки доброволец Батыргали агай» повестьлары.

**2 курс 4 семестр**

**Список произведений для заучивания наизусть**

*(по выбору по 5 стихотворений каждого автора, стихи, выделенные курсивом обязательные)*

